
PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2015 ДЕКАБРЬ № 12

Сөембикә

ВАКЫТНЫ НИЧЕК ҖИТКЕРЕРГӘ
кая ашыгабыз?

МОГҖИЗА БАР УЛ!
Малахов белән диңгезгә

РУСЛАН ШӘРӘФЕТДИНОВ СЫЙЛЫЙ:
тәмле «чыршы»

Аида ГАРИФУЛЛИНА:

«ТОРМЫШКА, ҖЫРГА, МӘХӘББӘТКӘ ТАБЫНЫП ЯШИК!»



PRESSA.RU



70

1945–2015

Сугыш язган хатлар

Исмәгыйль Сәлимшин Башкортстанның Туймазы районы Нарыш авылында дөньяга килгән. 1921 елгы ачлык вакытында Татарстанның Ютазы районы Кәрәкәшле авылына күченә. Тегермәнче булып эшли. Урыссу кызы Гайнелҗинан белән гаилә кора. Сугышка 1941 елның 15 ноябрендә китә. Аңа ул вакытта 46 яшь була. Сугышның башыннан алып ахырына кадәр алгы сызыкта — ут эчендә йөри. Сапер, хәрби төзүче була, күперләр, блиндажлар төзүдә катнаша. Ике тапкыр яралана, ике тапкыр контузия ала. Украина, Польша, Венгрия, Чехословакия, Австрия илләрен азат итүдә катнаша, Дунай елгасын кичеп чыга. Биш ел буе ул фронт дәфтәре алып бара: кайсы шәһәрләр, авыллар, станцияләр аша узганнарын, фронтташ дуслары, госпитальдә күргәннәрен — гомумән, сугыш хәлләрен яза.
1945 елның 3 августында демобилизацияләнә. Хатыны Гайнелҗинан белән биш бала тәрбияләп үстерәләр. Исмәгыйль Сәлимшин 1975 елның 18 февралендә вафат була һәм туган авылы Нарышта җирләнә.

«1943 ел, 16 июль.
Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Аллаһы Тәгаләнең исеме белән.
Хат башы, языгыз каршы!
Кадерле һәм сөекле хатыным Гайнелҗинанга, күз карам кебек күргән газиз балаларыма күптин-күп сәламнәр күндереп калам. Һәркайсыгызга саулык-сәламәтлек, шат-рәхәт тормыш, бәхетләр теләп калам.
Шушы көннәрдә мин сезнең хатны алып укыдым. Хатның һәр юлы, һәр сүзе минем өчен бик кадерле. Аңлатып тору кирәк түгелдер, хат алышу – очрашуның яртысы инде ул. Хат аша барыгызның да булмышын күз алдыма китердем. Балаларымның хак юлда булып, үз көннәрен үзләре тәэмин итә алуларына ышандым. Гайнелҗинан, бәгърем, рәхмәт сиңа, син җылы канатларың белән балаларны саклап, тәрбияләп үстереп киләсең. Өлкән кызым Нажия, сиңа рәхмәт. Әтиең урынына син тамак туклыгына ризык табасың. Ходайдан киләчәктә дә сезгә көч-куәт, түземлек сорап догалар кылам.
Әлхәмдүлилләһ, мин дә якты дөньяда йөрүемне дәвам итәм. Аллаһының шушы бәхетләрдән аермавына мин бик ризамын. Алдагы өметләрдә дә шулай ук аякларымда үзем йөреп торсам иде, дип ялынып-ялварып сорыйм.
Көңелем бу арада бераз тынычланып тора. Ләкин шуны әйтми мөмкин түгел. Бик сагындым, саргайдым. Бер сәгать тормый, аккан болытларга ияреп кайтып китәр идем, ләкин андый көчем юк. Очкан кошлар да безнең тарафка түгел, чит-ят якларга юл ала шикелле. Эч поша, йөрәк сызлый. Ахыр чиктә бик кыен. Нәрсә эшлик, түзәргә кала. Башны ташка орып булмый.
Тагын шуны уйлыйм. Туган-үскән Нарышыбызга кайтып төпләнүегез, бәлки, дөрес булгандыр. Кәрәкәшледә, мин булмагач, аркаланыр кеше калмагандыр. Үз авылыбызда, үз нигезебездә, туган-тумача арасында, чынлап та, кыен булмас үзегезгә. Үземнең хәлгә килгәндә, тагын бер әйберне язмый үтә алмыйм. Элегрәк фоторәсем салганыем. Күрәсез, мин бик ябык, тәндә ит әсәре юк. Аптырагансыздыр, бу ни хәлгә төшкән дип. Төшәрсең, ашарыңа бер телем икмәк, эчәреңә бер чеметем чәй булмаса. Ифрат кыен хәлләргә юлыктык бит без. Бөлгенлекнең соңгы чигенә җиттек. Атарга патроннарыбыз бетте. Ничек котыла алуыбызга әле булса да ышанып җитмибез. Аллага көн дә дога кылам. Якты дөньяда яшәүләр бетмәгән әле.
Шулай безнең хәлләр. Төшенкелеккә бирелмәгез, без хәзер әйбәт шартларда. Үз бурычыбызны үтәргә әзерләнәбез. Бу тарафта барысы да әйбәт булачак.
Хушыгыз. Изге теләкләр теләп калам. Әтиегез Исмәгыйль.»

(Исмәгыйль СӘЛИМШИННЫҢ бу хатын
Татарстан Фәннәр академиясе аспиранты Александр ДОЛГОВ әзерләп бирде.
Хат Исмәгыйль аганың кызы Сиринә ШАҺИМӘРДАНОВАда саклана.
Ул үзгәртелмичә-төзәтелмичә тәкъдим ителә.)





Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2015

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Тәхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Аида Гарифуллина.

Фото: Рөстәм Гарипова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Газинур Хафизов
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды:
10.12.2015 ел.
Заказ О-3509.
Тираж 6091.

Учредитель:
Акционерное общество «ТАТМЕДИА»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



Безнең илдә Яңа елны үткәрү кыйммәтләре ничек үзгәрә бара




«КЫШКЫ КАНИКУЛЛАРНЫ» НИЧЕК ҮТКӘРЕРГӘ ЯРАТАБЫЗ

ватандашларыбыз Яңа ел бәйрәмнәрен ничек үткәрергә планлаштыра (2015)



Яңа ел бәйрәмнәрендә ирләрнең һәм хатын-кызларның яраткан шөгыле (2014)





1699. 25 декабрь, 1 гыйнвар
Петр I «Россиядә календарь реформасы турында» указ чыгара: 25 декабрь – Раштуа, 1 гыйнвар – Яңа елның башы, барлык дәүләт учреждениеләрендә ял көне санала.



1918. 7 гыйнвар
Ленин «Россиядә Көнбатыш Европа календарен кертү турындагы Декрет»ка кул куя, Раштуа 7 гыйнварга күчерелә, «Яңа елның буржуаз бәйрәме» бетерелә.



1929. (ял көннәре булмый)
Сталин Раштуаны, чыршыны, бәйрәмнең калган башка атрибутларын да тыя. Алар «җәмгыятькә зарар китерү»гә тиңләнә.
1936. (ял көннәре булмый)
Сталин Яңа елны «балалар һәм хезмәт ияләре» бәйрәме дәрәҗәсендә кайтара. Чыршыны, башка атрибутларны да кире кайтаралар.
1947. 1 гыйнвар
СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән 1 гыйнвар бәйрәм һәм ял көне итеп игълан ителә.



1992. 1–2, 7 гыйнвар
2 гыйнвар рәсми рәвештә ял көне була, ә бер ел алдан 7 гыйнвардагы Раштуа рәсми дәүләт бәйрәме сыйфатында кире кайтарыла.



2005. 1–7 гыйнвар
Беренче тапкыр «Гомуми Яңа ел каникуллары» игълан ителә. (5 көнгә Раштуаның 2 көне өстәлә.)
2015. 1–10 гыйнвар
2005 елдан соң «Яңа ел каникуллары» берникадәр үзгәрешләр кичерә. Нәтиҗәдә, 10 көнлек ял сакланып кала.

Баш мөхәррир сүзе

Кар! Ниһаять, кар ява! Шулкадәр тансыкка әйләнер дип кем уйлаган! Безгә дә, европалыларга кебек, «ак Яңа ел»ны күрер өчен ерак сәяхәтләргә чыгып китәргә калмагае дип уйлый башлаган идем инде! Могҗиза нуры белән җемелдәшкән, ак бәхет белән өметләндереп балкыган кары булмагач, әкияти Яңа ел кәефе каян килсен?! Җир шары өстенә бердәй явып алсын иде ул – утлы яраларны каплап, кызган башларны суытып, караңгылыкны агартып... Күпне күрсәтте бу хәерсез ел! Төрек кардәшләр белән дә аралар суынды, күпләргә яшәү үрнәге сыман тоелган карт Европа да сабырлыгын, тынычлыгын җуйды – өйләреннән дә, илләреннән дә бәрәкәт китә бара. Анда шартлау, монда яну – барысы да нидер даулый, бүлешә кебек бу дөньяда. Телевизорны кабызырга куркыта, интернет кайный... Алар шаукымы безгә дә йога. Социаль челтәрләрдәге тормышны күзәтәм – күңелсез хәбәрләрне, авыр уйлануларны аралаштырып, кәефне күтәрер өчен дип, кечесе-олысы бер-берсенә хайваннар тормышыннан күренешләр юллый. Ә аларда – адәм ышанмаслык татулык, дуслык мисаллары. Эте-мәчесе, юлбарысы-кәҗәсе – бергә ашый, уйный, кочаклашып йоклый, бер-берсенә ярдәмгә ашыга...



Мәхәббәт, романтика хәяте Франциядән ике мисал – икесе дә тетрәндергеч. Берсе – шул инде, чит ил кешесе белән бала бүлешү. Аерылганда, бала әнисе белән калмасын өчен, ир хатынны сабыен артык нык – ирекне чикләрлек дәрәҗәдә яратуында гаепли. Әнинең кайнар хисләре җитди гаеп дип саналып, суд карары буенча ул – төрмәгә, бала балалар йортына җибәрелә! Әйе, ювеналь (бала хокукларын яклаучы) юстиция анда көчле – кирәгеннән дә артыграк тырыша бугай. Рәсми якланган хокук ышыгында гади кыйммәтләрнең кадере дә югала. Икенчесе – Париждагы теракт вакытында исән калган кызның тәэсирләре: таныш булмаган ир-ат аны үз гәүдәсе белән каплый, тере икәнлегең белгертмәскә куша. Аннары кыз, исәннәр арасыннан сөйгәнен эзләп бәргәләнгәндә, ялгышып, икенче кешене сөенеп кочаклап ала. Һәм бу кеше аның хәлен – алдану ачысын аңлап, кыздан елый-елый гафу үтенә. Эзләгән кешесе ул үзе булмаган өчен... Кызга бер белмәгән кешеләр ишегән ача, кибеткә барып, киемнәр алып бирә. Мәхшәр кичергән кызның икенче тетрәнүе кешеләрнең шулкадәр дә киң күңелле була белүеннән!

Әйе, кара белән ак аралаш бу тормышта: һәр яманга – бер яхшы. Яхшысы – кадерлерәк. Һәм көчлерәк тә! Кызымның бер танышы үзе теләп дөньядан китте, ә икенчесе рактан терелеп килә – могҗизага тиң җиңү! Тирә-юнебездә мондый мисаллар, җиңүләр, уңышлар юк түгелдер – без дә әйбәтен барлыйк, шулардан көч алыйк, башкаларга өмет бирик.

Бу «хәерсез» дигән елның матур, күңелле вакыйгалары да күп иде! Күтәрә алмабыз, димәдек, Татарстанны танытырлык зур-зур җыеннар, чемпионатлар үткәрдек, юбилейлар уздырдык, Әдәбият елы уңаеннан әдипләребезне зурладык. Республикабыз дәүләтчелегенең 25 еллыгына мәртәбәле килдек. Үзебез ышанган Президентыбызны сайлап куйдык. Димәк, Татарстанның киләчәге тотрыклы – ә иң мөһиме – тыныч булыр дигән өмет белән керәбез яңа елга. Иң мөһиме, иң кирәгедер ул бүгенге дөньяда – тынычлык. Һәм кешеләрнең кеше булып калуыдыр.


Дөньяны үзгәртә алмасак та, үз илебездә тату-матур яшик, игелекле, миһербанлы, мәрхәмәтле балалар, көчле шәхесләр, талантлы кешеләр үстерик – иң авыр кризисларны да төшенкелексез үтәрлек эчке запас булдырыйк. Табыннарыбыз элеккечә мул булмаса булмас, әмма ләкин күңелләребез ярлыланмасын иде. Кибет киштәләре буш чакта да китап киштәләре бушамаган халык бит без! Милли китапханәбезгә быел 150 ел тулды! Аерылмыйк китаптан, мәдәнияттән! Уңышларыбыз, горурланырлык исемнәребез бүген дә бар. Әнә, Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» романы (татар укучысына аны «Сөембикә» беренче булып ачкан иде!) «Большая книга-2015»тә җиңеп, Россиянең иң зур әдәби премиясен алды!

Эльдар Рязанов үзе китеп барды, ә Яңа елның бизәлгән чыршы кебек атрибутына әйләнгән «Ирония судьбы...» калды. Гаиләләрне, илне шундый үзгәрмәс әйберләр дә берләштерә бит. Без дә үз өлешебезне кертәбез – «Многоликая Россия» бәйгесендә журналыбыз беренче урын яулады – халкыбызның рухи, мәдәни кыйммәтләрен саклаган өчен. Бергә булсак кына шатлыкта да, кайгыда да җиңүләр дә яуланыр, авырлыклар да җиңелрәк узар.

...Карлары да явар, җылы диңгезләргә дә әле барырбыз – бер юл салып өлгергәннәре урынына икенчеләрен табарбыз. Әнә, чемодан тотып кайткан күршеләрнең җавабын: «Буадан», – дип ишеткән идем, Гоадан булып чыкты. «Бер ишек ябылганда, икенчесе ачыла», – диләр бит җан табиблары. Әйдә, бәрәкәт ишекләрен ачсын Яңа ел! Исән-имин булсак, барысын да узарбыз!

Ләйсән ЮНЫСОВА

PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





8

АИДАНЫҢ ВЕНА ВАЛЬСЫ

Э. Закирова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





14

БЕЗ БЕЛМӘГӘН ПАКЫСТАН

М. Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





22

МОРЗА КЫЗЫ СӘЛИМӘ

М. Сәфәров



18

ВАКЫТНЫ НИЧЕКЛӘР ҖИТКЕРЕРГӘ?

Г. Сафиуллина



27

СӨЕМБИКӘ АТЫМ...

Ф. Мостафина



ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



34 ПАРИЖДА ОЧРАШЫРБЫЗ
Л. Әбүдәрова

ЯШӘЕШ 



40 ЮК КИЛМӘГӘН ҖИРЛӘРЕ...
М. Авзалова



50 ӘКИЯТТӘ КУНАКТА
Л. Гәрәева

ШУЛАЙ УК: 

44 АХ УЛ ЙӨРӘК...
Р. Гатауллин

46 ИМТИХАН
М. Гаффарова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



58 МАЙМЫЛ КЫЗЫ

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

ДӨНЬЯ БУЙЛАП... ҖӘЯҮ

МИН БИТ СИНЕ ШУНДЫЙ ЯРАТАМ. Хикәя.

«ГҮЗӘЛИЯ ҖЫРЫ». Бер җыр тарихы.

МӘСКӘҮ КҮЗ ЯШЕНӘ ЫШАНАМЫ? Уйлану.

ВЕНЕРА ШАКИРОВА СЫЙЛЫЙ. Мастер-класс.









Күпләрне сокландырып, үрнәк булып, бергә озын-озак гомер кичерүче Хәдичә апа белән Сөнгат абый Төхфәтовлар гаиләсе хакында бу язмам.

64 ел бергә яшәп, «Тугрылык һәм мәхәббәт өчен» медале белән бүләкләнгән гаилә ул! Гаилә башлыгы Сөнгат абыйга аз да түгел, күп тә түгел, 100 яшь туласы иде. Тормышны бик ярата, юбилеен көтә иде. Ләкин, бер гасырны ук тутыра алмады шул, быел март аенда дөнья куйды. Хәдичә апа яшьрәк, аңа әле 91 генә.

Олы яшьтә булсалар да, берберсенә һаман да кирәк, һаман да терәк иде алар. Дөрес, олы кеше бер дә ярдәмсез генә көн күрә алмый инде. Сөнгат абый белән Хәдичә апага да балалары, оныклары булышып, көнкүрешләрен җиңеләйтеп торды. Ай-яй уңган балалар да инде! Оныклары да шундый. Кызларының ике улы сәйлән белән нәрсәләр генә үрми. Шул эшләре белән Казанда узган «Бәхетле балачак» конкурсында катнашып, бүләкләр белән кайттылар. Улларының кызлары исә чигәргә маһир. Картиналарга кадәр чигәләр. Аптырыйсы түгел, Заманында Хәдичә апа үзе дә чигү остасы булган. Аның чигешләре әле дә фатирларын бизи.

Сөнгат абый да үтә тырыш иде. «Әле сиксән яшенә кадәр көрәге кулыннан төшмәде, җир җимертеп йөрде», – дип сөйли кияүләре. Кем булуыңны беләсең килсә, күршеңнән сора, диләр. Сөнгат абый белән Хәдичә апаны күршеләре хөрмәт, ихтирам белән генә телгә ала. «Ишекләребез беркайчан бикләнмәде. Берәребез таба ашы пешерсә, барыбыз да шул күршегә җыела торган идек. Кран ватылса да, йозак ачылмаса да, торба тыгылса да, Сөнгат абыйга кердек. Беркайчан да булышмыйча калмады, караңгы чырай күрсәтмәде. Инструментларын күтәреп, ярдәмгә хәзер кереп җитәр иде», – дип сөйли ярты гасыр күрше булып яшәгән Назимә, Лиза апалар.

Сөнгат абый белән Хәдичә апа авылдашлар. Икесе дә Зәй районы Югары Ложы авылыннан. Ишле гаиләдә үскән Сөнгат абыйга тормыш йөгенә кечкенәдән җигелергә туры килгән. «Нужа чабатага тотындырды. Чабата сатып көн күрдек. Соңрак, әти белән җизнигә ияреп, урман кисәргә йөрдем», – ди иде ул.

Армия хезмәтен Ерак Көнчыгышта үтеп, шунда эшкә калган Сөнгат абый туган ягына 1940 елның кышында гына кайта. 1942 елны аны да сугышка алалар. Украина, Сталинград фронтында катнаша, Кавказ юнәлешендә була. Өч елын Германиянең Кельн шәһәрендә әсирлектә үткәрә. Ничә тапкыр үлем белән күзгә-күз очрашырга туры килә аңа! Берсендә әсирләрне, колоннага тезеп, каядыр алып китәләр. Араларында бер егет аз-маз немецча чамалый икән, каравыл торучылардан әсирләрне яндырырга алып баруларын ишетеп ала. Тиз арада бу хәбәр бөтен колоннага тарала. Бераз хәле булганнар кайсы кая йөгереп, кача башлый. Әсир киеме белән кая ерак китә алсыннар инде?! Аларның һәммәсен дә тотып, кире лагерьга алып кайталар. Лагерьда Сөнгат абый тиф эләктерә. Тамагыннан ризык үтмәс хәлгә килә. Ризык дигәне дә нәрсә генә соң инде – сыек баланда. Үлем тырнагыннан аны якташы, Тукай районы Борды авылыннан Маклаков Яков дигән егет алып кала. Ул үзенең бар булганын – яшелчә, ризыкларга алыштырып, якташына көчләп ашата. Сөнгат абый сугыштан соң аның янына рәхмәт әйтергә дә бара әле. 1945 елның маенда әсирлектән союзниклар килеп коткара аларны. Аннан соң инде СССРның фильтрацион лагерьлары... Сөнгат абый бу хакта беркайчан да сөйләмәде. Үзәкләре өзелгәндә тын гына елый иде. Сугыш турында сөйләү түгел, фильмнар да карый алмый иде ул. Бары 1988 елда гына хәрби билетына «шикләнерлек нәрсә табылмады» дигән мөһер суктылар. Соңгы елларга кадәр «әсирлектә булганым өчен балаларыма зыян килә күрмәсен» дип куркып яшәде. Әле дә йөрәге ничек чыдаган диген?! Нинди генә авырлыклар күрсә дә, тормышны бик ярата, һәр мизгелдән тәм таба иде.

Хәдичә апаның үзенә дә тормышның ачысын күп татырга туры килә. Ярославль якларында әсир немецлар белән торф чыгарганы үзәкләренә үтеп калган. «Кар эрүгә безнең эш башлана. Озынҗәен торф чыгарабыз, аннан аны киптерәбез. Көзен вагоннарга төяп озатабыз. Көненә 14 сәгать буе бил тиңентен суда тора идек. Хәзер әнә

аякларның сызлавына чыдарлык түгел», – дип сөйли ул шул көннәрне.

Сөнгат абый белән тыйнак кына туй ясап өйләнешкәч, алар Самара өлкәсенең Новокуйбышевск шәһәренә килеп төпләнәләр. Сөнгат абый төзүчеләр оешмасына эшкә урнаша. Аның турында еш кына җирле газеталарга мактап язалар. 1964 елда Түбән Кама шәһәренә күченеп кайталар. Сөнгат абый ташчы булып эшли. 1972 елда үзе төзегән бер йорттан аларга да фатир бирәләр. Тәхфәтовлар гаиләсе әлегәчә шунда яши.

Өлкәннәр, гадәттә, үзләренең үткәне турында бик тәмләп сөйләргә ярата. Ә Сөнгат абый белән Хәдичә апа киресенчә, аз сөйләшә, бернидән дә зарланмый, барысыннан да канәгать иде. Бәлки, шуның өчен дә Аллаһы Тәгалә аларга шулай тату булып бергә озын гомер кичерергә насыйп иткәндер.

Гөлсирә ВИЛДАНОВА.
Түбән Кама.

Безнең авылга ике генә «Сөембикә» килә. Аның берсен – китапханә, берсен мин алдырам.

Халыкның татарча укудан бизүенә, гасыр дәвамында татар хатын-кызының киңәшчесе дә, яклаучысы да, юатучысы да булган «Сөембикә»не яздырырга акча кызгануларына йөрәгем әрни. Югыйсә нинди кызыклы журнал бит. Бер генә тарих та уйлап чыгарылмаган, булганын язгансыз.

Үзем дә бертуган апамның аянычлы язмышы хакында бер утырып язарга кирәк дип, шактыйдан уйланып йөри идем әле.

Һәр кешенең тормышы – үзе бер китап. Без – Оренбург өлкәсе, Шарлык районы Яңа Муса авылы кешеләре. Мәктәпне тәмамлагач, апам Урта Азия якларына китеп, бухгалтер булып эшләде. Анда әтинең туганнары яши иде. Читтә озак тормады үзе, кабат Яңа Мусага кайтып, үзебезнең авыл егете Габбас җизнигә кияүгә чыкты. Баштарак кайнана-кайната белән яшәделәр, ике балалары туды. Аннан иске генә йорт алып башка чыккач, тагын дүртне алып кайттылар. Язмышның ачы сынавына юлыкканда апам җиденчесе белән йөкле иде. Җизнине йорт сүтешергә дип күршеләре өмәгә чакыра. 8 июнь булса да, шундый салкын, җилле көн иде ул. Без өй сыларга балчык изә идек, җизнинең хәле начар дип килеп әйттеләр. Өй сүткәндә башына кадаклы такта төшкән, шул кадак башын тишеп кергән. Район больницасындагы табиблар бик тырышсалар да, алып кала алмадылар. Биш айлык авыры булган апа, алты баласын кочаклап, яшьли тол калды. Торган йорты да кечкенә, бик иске иде. Авырын төшертергә киңәш бирүчесе дә булды, апам аларны тыңламады.

Сабырлыгы белән, Аллаһы Тәгалә һәм туганнар ярдәме белән тырышып-тырмашып җиде баласын да үстерде. «Коры җиргә күпме генә су сипсәң дә сеңә», – диләр. Ничек кенә ярдәм итсәләр дә, авырлыгы барыбер җитәрлек. Аягы белән бишек тирбәткәндә, кулы шәл бәйләде апамның. Шулай тырышып, яңа йорт салып керде. Авылыбызга артистларны, башкасымы килсә, гел апага кертәләр иде.

Бүгенге көндә апаның алты баласы авылда яши. Берсе генә Красноярскида төпләнде. Унсигез онықка – әби, унике турунга карт әби ул безнең. Мәктәптә узган очрашуларга апаны чакырып, балаларын яхшы кешеләр итеп ничек үстерүен сорыйлар. Ә балалары, әниләренә болай да бик авыр икәнен күреп, аның хәлен тагын да авырайтмыйк, булышыйк дип, шулай игелекле булып үскәндер.

Мин үзем дә толлык ачысы белән гомер итәм. 57 яшендә ирем Наил аммиак мичкәсенә төшеп үлде. К-700 тракторында эшли иде. Ул үлгәч, шул тракторларга карый алмас булдым. Тавышын гына ишетсәм дә, тракторы бар, Наилем генә юк, дип, җаным бәргәләнә иде. Ул хәсрәттән нишләргә белми йөргән көннәрдә бертуган абыем да үлеп китте. Ирем белән икесе бик дуслар иде. Ай авыр булды. КБУда эшли идем, хәсрәттән башым буталып, өстемә чыгар, дип, ул эшемнән киттем.

Пенсиягә чыккач, җәмәгать эшләренә чумдым. Күңелемдә яшәгән бик зур өч теләгем бар иде. Аның берсе – авылыбызда мәчет төзү, икенчесе – татарча каналлар карый алу, өченчесе – клублы булу. Аллага тапшырып, авылдашлар белән мәчет төзетү артыннан йөрергә керештек. Авыл советы рәисе бер буш йорт бирәм дигән иде дә, без риза булмадык. Мәчетнең борынгыдан килгән үз урыны бар, яңасы да шул урында төзелергә тиеш, дидек. Күрше бабай белән икәүләп авылыбызны алты кат урап чыктык. Авылдашлар, кем күпме булдыра, шуның кадәр акча бирде. Берьюлы унар мең бирүчеләр дә булды. Кем калай, кем сетка, кем башка төзү материаллары кайтартты. Мәчетне төзеп кердек. Аннары үзем Оренбургтагы мәдрәсәгә укырга кердем. Оренбург бездән 200 чакрымда, беренче елын шунда торып укыдым. Икенче елында атна саен барып йөрдем. Бүген үзем башкаларны дин гыйлеменә өйрәтәм. Икенче теләгем дә кабул булды – хәзер без дә «Татарстан–Яңа гасыр», «Мәйдан» каналларын карый алабыз. Карыйм дигән кешегә телевизорда карарлык нәрсә күп, шулай да үзеңнеке бик якын. Инде клублы да булсак... Шундый зур авылда клуб булмасын инде? Клуб булмагач, авылга концерт, театрлар да килми. Клубсыз яшәү бигрәк тә яшьләргә читен. Кайларга, кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәдек, әлегә нәтиҗәсе юк. Шушы өченче теләгемнең дә чынга ашканын күрергә язсын иде дип телим.

Рушан АБДРШИНА.
Оренбург өлкәсе,
Яңа Муса авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



АИДАНЫҢ ВЕНА ВАЛЬСЫ

Эльмира ЗАКИРОВА


ТАВЫШ ДИСӘҢ, ТАВЫШ, ЧИБӘРЛЕК ДИСӘҢ, ЧИБӘРЛЕК, ИЛАҺИЛЫК ДИСӘҢ, ИЛАҺИЛЫК!..

Сирәк очрый торган матур сопрано тавышлы, «опералы» исемгә ия талчыбыктай нәфис-нәзакәтле бу кыз үзенең музыкальлеге, таланты, затлылыгы, яшьлеге белән барысын да әсир итә.



Актанышның Байсарында, Сөн буенда – укытучылар гаиләсендә үскән Журналистлар берлеге әгъзасы Эльмира Закирова тормыш юлын туры юлдан тайпылмыйча гына уза алган сирәк кешеләрнең берсе. Ул хәтта «Хезмәт кенәгәсе»н дә «таушалдырмыйча» яшәгән. 33 ел бер урында – «Ялкын» журналында. Шуның 16 елын баш мөхәррир булып. Калган дүрт елы инде менә «Сөембикә»дә. Алай да «Хезмәт кенәгәсе»н «чуарлаган» икән ул. «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исем, «Татарстан Югары Советы Президумының Мактау грамотасы», «Казанның 1000 еллыгына» медале белән... Татар матбугатында исемнәре танылып килә торган дистәләгән талантлы яшь журналистлар – аның укучылары! Балалар редакциясендә, «Алтын каләм» фестивальләрендә Эльмира апалары аларга журналистиканы яраттыра алган. Болары – уңышлар. Ә бит әле хыяллар бар! Ирешелгәне, ирешелмәгәне. Эльмирабыз хыяллана белә. Шуңа күрә очеркларына һәрвакыт канатлы романтика килеп керә. Әкият белән чынбарлык кушылган, матур җөмләләр тезелгән язмаларын «Сөембикә»не укучылар бик ярата.
Инде беренче матур хикәяләрен укып та ләззәтләндек. Мөлаем, ягымлы, ярдәмчел, һәрчак яңалыкка омтыла торган каләмдәшебез һаман эзләнүдә: ялкынланып иҗат итә, хыяллар дулкынында тирбәлә. Еллар йөген бер дә тоймагандай, ерак сәфәрләр, йә булмаса шул ерак илләрдә яшәүче кызыклы затларның язмышларын башкалар сокланырлык җөмләләргә төреп, журнал сәхифәләренә алып керә. Әйе-әйе, кызыклы кешеләрнең кызыклы язмышлары белән рухлана, кабына белә ул. Хәер, журналистлар гаиләсендә шунсыз мөмкин дә түгелдер: ире Илдар да журналист бит! Өйләре дә журналистика утравы: командировкалар, эфир вакыты, төн утырып языласы мәкаләләр... Барган саен Мәскәүдән журналистикага кагылышлы китаплар җыеп кайту... Андагы журналистлар белән дустанә аралашулар... Аңа бу татлы иҗат халәтеннән әле бик озак төм табарга язсын иде.
Тату гаиләдә – тәүфыйклы улы, исән-сау әнисе... Димәк, түгәрәк датасын түгәрәк бәхет белән каршылый Эльмирабыз! Озын, бәрәкәтле гомер синә, каләмдәш!

«Сөембикә»леләр.



Аиданы кайда, ничек күргәнемне, кайчан тыңлаганымны искә төшереп утырам. «Марафон-15» телевизион тапшыруында Эдита Пьеханың «Наш сосед» җырын җырлап тамашачыны шаккаттырган 5 яшьлек Казан кызы Аида Гарифуллинаны хәтерләмәскә соң!.. 11 яшендә үк вокал буенча профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнә башлый. Бөтенроссия һәм Халыкара конкурсларда катнаша. 2001 елда Мәскәүдә П. Чайковский исемендәге Зур концерт залында камера оркестрына кушылып чыгыш ясый. 13 яшьтә Ф. Шаляпин исемендәге Фонд стипендиаты була... Концертлар, премияләр, Гран-прилар, исемнәр, алкышлар, чәчәкләр, җиңүләр... Әгәр режиссер булсам, мин Татарстан Республикасының атказанган артисты, опера җырчысы Аида Гарифуллина турында фильм төшерер идем.

Балачагында үзен Дон Кихот итеп күз алдына китергән, хәтта песиен дә Дульсинея дип атаган хыялый, мажаралар, китаплар ярата торган үсмер кыз өчен дөнья татарча, русча, инглизчә, французча, итальянча җырлар аша ачыла бара. Әнә ул тарихи романнар укый. Романтика, хыял, хисләрне бергә кушып шигырьләр яза; җыр-музыкадан аерылмый гына дизайн белән мавыга: бүлмәсен беркемнекенә охшамаганча итеп үзгәртеп куя!

2005 елда ул Казан мэры гранты белән Германиягә Нюрнберг Югары музыка мәктәбенә укырга китә! Алманча дәресләр, алманча сөйләшүләр. Әмма күңеле һаман дөньяның музыка башкаласына – Венага тартыла. Ике ел эчендә мөстәкыйльлеккә, үзе өчен үзе җавап бирергә өйрәнгән тәвәккәл кыз поездга утыра да... Венага китеп бара! Белькануто буенча билгеле музыка профессоры Клаудиа Висканы эзләп таба! Имтиханнар, кабул ителү... Инде өйдәгеләрдән сөенче алсаң да ярый!

Әти-әнисе кызларын музыка башкаласы Венада укыту турында хыяллана иде бит.

Аидага ияреп, без дә Германиядән Австриягә – әкияти Венага юл алабыз. Кечкенә Моцарт чыгыш ясаган концерт заллары, күңелле студент еллары... Вакыйгалар Казан Универсиадасына күчә. Аиданың вәкаләте зур анда: ул – Универсиада илчесе! Игорь Крутой аның тавыш үзенчәлекләрен истә тотып, махсус җыр яза! «Птица белая»! Хәтерләсәгез, төсле стразлар белән бизәлгән сирень төсендәге озын күлмәге Аиданы тагын да серлерәк күрсәткән иде. Әйе-әйе, юлда кайдадыр югалып, җырчыны бераз хафага салган күлмәк ул... (Күлмәкне атаклы Ливия дизайнеры Зухар Мурад Аида өчен махсус уйлап тапкан!) Бу вакыйгадан кызык мажара ясап булыр иде фильмда!.. Классик вокал белән заманча поп-музыка бергә кушылган әлеге җыр да, үзе дә никадәр күтәренке рух өстәде безгә! Күңелгә уелып калган тагын бер күренеш: Универсиада кунакларына Аида татарча беренче альбомын бүләк итә. «Кышкы романс», «Җидегән чишмә», «Сөембикә», «Фазыл чишмәсе»... Тавышы көмеш сыман чыңлап челтери...

...Әйдә, хәзер үзебезне Веронада – XX Халыкара «Опералия» вокал конкурсында дип хис итик. Дөньяның дистәләгән иленнән 600 дән артык җырчы килгән... Һәм



Фото: Pavel Antonov (New York)

PRESSA.RU





шуларның берсе – безнең Аида! Сылу, итагатьле... Конкурсантларны башта видеоязмалардан сайлыйлар. Соклангыч сопраносы, искиткеч башкару осталыгы, мөлаемлыгы белән ул таләпчән жюрины таң калдыра. Аида Гарифуллина лауреат исемен генә түгел, Европаның күп опера театрларына чакыру да алып кайта. Венага, Монте-Карлога, Валенсиягә...

Аида әле Италиянең Арена ди Верона сәхнәсендә, әле Лондондагы Җәйге олимпиадада, әле Петербургтагы Мариинский театрында...

«Өченче урынны игълан иткәндә тәнем чымырдап китте. Ул арада икенче урынны әйтәләр. Мин дә бит шулкадәр тырыштым, әзерләндем дип уйлап та бетерә алмадым – исем-фамилиям яңгырый! Беренче урын! Телсез калдым. Һич ышана алмыйм. Камерага карап елмайгандай итәм, ләкин ул әллә ничек кенә килеп чыга!..» – дип искә төшерә Аида ул минутларны.

Домингоның Казанга килүе – үзе бер вакыйга! Аида чакыруы буенча да бит әле! Әнә Аида гид ролендә олы кунакка Колшәриф мәчетен, Благовещение соборын күрсәтеп йөри. Кайчандыр Шаляпин җырлаган шәһәр Ратушасына килеп кергәч, яшь җырчы да, маэстро үзе дә шулкадәр тәэсирләнә – килешкәндәй, икесе берьюлы җырлап җибәрәләр. Соңрак матбугат конференциясендә Пласидо Доминго опера йолдызына югары бәя бирә: «Якташыгыз белән горурлана аласыз: Аида Гарифуллина Казанны бөтен дөньяга танытачак әле!» – ди ул. Ә кичен җиде меңнән артык тамашачы Аида Гарифуллина һәм Пласидо Доминго концертында рәхәт минутлар кичерә.



Санкт-Петербург. Мариинский театрында «Война и мир» операсының премьерасы. Һәм, әлбәттә, төп ария – Аиданыкы! Газеталарда: «Наташа Ростова Казанныкы», – дип язалар...

Алессандро Сафина, Майкл Болтон һәм Андреа Бочелли, Тимати һәм Билан, Хворостовский һәм Киркоров... Аида һәркайсы белән дуэт җырлый.

Бал дигәннән... Аида Гарифуллина балына да күз салабызмы? 2015 ел, февраль. Венада мәшһүр опера балы! Ачылу тантанасына Аида Гарифуллинаны чакырганнар! Вена консерваториясенең кичәге студенты әнә нинди очышта!.. Зәвык белән бизәлгән зал, чәчәкләр диңгезе, хатын-кызлар – затлы бәйрәм күлмәкләреннән, ирләр – фрактан... Аксөякләргә хас зәвык, тәртип, матурлык. Һәр тарафта музыка, музыка! Кавалерлар дамаларны биергә чакыра. Вальска бөтереләләр. XIX гасыр башларында Вена конгрессы вакытында Европа аристократиясе Наполеонны җиңүне шулай бәйрәм итә торган булган... Конферансьеның «Татарстан», «Казан» дигән сүзләре... һәм «Аида ГарифуллИна» дип, басымны үзләренчә соңгы иҗеккә төшереп, безнең Аиданы чакыралар! Менә ул! Үзе көләч, үзе сөйкемле... Яшькелт күлмәге, җилкәсенә таратып салган коңгырт чәчләре – бар да матур, килешә. Чын принцесса! Хыялында йөрткән образны менә кайчан чынга ашырып була икән. Джульетта вальсы яңгырый! Бары Аидада гына шундый тавыш – йомшак һәм көчле, нәфис һәм җылы – җаннарны иркәли торган... Күпләр аны тавышыннан ук танып ала! Күр, искиткеч зәвыгы, стильне тоемлавы, хисләрен тыйнак һәм тыенкы белдерә алуы белән залны ничек сихерли. Алкышлар, алкышлар, алкышлар...

...2015 елның көзе. Рәхмәт сиңа, Вена! Син тагын Аиданы күтәрдең! Аидага син тагын сюрприз әзерләгәнсең! Әнә ул бүләк тапшыру тантанасына ашыга! Хатын-кызларның бик популяр «Мадонна» журналы,





үз укучылары фикереннән чыгып, Аиданы Австриянең «Ел хатын-кызы» дип таныта. Вена операсында бер генә ел эшләсә дә, биш спектакльдә төп партияләрне җырлаган. Вена тамашачысы ихлас, ул рәхмәтле була белә: кемнедер яратып кабул итә икән, димәк, бу инде озакка.

Миңа калса, Аидага исемне дә хәтта алдан белеп куйганнар. Гарәпчәдән бүләк мәгънәсендә килеп кергән. Бу исем тормышта һәрчак булыша, бер-бер артлы уңыш китерә, диләр. Табигать Аидаларны матур йөз-кыяфәтле, талантлы итеп яраткан. Алар музыкаль, иҗади, шигъри... Юк, Аиданың әле без белмәгән тагын әллә нинди яклары, сыйфатлары бар. Алар аралашканда, интервьюлар биргәндә ялтырап ачылып китә дә Аида турындагы фильмыбызны тагын да баета, тулыландыра...

МИН МУЗЫКАЛЬ ГАИЛӘДӘ ҮСТЕМ. Җыр карьерам белән, һичшиксез, әнием Ләйлә Илдар кызына бурычлымын. Ул белгечлеге буенча хор дирижеры, Казан консерваториясен тәмамлаган. Мәктәптә музыка укыткан, Татарстан Дәүләт камера хорын оештыручыларның берсе булган. Вокал буенча минем беренче укытучым да, репертуар сайлаучым да, имидж ясаучым да – ул, әнием! Без аның белән бертуктаусыз төрле конкурсларга, хәйрия концертларына чыгып чаба идек. «Созвездие-Йолдызлык», «Татарстанның талантлы балалары» фестивальләре, «Утренняя звезда», «Зажги свою звезду!» конкурслары искә төшә... Бүгенге көндә әнием – «София Гобәйдуллинаның заманча музыка үзәге» директоры. Әтием Эмиль Дамир улы – эшмәкәр. Ландшафт дизайны белән шөгыльләнә торган үз фирмасы бар. Дизайнерлык сәләтем әтидән күчкән. Энем Рэм – ресторатор.

ИКЕ ЯКТАН ДА ӘБИ-БАБАЛАРЫМ — ЗЫЯЛЫ КЕШЕЛӘР. Табиблар да, фән кешеләре дә, җырчылар да бар. Безнең өйдә гел татарча җырлыйлар иде. Әбием дә, дәү әбием дә... Фәридә әбием хәзер дә озын көйләрне матур җырлый. Биш яшемдә ул миңа «Җидегән чишмә»не өйрәтте. Эстетик зәвыгы кайда да сизелә. Кибеткә кергәч үк затлы савыт-сабаны, матур тукымаларны шундук танып ала! Тамырларыбыз – Казанда. Бабабыз Хәйрулла Биккиниев приказчик булган. Әбием байларга энҗе-сәйләннәрдән ак калфаклар чиккән.

«Кыйммәтле асылташ, үзенчәлекле тавышка ия якты йолдыз» дип язалар Австрия журналистлары Аида турында.

ТАТАР МУЗЫКАСЫ ИСКИТКЕЧ МАТУР! Европадагы укытучыларым да шулай ди. Алар безнең көйләрдәге мелизмнарга һәм гармониягә соклана. Татар җырларын Европада да яңгыратып була дип уйлыйм. Халкыбызның менталитетын җыр аша бирәсем килә. Кызганыч, Пласидо Доминго белән бер сәхнәдән чыгыш ясаганда концерт программасына татарча җыр әзерләргә өлгерә алмадым. Хәзер үкенеп бетә алмыйм шуңа. Репертуарыма татар җырларын да кертергә телим.

ТОРМЫШ МИҢА БҮЛӘК ӘЗЕРЛӘП КУЙГАН ДИЯРСЕҢ! Юлымда гел уңышлар, күпсанлы бәхетле очраклар, җиңүләр... Ләкин бу читтән генә шулай тоела. Чынлыкта, алар артында бетмәс-төкәнмәс дулкынланулар, икеләнүләр, сораулар – иҗат газапларым ята. Матур күренеп, шәп җырласаң, музыка үзе үк теләсә кемне эретә ала дип уйлый идем. Хәзер мин язмыш бүләген һәр көн эшем, сәнгатем белән акларга тиешлегемне аңлыйм.

ДУСЛАРЫМНЫҢ ДУСЛАРЫ МИНЕМ ДӘ ДУСЛАР. Казанда шәһәр көнендә Дима Билан минем җырлаганны тыңлап, тавышымны ошаткан. Дуслашып киттек. Соңрак ул мине бер проектта үзе белән дуэт җырларга чакырды.



PRESSA.RU






■ «Опералия-2013»тә Пласидо Доминго Беренче премияне тапшыра.
■ «Любовный напиток»та (Доницетти) – Адина.
■ «Богема»да (Пуччини) – Мюзетта.
■ «Свадьба Фигаро»да (Моцарт) – Сюзанна.

Шунда Филипп Киркоров белән аралаштык. Ул исә Игорь Крутой белән таныштырды. Яңа елда «Голубой огонек»ка, «Песня года»га чакырдылар да, Тимати белән танышып киттек. «Евровидение»дә җырлар өчен җыр язарга тәкъдим иттем аңа. Тиматиның Америкада танышлары бар. Танылган рэпперлар белән клиплар төшердек. Рэп белән операны бергә куштык. Безнең чыгышны «Евровидение»дә күргәнсездер инде.

● **ВАЛЕРИЙ ГЕРГИЕВ БЕЛӘН ОЧРАШТЫРГАН ӨЧЕН ЯЗМЫШЫМА МЕҢ РӘХМӘТЛЕ!** Мариинский театрына ул чакырды мине! Театр белән бүген дә тыгыз элемтәдә яшим.

Аиданың Джульеттасын атаклы тенор Пласидо Доминго иң югары балл белән бәяли!



● **КИЛӘЧӘККӘ ПЛАННАР ЗУР.** 2016 елда Парижда – «Снегурочка», Валенсиядә – «Травиата», Венада Австрия композиторы Йоһанн Додерерның «Фатима»сында җырлаячакмын. Прагада, Калифорниядә, Версальдә концертларым булачак.

● **ПЛАСИДО ДОМИНГО – ИСКИТКЕЧ КЕШЕ.** Аңардан һәрчак җылылык, аталарча кайгыту тоям. Доминго белән бергә җырлау теләсә кайсы җырчы өчен бәхеттер. Тәкәбберлек, һавалылыкның әсәре дә юк аңарда. Ул әле сине үз югарылыгына күтәрергә мөмкин. Киләчәккә аның белән уртак проектларыбыз бар. 2017 елда без маэстро белән Вердиның «Травиата»сында җырлаячакбыз.

● **«БАЙЛЫК КЫЧКЫРА, ЗАТЛЫЛЫК ПЫШЫЛДЫЙ».** Нәзакәтлелеккә омтылган кызлар колагына бу сүзләр. Тышкы кыяфәткә игътибар бирәм. Бу – тамашачыга зур хөрмәт дигән сүз. Эчке һәм тышкы образ сәхнәдә бербөтен тәшкил итә. Киемдәге юк кына кимчелек тә музыкадагы матурлыкны җиткерергә комачаулый. Шуңа күрә мин концерт йә бәйрәм күлмәген бик озаклап сайлыйм. Көндәлек тормышта гади күренәмдер: макияжлар кулланмыйм. Мода яратам. Бер киемне икенчесе белән яраштыру ошый үземә. Миңа калса, танылган йә, киресенчә, яңа юнәлештә эшләүче яшь дизайнерларның бер-ике кыйммәтле киемен сатып алып, булган киемнәрең белән аралаштырсаң, кабатланмас образың булачак.

● **ТАБИГЫЙ ОЯЛЧАНЛЫГЫМНЫ ҮЗГӘРТӘ АЛСАМ ИКӘН!** Тирән кичерешләремне башкаларга күрсәтми яшерә алам. Кайберәүләр моны тәкәбберлек дип кабул итә. Ләкин бу алай түгел. Тамашачы белән булган һәр очрашу кадерле миңа.

● **БУШ ВАКЫТЫМ ЮК ДИЯРЛЕК.** Күп вакытым репетицияләрдә уза. Табигатьтә булырга, яхшы иске киноларны карарга яратам. Аеруча Одри Хепберн уйнавы ошый. Опера җырчылары турында китаплар җыям. Китап уку, фильмнар карау – күп очракта самолетта гына эләгә.

● **ЯҢА ЕЛ – ИҢ ЯРАТКАН БӘЙРӘМЕМ!** Мин гел принцесса булып киенә идем! Әнием, ак якалар куеп, пан-бәрхеттән миңа принцесса күлмәге тегә. Мине нәни принцесса дип йөртәләр. Шул әкияти халәтне, балачак яктысын гомер буена саклап каласы иде! Хыялларга ышанам мин. Ә «Сөембикә» укучылары тормышка, шигърияткә, мәхәббәткә табынып яшәсеннәр!!!

P. S. Шушы көннәрдә Мәскәүдә Беренче Россия милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасы узды. Вена операсы солисты, Татарстан Республикасының атказанган артисты Аида Гарифуллина «Опера җырын иң яхшы башкаручы» титулына ия булды! Котлыйбыз!

ҖӘМГЫЯТЬ



■ **Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Финляндиядә татар җәмәгатьчелеге белән очрашты. Чарада җәмәгатьчелекнең йөздән артык вәкиле катнашты. Әңгәмә татар телендә барды. Финляндиядә меңгә якын татар яши, күпчелеге — Хельсинкида; Тампере, Турку, Котка шәһәрләрендә дә милләттәшләребезне очратырга мөмкин. Рөстәм Миңнеханов Финляндия татарларының туган телләрен, мәдәниятләрен, гореф-гадәтләрен саклап калуларын уңай үрнәк дип бәяләде. Җәмгыятьнең татар теле укытучысы, журналыбызның «Сөембикә беләзеге» иясе Хәмидә Чайдамга «Рәхмәт сүзе» тапшырды.**

■ **Казанда «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы узды. Анда Россия Федерациясенең 52 төбәгеннән, 23 ерак һәм якын чит илләрдән 600 гә якын делегат килде. Татар эшмәкәрләре, эре ширкәтләр җитәкчеләре, татар иҗтимагый оешмалары вәкилләре чыгыш ясап, эш тәҗрибәләре белән уртаклашты. Делегатларга Татарстанның икътисадый, инвестицион куәтен күрсәтүгә аерым игътибар бирелде. Форумның пленар утырышы эшендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты, форум кунакларына Татарстанга килүләре өчен рәхмәт белдерде.**

МӘДӘНИЯТ

■ Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай клубында, юбилейлары уңаеннан, халык язучылары, Г. Тукай исемендәге премия лауреатлары Гариф Ахуновны һәм Мөхәммәт Мәһдиевне, шагыйрь Хәсән Туфанны искә алу кичәләре үтте. Алар җырлар, әдәби әсәрләрдән өзекләр, замандашларының җылы хатирәләре белән үрелеп барды.

■ Татарстанның халык язучысы, күренекле җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның туган йорты, яңартылып, ишекләрен кабат ачты. Бу изге эшне «Таттелеком» ҖЧҖ җиренә җиткереп башкарып чыкты. Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылындагы тарихи әһәмияткә ия әлеге нигезгә бер төркем язучылар кайтып, Туфан Миңнуллинның йорт-музеенда булдылар, язучының якташлары белән очраштылар.



■ «Сөембикә» журналы ярдәмендә уздырыла торган Милли кием дизайнерларының VI Халыкара «INTERNATIONAL FASHION-2015» конкурсының җиңүчеләре билгеле булды. «Профессионал» номинациясендә беренче урынга Казан милли фәнни технологик университетыннан Лилия Хәбибрахманова лаек булды. Ул «Камзол» коллекциясен тәкъдим иткән иде. Гран-при исә Чиләбе шәһәреннән Лилия Васильевага тапшырылды. Аның «Иркле кош очышы» коллекциясе арада иң лаеклысы дип табылды.

КОТЛЫЙБЫЗ



■ **Казанда хатын-кыз, ана һәм гаилә матурлыгы республика конкурсы «Нечкәбил» XI финалы узды. Татарстанның төрле районнарыннан килгән 12 конкурсант төрле номинацияләрдә җиңү яулады. Чаллыдан күп балалы Дилүзә Хәбиева «Нечкәбил-2015» титулына лаек булды. Ул «Моңлы нечкәбил» номинациясендә дә җиңү яулады. Дилүзәгә ире Руслан, балалары Эрнест, Искәндәр һәм Ясминә көч биреп торды.**

МӘГАРИФ

■ Иннополис университеты каршында сәләтле балалар өчен мәгълүмати технологияләр лицее эшли башлаячак. Интеллектуаль яктан сәләтле, математика, информатика, физикадан көчле һәм үзенең киләчәген мәгълүмати технологияләр белән бәйләргә теләгән егет-кызлар өчен лицей зур мөмкинлекләр ача. Иннополис университеты каршындагы мәгълүмати технологияләр лицее Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов инициативасы белән булдырылган.

■ 2015 ел Гаяз Исхакый мирасының Ватанга кайтуы белән истә калачак. XX гасыр татар классик әдәбиятының күренекле язучысы Гаяз Исхакыйның 15 томлык әсәрләр җыентыгы басылып чыкты. Әлеге 15 томлык китаплар – олпат әдипнең шәхси хатлары, автобиографик язмалары, тормышына һәм иҗатына караган документлар, аның турында истәлекләр тупланган тулы басма. Шул уңайдан КФУның социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты, «Татмедиа» АҖ, Г. Исхакый истәлегенә багышлап «Төрки телле мәгълүмати мәйданда татар журналистикасының роле һәм урыны» дигән темага фәнни-гамәли конференция уздырды.

СПОРТ

■ **Казанда билбау көрәше буенча XIII Дөнья чемпионаты тәмамланды. Тарихта беренче тапкыр ул «көрәш» IV Дөнья чемпионаты белән бергә үтте. 20 илдән 200 дән артык атлет көч сынашты. Арада Дания, Румыния, Эстония, Латвия, Греция, Пакыстан спортчылары бар иде. Барлык үлчәү категорияләрендә алтын яулап, Россия җыелма командасы абсолют җиңүче булды.**

■ **Казанда «Татарстан өметләре» спорт акробатикасы буенча республика чемпионаты ачылды.**



PRESSA.RU











Фото интернеттан алынды

БЕЗ БЕЛМӘГӘН ПАКЫСТАН

Ниһаять, Азия илләренең Омбудсманнар Ассоциациясе директорлар советында – үзебезнең кеше! Җиләк-җимешле, гөл-чәчәкле җылы яклардан кайтып төшүенә дә берничә көн генә әле аның. Эшлекле очрашулар, һәр илне борчыган уртак проблемалар турында җитди сөйләшүләрдән бушаган арада, аз гына вакыт табып, күзнең бер чите белән генә булса да серле дә, гаҗәеп гүзәл дә тоелган шәһәрне күреп калырга, аның яшеллеккә күмелгән чиста урамнары буйлап йөрергә кем генә теләмәс икән?!

– Кызганычка каршы, вакыт бик аз иде. Әмма анда алган тәэсирләр... – ди ул, тормышындагы, хәер, аның гына түгел, республика тормышында мөһим урын алган вакыйганы күз алдыннан кичерә башлап.

Азия илләре омбудсманнары очрашуы

Пакистан башкаласы Исламабадта Омбудсманнарның Азия Ассоциациясе (аңа 19 илдән 34 әгъза керә) олы җыены булып үтте. Бу – Азия илләренең кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләре катнашында булган очрашуларның ундүртенчесе. Дөньяның кеше хокуклары сагына баскан мәртәбәле мөселманнарын үз канаты астына җыйган әлеге берләшмә 1996 елның 16 апрелендә оешкан иде. Ул, кыскасы, Азия омбудсманнарының хөкүмәтнеке дә, сәяси дә булмаган, бәйсез һәм профессиональ форумы. Аның максаты барлыкка килүенең беренче көннәреннән үк ачык һәм аңлаешлы итеп куелды: омбудсманнар тәкъдим иткән концепцияләрне алга чыгару һәм тагын да үстерү; һөнәри осталыкны чарлау; әлеге тармактагы фәнни тикшеренүләрне хуплау; омбудсманнар арасында тәҗрибә уртаклашуны тәэмин итү.

Җыен ике көн дәвам итте. Шул вакыт эчендә алар дүрт пленар утырыш үткәрергә дә, коррупциягә каршы көрәштә, дәүләтчелек идарәсенең стандартларын үстерүдә омбудсманнар роле темасына чыгышлар тыңларга да, Ассоциациянең директорлар шурасына сайлаулар уздырырга да өлгерделәр. Шулай ук яшерен тавыш бирү юлы белән ун кандидатның бишесе яңабаштан Ассоциациянең директорлар шурасы әгъзасы итеп сайланды. Алар арасында Татарстанда кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Харис кызы Сабурская да бар.

«Безне беләләр, безнең белән кызыксыналар...»

– Шулай итеп, Сәрия Харисовна, Сез Казанга яңа статуста, яңа вәкаләтләр белән кайтып төштегез...

– Үзем өчен дә көтелмәгән яңалык булды ул. Казанны, Татарстанны чит илләрдә бүген беләләр һәм республикада алып барылган эшләргә сокланып, гаҗәпләнеп карыйлар. Сизелеп тора: мөнәсәбәт икенче. «Мин Татарстаннан», – дисәм, кочаклап ук алалар. Якын итәләр. Анда һәр омбудсманга сүз бирелде. Мин дә сөйләдем: Татарстан турында, республикадагы үсеш-яңалыклар турында... Шул исәптән аның Россия регионнары арасында икътисадый яктан иң алдынгы булуын, Конституциябездә кешенең, аның хокукларының иң зур кыйммәт булып танылуын, Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның быелгы сайлауларда 94 процент тавыш җыюын һәм моның һич кенә дә очраклы хәл булмавын, чөнки Президентның эшчәнлеге – халык мәнфәгатьләренә юнәлтелгәнлеген, һәм республикада, Россия Федерациясендә бердәнбер документ булган «2014–2018 елларга кеше хокуклары буенча стратегия» кабул ителүен дә әйттем. Чыгышымны яратып тыңладылар. Ахырдан гөрләтеп кул чаптылар. Соңыннан, утырыш тәмамланганнан соң да, яныма килеп ихластан котладылар. Шул чагында горурлану хисләре кичердем: бу бит миңа гына түгел, Россиягә, Татарстанга мөнәсәбәт тә... Нәтиҗәсен күрәсез: мин – Директорлар советында!



■ Пакыстан омбудсманнары арасында да хатын-кызлар бар иде. Алар бик мөлаем, матур итеп сөйләшә, үзенә карата белә. Фотода: Пакыстан Федераль Омбудсманы Секретариатының хатын-кызларны хезмәт урынындагы әдәпсез бәйләнүләрдән яклау мәсьәләләре буенча киңәшчесе Neelam S.Ali белән.

Киемеңә карап каршылыйлар

– Белүемчә, Сезнең мондый зур җыеннарга беренче генә баруыгыз түгел?

– Без – Азия илләренең Омбудсманнар Ассоциациясенә Россия Федерациясе исеменнән кертелгән бердәнбер регион. Шуңа ике елга бер мәртәбә үткәрелә торган мондый очрашуларда, кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил буларак, без һичшиксез катнашырга тиеш. Бу форумга 2011 елдан бирле өченче мәртәбә баруым. Аның беренчесе – биредә эшли башлауга ук – Филиппинда булды. Икенчесе – Иранда. Һәм менә монысы – өченчесе.

Ел әйләнә мандариннар үскән бу илдә хәтта хатын-кызларны кайгыртучы министрлык та бар.

Иран да, Пакыстан да – ислам дине тота торган дәүләтләр. Тик аның беренчесе – бик дини, ә икенчесе – дини дәүләт булса да, дин тотуларын күзгә бәреп күрсәтми. Ничектер башкачарак, дип әйтимме. Иранга баруымны хәтерлим. Аэропортына төшеп кундык та, очкычтан төшеп барабыз. Безне каршыларга килгән вәкилләрнең берсе: «Мадам, бездә болай тән күрсәтеп йөрмиләр. Өстегезне алыштырыгыз», – дип, мине шок хәлендә калдырды. Мин үземчә яңа костюмнан, башымда – яулык... Бик тырышкан идем югыйсә. Моны күрүче дә булмады. Аларның үз законы. Чалбар киеп, өстемә кардиган ябынып, әйткәнне тәки үтәргә туры килде. Ирләр хатын-кыз белән кул биреп исәнләшмиләр анда. Гомумән, безнең затка мөнәсәбәтләре бик тыйнак аларның. Иранга очканда самолеттагы пассажирларның яртысы диярлек хатын-кыз иде. Карыйм, берсенең дә башында яулык юк. Мин генә

PRESSA.RU



■ Пакыстанда хатын-кызга эшләргә ярамый торган бердәнбер урын – ресторан. Анда гел ирләр генә. Ә калган җирдә, әйтик, армия, полиция, хәрби авиациядә дә хатын-кызлар бар. Айшә Фарук, мәсәлән, теләсә нинди, хәтта атом-төш коралы кулланылган очракта да, хәрби хәрәкәтләрдә катнаша алырлык итеп әзерләнгән беренче очучы хатын-кыз. Пакыстандагы егермеләп хатын-кыз пилотның дүртесе илнең иң дәрәҗәле йөз хатын-кызы исемлегенә дә кертелгән.

яулык бөркәнгән. Килеп төшүебез булды, барысы да, сүз берләшкәндәй, җилкәләрендәге яулыкларын алып, бөркәнеп тә куйдылар. Кызык булып китте. Әмма ничек кенә булмасын, гаилә, хатын, балалар өчен ир-заты мөкиббән китә. Биредә гаилә кыйммәтләре күз карасыдай саклана.

«Республикадагы үзгәрешләрне үз күзебез белән күрәсебез килә», – диде олы җыен кунаклары, Татарстанда кеше хокуклары яклау буенча вәкаләтле вәкилнең әледән-әле алкышлар белән бүленгән чыгышыннан соң.

Пакыстанда да шулай. Гаиләләре белән бергәләшеп, рестораннарга, паркларга йөриләр. Бергәләшеп ял итәләр. Бала кадерен беләләр, бала хәтерен саклыйлар. Беркайда – әйтик, шул ук без йөргән ресторанда да хәмер күрмәссең. Андый нәрсә, гомумән, юк. «Аерылышулар бармы?» – дисез. Ирләр эчмәгәч, хатыны һәм балалары белән бергәләшеп ял иткәч, нинди аерылышулар турында сөйләргә мөмкин. Бездә генә ул мәҗлес җыйдыңмы, өстәлгә, иң кадерле кунак булып, аракы менеп кунаклый. Ә инде кайда аракы, шунда тавыш, шунда таркалу-җимерелү...

Пакыстанга барыр алдыннан, махсус, кибеткә барып, үземә ике милли күлмәк сатып алдым. Президент Мамнун Хөсәен безне – омбудсманнарны үзенең Резиденциясенә чакырды. Кунаклар өчен әзерләнгән өстәлдә чәй, сок, су, каһвә ише эчемлекләр иде. Президент безнең һәркайсыбыз белән кул биреп исәнләште. «Татарстаннан...» дигәч, янымда озаккарак тукталды, кызыксындырган сорауларын бирде. Янә бер башка үсеп киткәндәй булдым. Бу илдә хатын-кыз шарфын муенга салып кына, бөркәнмичә дә йөри. Алай гаеп итүчене, кисәтүчене күрмәдек. Ризыклары авызны яндыра. Төрле инфекция, йогышлы авырулардан саклану өчен ризыкка көчле тәмләткечләр салалар. Ә болай... кая карама – әфлисун, мандарин... Җиләк-җимеш белән бөтен дөнья тулган. Исламабадның архитектурасы, йортларының тышкы күренеше бик гади дип әйтер идем. Ак кирпечтән ясалган тартмалар шикелле. Ләкин эченә керсәң, хәйран калып торасың мәгәр.

Шәһәрне хәрбиләр саклый

– ИГИЛ пакистанлыларга да көн күрсәтмидер. Теракт, кан-коештан ничек сакла624налар? – дип кызыксына башлыйм, әңгәмәне сәяси юнәлешкә борып.

– Башка шәһәрләрендә ничектер, белмим, ә менә Исламабадта хәрби режим кертелгән. Һәркайда – урам уртасындамы, борылыштамы – хәрбиләр басып тора. Шуңа күңел тыныч булды. Вакыт табып, кибетләренә дә кереп чыктык. Шул сувенирлар, шарфлар, яулыклар, бизәнү әйберләре... Алар бит, нигездә, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнә. Ил җитәкчелеге хатын-кызны эшкә урнаштыру мәсьәләләренә дә җитди игътибар бирә. Алар хәзер гел өйдә генә утырырга риза түгел.

Шунда бер ханым белән таныштым. Күз ала алмаслык чибәр үзе. Өч балалары бар. Өчесе дә үз тормышлары белән... аерым яшиләр. «Без инде ирем белән кайларда гына булмадык. Соңгы вакытта Һиндстанда, аннары Америкада булып кайттык, – дип сөйләп торды. – Сезгә – Татарстанга да килеп чыгарбыз әле», – диде. «Килегез, көтәбез!» – дидем.

– Ә ничек аралаштыгыз?

– Инглиз, бары инглиз телендә. Барысы да шул телдә сөйләшә. Мин үзем дә әзрәк сукалыйм. Янымда тәрҗемәчем дә бар иде. Кайчак күз карашы белән дә аңлашып була бит ул. Без шул ике көн эчендә нык дуслашырга өлгердек, якын туганнар кебек аерылыштык.

Кайтырга чыкканда, очкычка утырышып алгач, берничә минутка тын калып, юл догасы тыңладык. Аларда шундый әйбәт гадәт яши икән. Дога ишеткәч, тынычланып китәсең. Илеңә исән-имин кайтып җитәчәгеңә шигең калмый.

Азия илләренең Омбудсманнар Ассоциациясе җыены ике елга бер мәртәбә уздырыла. Киләсе очрашу 2017 елны – Көньяк Кореяда булачак икән.

Анда безнең вәкил – Ассоциациянең Директорлар советы әгъзасы буларак, яңа вәкаләтләре белән катнашачак инде алайса. Татарстанны дөньяга танытуның – әңгәмәдәшем әйтмешли, җете бер үрнәге бу.

Әңгәмәдәш – Мәдинә АВЗАЛОВА.













НӘРСӘ ҖИТӘ АНА БУЛУГА?!

Һәр минут саен Россиядә өч аборт ясала.

...Хатын-кызларның 30 процентка якыны баласын ире кушканга төшерә.

...Улларын әниләр ялгыз гына тәрбияләгән гаиләләрдә, малайлар ир-ат белән аралашу, аңардан нәрсәгәдер өйрәнү, үрнәк алу тәҗрибәсеннән мәхрүм. Моның аяныч нәтиҗәләре күз алдында... Бүгенге ир-атларның күбесе тормыш авырлыклары белән очрашырга әзер түгел, ата буларак үз вазыйфаларын үтәми, дөресрәге, бу хакта алар белми дә.

...Санкт-Петербург шәһәрендә кавышкан парларның – 45 проценты, Ленинград өлкәсендәгеләрнең 79 (!) проценты аерылыша.

«Ана изгелеге» Бөтенроссия программасының Казанда узган IV форумында һәркемне сискәндереп куйган, уйланырга мәҗбүр иткән мондый фикерләр, саннар шактый яңгырады. Быелгы форум «Күпгасырлык гаилә традицияләре – Россия киләчәгенең нигезе» дигән темага багышланган иде. Анда Россиянең 50 төбәгеннән, Кытай, Япония, Сербия, Украина, Белоруссия, Молдова, Грузия кебек илләрдән иҗтимагый оешмалар, федераль һәм төбәкара хакимият органнары җитәкчеләре, галимнәр, журналистлар – барлыгы 700 гә якын кеше катнашты.

«Гаилә – дәүләтнең нигезе, ул мәдәниятебезне, телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калу урыны, – диде Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үзенең сәламләү сүзендә. – Гаиләләр нык булсын өчен без бөтен шартларны тудырырга тиеш. Никахларны саклап калу максатыннан аерылышу процессына үзгәрешләр кертү – аны катлауландыру буенча тәкъдимнәр керттек. Моның белән килешмәүчеләр дә бар. Әмма әлегә үзгәреш кирәк, бу бик мөһим мәсьәлә».

Рөстәм Миңнеханов Татарстанда күп балалы гаиләләрне ничек зурлау үрнәген дә күрсәтте: форум кунаклары алдында Балтачта яшәүче биш бала анасы Зөлфидә Теләковага һәм Сарман районының Җәлил бистәсендә гомер кичерүче, шулай ук биш бала тәрбияләүче Наталья Дубининага «Ана даны» медальләрен тапшырды.

РФ Дәүләт Думасы депутаты, Федерация Советы әгъзасы Елена Мизулина да Татарстан Президентының аерылышуларны катлауландыру тәкъдимен хуплап чыкты. «Гаиләдә балигъ булмаган балалар булганда никахны өзү процессын катлауландыру бигрәк тә мөһим. Чөнки бала өчен әти белән әнинең аерылышуы һәрвакыт фаҗига, – диде ул. – Форумда катнашучыларның фикере уртак: традицион гаиләләр – Россиянең нигезе. Гаиләләргә бүген өч куркыныч яный. Аның беренчесе – аерылышулар, икенчесе – бала төшерү һәм өченчесе – суррогат әниләр. Соңгысын күп илләрдә фахишәлек, кеше сату белән тиңлиләр».

«Ана изгелеге» Бөтенроссия программасының иганәчеләр шурасы рәисе Наталья Якунина әйтүенчә, форум Россиядә гаилә институтын ныгыту, күп балалы гаиләләрне саклау максатыннан оештырылды. Бу эшкә Татарстан матбугаты да зур өлеш кертә – «Татмедиа» Республика агентлыгы җитәкчесе урынбасары Эльвира Әхмәтованың саллы чыгышы шул хакта булды. «Сөембикә», «Гаилә һәм мәктәп» журналлары тәҗрибәсе дә күпләр өчен үрнәк алырдай дип табылды.

PRESSA.RU



Фото: Ксения Богданова

ВАКЫТНЫ НИЧЕКЛӘР ҖИТКЕРЕРГӘ?



Гөлнур САФИУЛЛИНА

БАРЫСЫ ДА ЭШТӘГЕ ШУШЫ СӨЙЛӘШҮДӘН БАШЛАНДЫ.

– Бер журнал сатып алдым әле, – диде Лариса. – «Вакытны ничек җиткерергә?» дигән сорауга җавап эзләгәннәр.
– Йә, нинди киңәшләр бирәләр? Берәр файдасы булдымы? – дибез. Бу сорау барыбыз өчен дә кызык. Вакыт җитмәү мәсьәләсе кагылмаган хатын-кыз бармыни ул?!
– Укырга өлгермәдем шул әле. Һаман вакыт җитми...

Рәхәтләнеп көлештек. Яратып көләбез анысы: «Сөембикә»нең җаваплы сәркатибе булып эшләгән Ларисаның мең мәшәкатьле тормышы күз алдыбызда лабаса. Һәр хатын-кыз кебек ул да йөзгә бүленә: эш, гаилә, кызлары... Әле йөз яшькә җитеп килүче дәү әтиләре дә аның кулында. Шагыйрь Зөлфәт килене ул безнең – аның турында истәлекләр китабы туплауны да үз өстенә алды.

Бүгенге хатын-кызның тормышын, бер карасаң, элеккегеләр белән чагыштыра торган да түгел. Кер юмыйбыз – машинабыз бар. Савыт-саба юу җәһәтеннән дә күпләр тагын шул ук машинага салынды. Кул астында – мультиварка, блендер, кухня комбайны, сок сыгу

җайланмасы, миксер, каһвә пешерә торган машина... Балаларыбыз да биш-алты түгел, күп булса – бер яки ике, сирәк кенә өч. Ә тормыш дигәнең нигәдер һаман җиңеләйми – без барыбер өлгермибез! Югыйсә шуның кадәр «ярдәмче»ң барында үз-үзеңне көйләп, үз күңелеңне күреп утырасы гына инде: яраткан шөгылеңә тотынасы, теләгән кешеңне күрәсе, барасы җиреңә чыгып китәсе... Тик юк шул! Хәтерлисезме, элек бәйрәмнәр җитсә, ким дигәндә 30-40 котлау открыткасы ала идек, үзебез дә шуның кадәр яза идек... Әйе, яза идек... Ә хәзер телефонга килгән «смс»-котлауга да җавап язарга кул җитми. Куш бит тутырып хатлар юллау турында әйткән дә юк. Яшьләр бөтенләй «уздыра» – тизрәк булсын дип, «смс» язганда сузык хәрефләрне дә куеп тормый: «сәлам» – «слм» аларда, «рәхмәт» – «рхт»... Ашыгалар! Кая ул элеккеге хатлардагы кебек йорт эчендәге һәммә кешегә аерым атап сәлам күндерү, моның белән генә чикләнмичә, бөтен тирә-күршене, урамында яшәүчеләрне исемләп искә төшереп чыгу!

Әле кайчан гына, әйтик, Татарстанның ерак районнарыннан саналган Чүпрәледән, Баулыдан яки Актаныштан Казанга килеп китү өчен ким дигәндә өч көн кирәк иде (бу әле шәһәрдә эшләреңне көнендә төгәлли алсаң!): бер көн киләсең, бер көн Казанда булсаң, бер көн кайтасың... Ә бүген? Анда яшәүчеләр өчен иртән Казанга чыгып китеп, кич әйләнеп кайту гадәти хәл түгелмени?! Юллар әйбәт, машиналар шәп... Кәгазь, документ илтәсе генә булса, гомумән, юлга чыгып та тормыйлар: моның өчен интернет, факс бар. Тик моңа карап, аларның да «буш вакытыбыз артты» дигәннәре ишетелми.

Адәм баласы һәрвакыт вакытны үзенә буйсындырырга тырышкан: сәгать уйлап тапкан, календарь төзегән. Әмма җил исү, яңгыр яки кар яву, табигать фасыллары алышыну кебек күренешләр безнең теләкләргә берничек бәйләнмәгән кебек, вакыт та шулай. «Их, тәүлек 36 сәгать булса иде ул! Юк, 48!» Мондый сүзләрне адым саен ишетәбез. Тик табигатькә ничек каршы барасың? Аннан, тәүлек ике тапкырга озынайса да, җитәр идеме ул безгә, канәгать булыр идекме икән? Бәлки, безгә бирелгән шушы 24 сәгатьне ничек дөрес итеп файдаланырга өйрәнү мөһимрәктер...

«Минутында тотмасаң, сәгатендә тоталмассың».

Вакытны күбрәк хатын-кызлар дөрес бүлми, дөрес кулланмый дип саный белгечләр. Белмим... Сез ничектер, тик мин моның белән килешергә теләмим. Безнең өскә йөкләнгән (яки берәү дә йөкләмичә, үзебез, үз иркебез белән алган) вазыйфаларны саный китсәкме?! Кайдан, ничекләр җитсен ул безгә?! Алай булсаң да, тегеләй булсаң да, бер тәүлек ләбаса ул. Әмма үзең өчен буш вакыт барыбер табасы, җиткерәсе килә!

Вакытыбызны дөрес бүләргә өйрәткән киңәшләр шактый.

ФИКЕР



Чулпан ЮНЫСОВА, журналист, ике бала анасы:

– Дөньяда вакыт белән генә узыша алмыйсың бугай. Иң җитезе ул, беркемнән дә тоттырмый. Балачакта – вакыт төшенчәсенең асылын әле аңлап җиткермәгәндә – аны җитәкләп чабарга әзер идем... Хәтерлим, мәктәптә яратмаган дәрестә утырганда 45 минутны уздыра алмый интегә идек, ә кышкы каникул белән язгы каникул арасында адашып, зарыгып йөрүне әйтеп тә торасы юк. Үсә барган саен, вакыт, мине калдырып, алгарак китә башлады. Инде хәзер, гомернең алма кебек чагына җиткәндә, гомумән, чабыш атыдай алга ыргылды: күпме йөгерсәм дә, куып тота алмыйм. Вакыт хакында еш уйланам мин. Нигә җитми ул миңа? Югыйсә сабыйларым үскәнгә куанып, өйдә утырган чагым. Аны уздыра алмый интегергә тиешмен кебек! Тик дүшәмбе иртәсендә күзне ачам да, япканда инде якшәмбе киче була... Шуңадырмы, ул бик кадерлегә әйләнде.

Камиллеккә чикләр юк. Үз өстендә эшләргә, балалар белән шөгыльләнергә, уңган хуҗабикә, назлы хатын булырга теләүчеләргә телевизор, андагы бетмәс-төкәнмәс кинолар, ток-шоулар зур киртә. Шуңа да иң беренче телевизор белән дуслыкны өздем. Үзенә вакыт таләп итүче күпсанлы социаль челтәрләр белән дә хушлашырга туры килде. Дөрес, барысы белән дә түгел – анысы замана таләбе. Дөнья арбасыннан төшеп калмас өчен кирәкле мәгълүматны, яңалыкларны үземә охшаган интернет битләрдән укыйм. Мәгълүматны сайлап кына җыям, башны чүп-чар белән тутырмыйм. Кызганычка дип әйтимме, әллә бәхеткәме, тик шактый танышлар белән дә ара үзеннән-үзе өзелде: телефон аша сәгатьләр буе сүз булсын өчен генә сатылган гайбәт мәгънәсез булып тоела башлады. Алардан калган буш урынны балалар белән аралашу, яраткан китапларга һәм кул эшләренә калдырдым. Аудиокитапларга өстенлек бирә башладым. Дөрес, ул буяу исе килеп торган китапны тотып уку рәхәтлеген алыштырмый. Кайберәүләр ашарга пешерү вакытны әрәмгә уздыру дип исәпли. Мин исә гаилә табын артында тагын да якыная дигән фикердә. Якыннарыма тәмле ризыклар әзерләгәндә, аудиокитаплар тыңлыйм – вакыт икеләтә файдага уза. Әмма минем иң зур уңышым – көнне иртә башлау. Иртә торган – аш пешкән! Шул очракта гына барлык планлаштырылган эшләрне башкарырга, тирә-якка күз салып, тормыш матурлыгын тоярга, миңа мондый вакыт биргән өчен Ходай Тәгаләгә рәхмәт әйтергә дә өлгереп була.

PRESSA.RU

ФИКЕР



Эльмира ЗАРИПОВА, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры, игезәк балалар анасы:

– Вакытны җиткерүнең төп сере – эшләреңне оештыра белүдә дип саныйм. Барысына да өлгерүемә, уларымны үстерергә җитешүемә килсәк, минем төп ярдәмчем – әнием, балаларымның дәү әнисе һәрчак янныбызда.

«Вакыт белән акча табыла, акча белән вакыт табылмый».

Дөрес, без аларның күбесен, белепме-белмичәме, болай да шулай эшлибез икән. Әмма искә төшерүнең зыяны булмас.

Өй эчендә башкарган эшләрнең исемлеген төзеп (алар болай да башта инде!), атнаның җиде көненә бүләргә кирәк. Тау кадәр кер үтүкләүне һәм идән юуны бер көнгә планлаштырмагыз.

Юк-бар нәрсәләргә – сериал карауга, артык якын да булмаган танышыгызның сәгатьләр буе телефоннан нидер сөйләвен тыңларга, компьютер каршында утыруга, әледән-әле «Вконтакте», «Одноклассники»ны карап алуга исраф иткән вакытыгызны юри генә санап карагыз әле. Бер генә түгел, берничә көн буе. Ничек бар – шулай язгыз: үзегезне үзегез алдаудан берәүгә дә файда булмас. Йә, барысын кушкач, сәгатьләр шактый җыеламы? Ә бу вакытны дус кызыгыз урамга йөгерергә чыгадыр, чит тел өйрәнәдер...

Һәр эшне үз вакытында башкарырга кирәк. Мәсәлән, фатир өчен вакытында түләсәгез, ай ахырында чиратта торып, вакыт уздырмас идегез. Бүгенге эшне, гомумән, нигә иртәгәгә, берсекөнгә калдырырга? Һәр яңа көн белән яңа мәшәкатьләр туа. Берсе өстенә икенчесе өстәлгәч, аларны тиз генә җиңеп тә булмый. Борчылгач, гадәти генә эшләр дә озаграк эшләнә.

Эшлисе, тотынасы килмәгән эшләрне иң азакка калдырмагыз. Иң яхшысы – эшләп куярга да, онытырга. Югыйсә безнең авырына барып җитәсе килмичә, эшнең җиңелен дә махсус озакка суза торган начар гадәтебез бар. Нәтиҗә һаман бер – вакыт югалтабыз.

Без бик уңган, булган, тырыш... Юк, юк, моңа беркем дә шикләнми, ләкин шулай булса да, әйдә, өй эшләрен башкалар белән дә бүлешик әле. Безнең бу яңалыкка артык сөенүче табылмас табылуын... «Аннары бергәләп кая да булса барырбыз!» – дип әйтеп карасак?

«Сезнең өй иң чистасы булырга тиеш!» дигән йөкләмәне безгә кем тапшырган иде, хәтерләмисезме? Юк шул менә... Тәртип, әлбәттә, булырга тиеш. Әмма кулга юеш чүпрәк тотып, бертуктамый тузан сөртеп йөрү, көн саен идән юу артыграк түгелме? Иребез, балалар өчен йөзебездән елмаю китмәве мөһимрәк дип уйламыйсызмы? Гел сукранып йөргән кешене кем яратсын? Җыештыруга никадәр вакыт китүен әйтмим дә әле.

Көнкүреш техникасы белән дуслык ничегрәк? Алар бит «башкаларда бар, бездә дә булсын»га гына алынмагандыр? Һәммәсен эшкә җигегез – техниканың төп бурычы шул бит: безнең тормышны җиңеләйтү. Кичтән иртәгә башкарасы эшләрне барлап чыгып, теркәп куюның зыяны юк. Хәтер – тишек иләк, диләрме? Эшкә нәрсә киеп барасыгызны кичтән хәл итеп куярга гадәтләнсәгез, иртән ыгы-зыгы шулай ук азрак булыр.

ФИКЕР



Зөлфия ВӘЛИЕВА, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисткасы, ике бала анасы:

– Дөресен әйтәм – өлгереп булмый... Эшләрнең барыбер кайберләрен читкәрәк этеп куясың, кайсынадыр күбрәк игътибар итәсең. Әлеге минутта тотынган эшеңә, әлбәттә, җаваплы карыйсың: бер эшне башкарганда икенчесен уйларга керешсәң, монысына зыян килә. Психологлар, әйтик, савыт-саба юсаң да, шуңа сеңеп бетеп эшлә, диләр. Шуның турында гына уйлап, ләззәтен тоеп, рәхәтен табып...

Алдан бер нәрсәне планлаштырганым юк. Эшләп караганым бар – барыбер мин теләгәнчә килеп чыкмый. Дөрес, кичтән иртәгәге көнне уйлыйсың инде, шуларны-шуларны эшләргә кирәк дип, ә бер атнага, бер айга, бер елга план төзү, белмим... Планлаштыру дөресрәктер анысы. Бәлки, ул очракта кешенең хыяллары да тизрәк чынга ашадыр. Хыялланган әйбереңнең рәсемен каршыңа элеп куеп, шуңа әледән-әле карап утырсаң, ул тормышыңа тизрәк керә диләр бит. Хыялларым язылган дәфтәр миндә дә бар анысы...



Тукталып, якын кешеңнең күзенә карарга, сөйләшергә, хәлләрен белешергә, балалар белән, онытылып, иркен генә уйнап утырырга вакыт җитми безгә хәзер. Моны аңлагач, мин аларны әкрен генә тормышыма кертә башладым. Ыгы-зыгыдан, дөнья мәшәкатьләре артыннан чабудан читләшергә тырышам бүген. Вакыт тиз бара, җитми, диләр. Шулай тормыш та узып китә. Искә төшерерлек бер нәрсә калмый... Әмма иҗат кешесе вакытын күбрәк барыбер үзе планлаштыра ала – безгә бу яктан җиңелрәктер.

Балаларга ниндидер эш кушып калдырасыз икән, җай табып, көндез шалтыратып, исләренә төшереп алыгыз. Ышанмаганга түгел, уен белән мавыгып, оныта торган гадәтләре бар. Тагын үзегезгә эшләргә туры килмәгәе...

Бер эш артыннан икенчесен планлаштырып, үзегезгә суларга да вакыт калдырмадыгызмы? Онытмагыз: сез робот түгел, ә гап-гади хатын-кыз. Тәнәфесләрсез берничек тә булмый!

Эшне генә түгел, ялны да алдан планлаштырыгыз. Беренчедән, бу – вакытны бүлү өчен генә түгел, чыгымнарны чамалау өчен дә кирәк. (Кино билеты да, театрныкы да арзан тормый хәзер.) Икенчедән, алда ял көтәсен белгәч, эшләр тизрәк тә, җиңелрәк тә эшләнә!

Кичтән йокы килгәндә ятып йоклап, иртән көн саен билгеле бер вакытта, әйтик, сәгать алтыда торырга күнегү, хатын-кызга үзе өчен өстәмә буш вакыт бирә. Бу чакта әле беркем бүлдерми, телефоннар шалтырамый. Телефон дигәннән, кичен аны, гомумән, сүндереп куярга да мөмкин бит. Ярый, көн саен димик, әйдә, көн аралаш... Моңардан дөнья җимерелмәс, элек кесә телефонсыз яшәгәннәр бит әле.

...Үткән гасырның иң бай кешесе – грек миллиардеры Онассис соңгы көннәрендә: «Минем тормышым алтын туннель булды. Беркая да алып бармый торган туннель...» – дип язып калдырган. Гомернең ахырында: «Мәгънәсезгә яшәдем...» – дип уйлаудан да ачы үкенеч юктыр. Акча тавы өстендә утырган бай абзый: «Байлык – бәхет түгел», – ди. Безнең дә күп вакытыбыз шул байлык артыннан чабып узмыймыни? Югыйсә берәү дә чыбыркы тотып артыбыздан кумый. Чыбыркы үз кулыбызда – әйләнәбез дә үзебезгә сугабыз, әйләнәбез дә сугабыз...

Без күп вакыт үткәндә калган хатирәләр яки киләчәк хыяллар белән яшибез. Ә тормыш бит ул менә бүген, шушы сәгать дигән сүз. Урамда, әнә, ап-ак кар ява, көне буена күрешмәгән балаң сагынып каршыңа чаба, якын кешең янәшәңнән атлый... Иң мөһимен күрергә, иң мөһимен аңларга вакыт табыйк.



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы:

– Без бу дөньяда бөтен нәрсә дә үзебезнеке дип иялөшкән: кигән киемебез, ашаган ризыгыбыз, йортыбыз, машинабыз... Ә дөреслектә, боларның берсе дә безнеке түгел. Кайчан да булса аларны барыбер югалтачакбыз: йә без аларны калдырып китәчәкбез, йә алар безне... Безнең файдага эшли торган бер генә нәрсә бар, ул – вакыт. Тәмле ризык, яхшы машина, әйбәт йорт тормышыбызны гына җиңеләйтә, ә вакыт безгә хезмәт итә ала. Ләкин шул ук вакытта галимнәр: «Вакыт – кылыч кебек: йә син аны ныклап тотасың, йә ул сине кисә», – диләр. Вакыт – зур байлык, әмма без аның тиңсез хәзинә икәнен дә, вакытны үзебезгә ничек эшләтергә икәнен дә белмибез. Вакытның нәрсә икәнен шайтан менә бик яхшы аңлаган. Аллаһы Тәгалә аны тәмугка кертергә дигән хөкем чыгаргач, ул моны кичектерүне, ягъни вакыт сорый. «Вакыт булса, мин бөтен нәрсәне эшли алам», – ди. Вакыт ярдәмендә шайтан бик зур тәҗрибә туплый: кешене, аның холкын өйрәнә һәм кешеләргә начарлык кыла башлый. Шушы мисал белән Аллаһы Тәгалә безгә: «Вакытның кыйммәтен аңлагыз, әмма аны шайтан кебек тотмагыз, файдага үткәрегез», – ди.

Без бу дөньяда ике чикне үтә алмыйбыз: беренчесе – урын (пространство), икенчесе – вакыт. Вакытны беркем үткәне, аның аръягына чыкканы юк. Пәйгамбәребезнең өммәте – ул иң кыска гомерле өммәт. «Минем өммәтемнең яше 60 белән 70 арасында булыр», – ди ул. Шул кыска гомерне файдалы итеп үткәрергә тырышырга тиешбез. Аллаһы Тәгалә моның өчен безгә ярдәм дә итә: һәр игелегебезне унга тапкырлый – бу кыска гомер эчендә күп игелек кылып булмый, ул шулай тапкырланса гына күбәя ала. Ә начарлыклар бергә – бер языла.

Кеше игелек, яхшылык кыла икән, вакытының да кадере арта – озыная. Берәр яхшы эшкә тотынсак, вакыт, чыннан да, тукталган кебек була бит. Ә менә күңел ача башласак, бик тиз узган кебек. Пәйгамбәребез: «Кыямәт җитәр алдыннан, вакыт тизрәк барыр», – ди. Моны галимнәр раслады инде.

Вакыт нигә җитми, дип, минем дә уйланганым бар. Йөз чакрымны дәү әни-дәү әтиләр кебек ике көндә узмыйбыз – машинабыз бар. Кайбер мәсьәләләрне өйдән дә чыкмыйча хәл итәргә кулыбызда телефон. Тик өлгермибез! Элеккегеләр кирәк артыннан куып яшәгән, ә без... Тамагыбыз тук, өстебез бөтен – безгә хәзер артыгы кирәк, яхшысы, затлырагы... Менә шул артыгы артыннан куып, безгә вакыт җитми дә. Ә артыкның чиге юк. Тагын бер сәбәп: кеше хәзер бик күп күңел ача. Моның өчен әллә никадәр мөмкинлекләр бар: кинотеатрлар, телевизор – боларга чумсаң, көне буе кузгалмый утырырга була. Моңа файдасыз юк-бар сөйләшүләр дә керә, ашап-эчүләр дә (элек карын ачканга ашаганнар, ә хәзер ашау вакыты җиткәнгә, эч пошканга).

Көнне дөрес итеп планлаштыра белмәү, тормышта билгеле бер максатлар куя алмау да вакыт җитмәүгә китерә. Күпләр, нәрсәгәдер ирешер өчен түгел, көн үтсенгә яши. Әйе, көнне юкны бушка аударып та уздырырга мөмкин, гыйбадәт кылып, Аллаһы Тәгаләне искә алып та. Соңгылары вакытны киңәйтә, икенче төрле итеп әйткәндә, тормышыбызга бәрәкәт өсти, һәм без кыска вакыт эчендә күп нәрсәгә өлгерә башлыйбыз. 27 яшендә вафат булган Габдулла Тукайны, аның калдырган мирасын гына искә төшерик.











Гариф Бурнашев гаиләсе белән Кырымда ял иткәндә. XX гасыр башы.
Солтан-задә *(сулдан икенче)* В. И. Ленин белән сөйләшеп утыра.
Сәлимә Бурнашева кызы Эльнара белән. 1940 ел.
Сәлимәнең әнисе Хәдичәнең бертуганы Шәмсия Хөсәен кызы Ширинская.

МОРЗА КЫЗЫ СӘЛИМӘ

ШУШЫ ЗАМАННЫҢ БӨЕК ШӘХЕСЛӘРЕ БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР, МӘХӘББӘТ РОМАННАРЫ...

Зиннәтле-ялтыравыклы тормыш, байлык белән сыналулар да, коточкыч газап, михнәт чигүләр дә – һәммәсе җитәрлек тигән аның өлешенә.

Халык арасында танылган, күренекле шәхесләрнең исемнәре кергән энциклопедияләрдән аның хакында мәгълүмат таба алмассыз. Сәлимә Ариф кызы Бурнашева – үзенчә, үз тормышы белән яшәгән ханым. Янартауда вулкан атылгандай кинәт гөрелдәгән совет тарихының үзәгендә кайнаган ханымның тормыш юлы кызыклы да, фаҗигале дә.

Сәлимә Бурнашева 1913 елның мартында, ул чакта Тамбов губернасына, хәзерге Рязань өлкәсенә кергән Әҗе авылында мех белән сәүдә итүче бай сәүдәгәр Ариф (Гариф) Хөсәен улы Бурнашевлар гаиләсендә дөньяга килә. Борынгы һәм дә зур тарихлы бу татар авылы милләтебез тарихында якты эз калдырган, танылган шәхесләрнең ватаны, кадерле-изге җире буларак билгеле. Мәскәүнең Җәмигъ мәчетенә нигез салган меценат Салих Ерзин, революционер-большевиклар Хәсән Урманов һәм Баһаветдин Шиһабетдинов, Гыйффәт туташ тәхәллүсе белән язган шагыйрә Заһидә Бурнашева, Коръән-хафиз Ибраһим Урманов, бик күп имамнар, педагоглар шушы авылда туып, канат ныгыткан. Совет Татарстанына байтак еллар җитәкчелек иткән, аннан Әфганстанда илче булган Фикрәт Табиев та 1928 елда Әҗедә дөньяга аваз салган.

Сәлимә туган елларда Әҗедә җиде меңгә якын халык яши. Мокша елгасы ярында урнашкан бу авылда җиде мәчет, мәдрәсәләр эшләп тора. Шәкертләр Россиянең төрле почмакларыннан монда килеп укый, гыйлем ала торган була.

Бурнашевларның туган җире, нәсел-нәсәбе төпләнеп, бер оя булып яшәгән Әҗе гаҗәеп матур урында урнашкан. Сәлимәнең әнисе – борынгы морзалар нәселеннән чыккан Хәдичә Хөсәен кызы Ширинская Әҗедән унике чакрым ераклыктагы Богданово авылында туган. Ширинскийлар һәм Бурнашевлар шул заманның күренекле, бай сәүдәгәре Ерзиннар, Кастровлар, Девишевлар белән аралашып, туганлашып бергә яши. Әҗедән ерак та түгел борынгы Касыйм каласы җәелеп ята. Мәскәүгә дә кул сузымы, дисәң дә ярый.

Байлык-муллыкта рәхәтләнеп яшә дә яшә генә! Ләкин Сәлимәгә һәм аның туганнарына да әтиләре тапкан байлыкның кадерен белеп, озын-озак рәхәт гомер кичерергә язмаган! Чөнки түнтәрелеш – революция еллары күз ачып йомган арада бөтен нәрсәнең астын-өскә әйләндереп ташлый.

Унҗиденче елгы революциягә кадәр үк Сәлимәнең әтисе – Ариф Хөсәен улы Бурнашев Әҗе белән элемтәләрен өзмичә генә Мәскәүдә тамырланырга өлгергән була. Эшлекле, байлыклары белән танылган сәүдәгәрләр нәселеннән ич ул: аның әтисе Хөсәен Сөләйман улы Бурнашев Мәскәүдәге немец компанияләренең берсендә каракүл тиреләр буенча эксперт булган. Шул ук вакытта Әҗедә кәҗә мамыгын аялау-язу предприятиесе дә ачып җибәргән. Чималны Оренбург ягыннан сатып алалар, Әҗедә мамык аялана, эшкәртелә, Мәскәүдә күпләп сатуга куела. Хөсәен улы Ариф Бурнашев каракүл тиреләре сату белән яшьтән үк шөгыльләнә. Төркестан белән киңкырлы элемтәләр урнаштыруы исә зур табыш китерә.

Мәскәүдә Ариф Бурнашев башта Иске Татар бистәсендә – Замоскворечье дигән җирдә – ягъни Мәскәү елгасының аръягында яши. 1916 елда шәһәрнең икенче читендәге 2 нче Мещан урамында ике катлы йорт били. Җәйлеккә гаилә Әҗегә кайта, табигать кочагында хозурланып, җиләк-җимеш өлгергәч, саф һава сулап, шәһәр шау-шуыннан арынып ял итүгә ни җитә!

Адәм ышанмаслык вакыйгаларга гаять тә бай егерменче гасыр Сәлимә язмышында да сизелерлек эз калдырган.

Әйтергә кирәк, бу гаиләдә яшәгән һәркем рус телен яхшы белә, китаплар укый, матур әдәбият белән кызыксына. Бер кызыклы хәл – яшәве Мещан урамындагы мәчет янәшәсендә генә булса да, Ариф Хөсәен улы җомга намазына Мәскәүне аркылыга-буйга гизеп, Зур Татар урамындагы мәчеткә килә. Чөнки аның якын дуслары – Касыйм каласы һәм Әҗе авылыннан чыккан татар сәүдәгәрләре намазга иске мәчеткә йөри торган була. Ә иң

PRESSA.RU

мөһиме: монда Бурнашевлар гаиләсен ихтирам иткән имам-хатыйб Абдулла Шәмсетдинов эшли, аның белән аралашу, бер күреп сөйләшү үзе әллә ни тора.

Сәлимә һәм аның кыз туганнары Хәсәнә, Нәсимә, Айниҗамал, Җәмилә 2 нче Мещан урамында үсә. Алар йортында танылган шәхесләр, әйтик, әтиләренең якын танышы – мәшһүр дин галиме Муса Бигиев кәтеп алынган кунак. Егерменче елларда совет властена яраклашкан катлам вәкилләре – елдам-зыялы эшмәкәрләр дә бу кунакчыл йортны чит итми. НЭП – яңа икътисадый сәясәт әле байларга үзләре теләгәнчә яшәрлек форсат бирә. Бер вакыт Бурнашевларга ярлы киенгән фәкыйрь карчык килеп керә. Баксаң, хәерче дигәнең революциягә кадәр Мәскәүнең атаклы рус сәүдәгәре Карзинкина ханым икән. Йорт хуҗабикәсе Хәдичә Бурнашевага яшерелгән кыйммәтле хәзинәсен күрсәтергә килгән. «Кызыл барыня»ларга кадерле әйберләрем әрәм, аларга эләккәнче сезгә китерим дидем», – дип тәмамлый сүзен.

Хәзер инде ул заман кануннарын аңлап бетереп тә, аңлатып та булмый.

1930 елның гыйнварында алар өчен дә кара көннәр башлана. Ариф Бурнашевны һәм аның абыйсы Абдрахманны Мирсәет Солтангалиев эше буенча гаепләп, кулга алалар. Мәскәүнең татар элитасында исәпләнүче Ариф Бурнашев эшчәнлегенә нокта куела: биш елга төрмәгә утыртылган зыялыга гаиләсе янына кире кайтулар насыйп булмый. Ул 1957 елда – вафатыннан соң гына аклана.

Әтисе кулга алынуга карамастан, Сәлимәгә икътисад техникумын тәмамлау насыйп була. Дәүләт учреждениесендә тыйнак кына вазыйфа башкара ул. Ә беркөнне аңа ниндидер спектакльгә билет таратуны йөклиләр. Бер кабинетка килеп керә кыз, һәм нәфис фильмдагы сыман, киләчәк язмышы белән очраша.

Хуҗа – Аветис Солтан-задә – Иран коммунистлар партиясенә нигез салган, Коминтернның күренекле эшлеклеләренең берсе, дөньялар болгангач качып, СССРга килеп урнашкан һәм Мәскәүдә мөһим икътисадый пост биләгән ир-ат Сәлимәгә бер күрүдә гашыйк була. Солтан-задә егерменче еллар уртасында Ленин белән аралашкан, фарсылар арасында революция ясау ихтималы хакында киңәшкән, СССРда икътисад һәм колониализм мәсьәләләренә багышланган китаплар чыгарган. Егерменче еллар уртасында Солтан-задә, ул чакта «Экономическое строительство» журналының баш мөхәррире, журналист Елена Берлин белән таныша. Аларның Леонид исемле уллары туа.

Солтан-задәгә Сәлимә өченче хатын булып бара. Карт коммунист белән япь-яшь сәүдәгәр кызы арасындагы мәхәббәт көчле була. Яшь аерымлыгы да (25 яшь!), Сәлимәнең әтисе репрессия корбаны булу да гашыйклар юлына киртә куя алмый. Чынлыкта, аларның дини тәрбия-карашлары да нык аерыла. Аветис Солтан-задәне мәскәүлеләрнең күбесе әзәрбайҗан милләтеннән, мөселман дип белсә дә, чынлыкта, ул әрмән гаиләсендә туган – үз фамилиясе Микаэлян була.

Мәскәү. 1930 нчы еллар. Сәлимә Бурнашева шәһәр уртасында иркен фатирда яши. Үзләренең затлы дачасында Михаил Тухачевский белән теннис уйный. Ул – совет элитасының бер өлеше.

Сәлимә Бурнашеваның бу чордагы тормышы турында якын дусты һәм туганнары Рауза Кастрованың (1911–2012) истәлекләре сакланган. Солтан-задәләр дачасында Яңа елны каршылаулары хакында яза ул. Кунакларга – аеруча Иран һәм Әзәрбайҗан коммунистларына ишекләре һәрчак ачык булганга монда күптөрле халык җыела. Советларның икътисадый тормышында күренекле урын, югары постлар биләгән Солтан-задә Шәрык белән элемтәләрен өзми, андагы коммунистлар арасында абруйлы һәм хөрмәтле санала. Зур урыннар биләгән түрәләр дә бу кунакчыл йортка эзне суытмый.

Сталин заманындагы Мәскәү өчен Сәлимәнең тормышы тоташ әкияткә охшаш. Әмма бәхетле әкият биш ел чамасы гына дәвам итә.

1938 елның гыйнварында Солтан-задәне, Коминтерн эшлеклеләренең күбесен кулга алган сыман, төрмәгә ябалар һәм шул ук елның июнендә атып үтерәләр. Сәлимә Бурнашева да бу фаҗигадән читтә кала алмый, билгеле. Аны да халык дошманы хатыны буларак төрмә көтә. Атаклы Бутырка төрмәсендә ул 9 ай утыра... Нәни кызы Эльнараны ниндидер могҗиза белән генә туганнары саклап кала. Сәлимәне коточкыч газаплардан нәрсә коткара? Моны әйтүе кыен. Аны лагерьга җибәрү яки атылудан партия әгъзасы булмавы коткара дип исәпли ул үзе.

Зиннәтле, бай тормыш турында бүтән хыялланмый, эчтән тына ул. Сугыш елларында, 1944 елга кадәр, кыз туганнары белән туган ягында – Әҗедән ерак түгел Ермишь дигән бистәдә яши. Бухгалтер булып эшли.

Ләкин матур, рәхәт тормышка тартылу хыял булып күңелендә пыскый әле. Язмыш Сәлимәне Советлар Союзы маршалы Григорий Кулик белән очраштыра. Яңадан ялкын булып мәхәббәт уты кабыну... Маршал чибәр Сәлимәгә өйләнергә, гаиләсен ташларга ниятли. Ләкин акыл кергән, авызы бер пешкән Сәлимә бу тәкъдимне кабул итә алмый, тотрыксыз совет элитасы даирәсенә яңадан аяк басарга шүрли. Чыннан да, Григорий Куликны 1947 елда кулга алалар. 1950 елда аталар. Сәлимәгә әле шактый еллар яшисе дә яшисе...

Сугыштан соң Сәлимә Бурнашева Петровкада – СССР елга флоты министрлыгында эшли. Пенсиягә чыгар алдыннан РСФСР авыл хуҗалыгы министрлыгына эшкә күчә. Оныгының истәлекләренә караганда, Сәлимә Ариф кызы көнкүреш ваклыкларына күмелергә яратмый торган, күңел ачуларга әвәс, богемага табынган ханым була. Сәүдәгәрләр арасында үсүе, Солтан-задә белән яшәве холык-фигылендә дә, яшәү рәвешендә дә, күрәсең, сизелерлек эз калдыра. Татар телендә ул аз һәм

начар сөйләшә. Әмма картая-картая татар җырлары белән күбрәк кызыксына, борынгы көйләр тыңларга ярата. Туган авылы Әҗегә кайтып, аз булса да шунда яшәргә хыяллана.

Гомеренең соңгы елларында ул Альцгеймер авыруы белән интегә. Күпне күрү-кичерүе, Бутырка төрмәсендә утырулары эзсез узмый, билгеле. Дөрес, үзе бу хакта искә алырга яратмый. 1930 елда 16 яшьлек кече сеңелләре Нәсимәнең скарлатинадан үлеме аны нык тетрәндерүе хакында кат-кат искә төшерә. Әмма тетрәнүләрнең күпкә авырраклары да кичерә бит ул. Ихтимал, коточкыч 1938 ел аның хәтеренә, сәламәтлегенә төзәлмәс яра ясагандыр. 50 нче еллар ахырында кызы Эльнараның кияүгә чыгып, Чехословакиягә китеп баруы да аны утка сала. Дөрес, кызы соңрак Мәскәүгә әйләнеп кайта, әмма алар арасындагы киеренкелек саклана. Сеңелләре белән кайчак аралашса да, яшьлек дуслары белән араны бөтенләй өзә.

Сәлимә ханым Мәскәүдә 1984 елда вафат була. Данилов мөселман зиратында Бурнашевлар гаиләсе мәңгелек йорт иткән җирдә җирләнә. Янәшәсендә Ерзиннар, Ширинскийлар, Вергазовлар, Кастровлар... Каберләрдә борынгы ташлар һәм хәтер... Үзләренеке янына ул да кайта...

Сәлимә Бурнашева һәм аның бүтәннәрнекенә охшамаган язмышы турында мин балачактан ишетеп үстем, чөнки ул безнең ерак кардәшебез иде. Аның сеңелләрен дә күреп белә идем. Күптән түгел мин Сәлимә Бурнашеваның Чехиядә яши торган оныгыннан әбисе язмышына бәйле кайбер мәгълүматлар да алдым. Дусты – Мәскәүдәге татарлар тарихын өйрәнеп, хатирәләрне барлап-җыеп саклаучы легендар шәхес – Рауза Әхмәт кызы Кастрова белән дә күп тапкырлар сөйләшеп утырганым булды.

Сәлимә Бурнашева. XX гасыр һәм бер татар хатынының язмышы дип атадым мин бу язмамны...

Марат СӘФӘРОВ,
педагогика фәннәре кандидаты.
Мәскәү.
Роза КАМАЛЕТДИНОВА
тәрҗемәсе.

САБЫЙЛАР ӨЧЕН «ШАТЛЫК»

Арча ягының изге маршрутларын яттан беләбез — Мәрҗани, Тукай, Бәширов, Ахунов, Мәһдиев эзләре... Хәзер менә кунаклар тагын бер якты ноктаны сәфәр максаты итә. Калку урында булганга күрә ерактан ук балкып тора торган ул йорт — «Шатлык» дип исемләнгән балалар бакчасы. Арча хакимияттеннән лаеклы ялга дип китеп барган Надия Равил кызы Мифтахетдинованы да мин шунда барып таптым.



«Бер ел буе прораб булып эшләдем мин. Хәзер менә шушы сабыйлар йортының директоры булдым», – диде Надия ханым. Нигез салдырып, кирпеч өйдереп, дизайн макетлары сызып җенләнгән заман артта калган. «Дошман» үтеп керә алмас тимер рәшәткә артыннан мәгърурәнә күренеп торган өч катлы бина әйләнәсенә инде 60 миләш куагы да утыртылган. «Матур бакчабыз булыр. Әлегә җәен чәчәкләргә күмелеп утырабыз», – ди, Надия Равил кызы, киләчәккә карап. Әйе, балалар бакчасы Киләчәккә старт мәйданы. Сабыйлар – Киләчәккә бездән сәлам, бүләк, хәтта ки өмет ул.

Бала вакытта үзе балалар бакчасының, пионер лагеренең ни икәнен белмәгән, әмма шулай да курчакларына киемнәрне әнисе эштән алып кайткан мех кисәкчекләреннән тегә-тегә кулын шомарткан кызның хыялында әкияти сабыйлар дөньясы образы яшәгәнен берәү дә белмәгәндер. Хәер, тормышын балалар белән бәйләргә теләгәнгә күрә укытучылыкка укыган лабаса ул. Шактый гомере җитәкчелектә узганнан соң, менә кабат сабыйлар белән аңлашып аралашу рәхәте кичерә Надия ханым.

Ачылганына бер ел икән инде «Шатлык»ның. Быел икенче Яңа ел бәйрәменә әзерләнәләр булыр. Мине чәкчәк тотып каршылаган сабыйкайлар «Каз өмәсе» бәйрәменә күлмәк алыштырган арада мин «Шатлык» белән хозурланып йөрим. Аякны төреп ала торган йомшак келәмнәр – Мәскәүдән кайтартылган. Бала белән табигать мотивларына бизәкләр төшерелгән тәрәзә челтәрләре – Арча осталары кулыннан узган. «Ике яшьтән алып мәктәпкә кадәр» программасы белән эшләү өчен матурлык базасы җитәрлек икән монда. Һәм шул матурлык спорт залы, музыка залы, логопед бүлмәсе, медицина бүлмәсе, психолог бүлмәсе, инглиз һәм татар телен өйрәтү бүлмәләре белән ныгытылган. Һәр төркем бүлмәсендә телевизор, ноутбук, телефон, видеопроектор, бактерицид лампа бар. Өстәвенә, «Әкият» театры, уен кораллары оркестры, балалар вокаль ансамбле дә оешып өлгергән икән. Бакчада эшләүче 68 кешенең 35 е югары белемле белгеч-тәрбияче булганны белгәч, инглиз теле фестиваленең «Шатлык»та узуына гаҗәпләнмәдем. 14 төркемдәге (рус һәм татар төркемнәре аерым үзе) 330 баланың кечкенәдән рус, татар, инглиз телләрендә аралашып үсүенә дә фәкать сокланырга гына кирәк. 260 урынга төзелгән бакчага 330 бала йөрүе дә хак. Әле 140 бала электрон чиратта тора. Арча бистәсе өчен генә дип төзелгән бакчага Кәче, Бәрәскә кебек якын авыллардан да йөриләр. Тәрбия кылу чит илләрдәге кебек булса да, түләү авыл бакчаларындагы кебек кенә.

Һәр тәрәзәсе басуга карап торган сабыйлар йорты хатын-кызлар кулында гына түгел. Тәрбия кадәресе исә хатын-кыз кулында. «Каз өмәсе» бәйрәменә килгән кунаклар арасында элек үзләре тәрбияче булып эшләгән апалар да бар иде. Алар бу бакчада узган «Нәүрүз», «Сөмбелә», «Әбиемнең серле сандыгы» бәйрәмнәрен яратып киткән булганнар. Мондагы милли тәрбия, халыкчан рух бик сөендерә икән аларны. Инде менә тәрбиячеләре Айгөл Котдусова белән Миләүшә Шиһапова ярдәме белән 12 нче, 14 нче төркем сабыйлары әзерләгән «Каз өмәсе» тамашасын карыйлар. Каз канатлары белән «кагынып» биегән кызлар, шук малайлар уены чыннан да бик кызык тамаша икән лабаса. Халкыбызның тагын бер матур йоласын хәтерләп, белеп калачак инде бу бәбкәчләр.

Асия ЮНЫСОВА



«Сөембикә». Искәндәр Рафыйков эше

ӘЛВИДАГ, ӘЛВИДАГ...

Сөембикә – Нугай морзасы Йосыфның сөекле кызы. Мәскәү белән тарткалашуда шактый уңышларга ирешкән Сафагәрәйнең хатыны. Сафагәрәйнең кинәт үлеменнән соң тәхеткә утырган Сөембикә ханбикә Казанны, аның халкын җаны-тәне белән яраткан. Ул аксөяк адәмнәргә дә, кара халыкка да бертигез ихтирам белән караган, алар турында кайгырткан. Аның шушы сыйфатын ханбикә Казаннан киткәннән соң да сагынып сөйли торган булганнар.

Казаннан китәсе көнне Сөембикә Сафагәрәй кабере белән хушлашу өчен ханнар төрбәсенә юнәлә. Артыннан улы Үтәмешне күтәреп баралар. Сөембикә хәләл җефетенең төрбәсе янына егылып, үксеп-үксеп елый, Сафагәрәйгә мөрәҗәгать итеп: «И сөекле падишаһым Сафагәрәй! Синең белән үткәргән бәхетле гомерем бик кыска булды. Күрсәң иде син үзеңнең патшабикәңнең ни хәлдә икәнлеген! Ул дошман тозагында, аны ят гаскәр уратып алган. Ник ташлап киттең син мине, кемнәргә калдырдың безне? Бер генә юатыр кешем дә калмады бит. Кемнәргә генә мөрәҗәгать итим дә, кемнәрдән ярдәм сорыйм соң? Балабыз Үтәмешкәме? Тик ул сабый гына шул, бернәрсә дә белми. Атамамы? Ул бик ерак, миңа ярдәм итә алмый. Казанлыларгамы? Алар, антларына хыянәт итеп, мине саттылар. Ичмасам, ятларга түгел, үз динемдәге, үз телемдәгеләр кулына төшсәм дә җиңелрәк булыр иде миңа. Юк шул, синең яныңа да төшеп ята алмыйм. Китәм ятларга, читләргә. Хуш бәгърем!»

Аны көч-хәл белән аерып torгызалар. Хәле шулкадәр кызганыч була. Матурлыгы белән дан казанган, тиңе булмаган Сөембикәнең битләре тырмалып беткән, чәчләре тузган, туктаусыз елаудан күзләре шешенгән. Моны күреп, аның янындагы сагавыллар аны юатмакчы була. Янәсе, нигә син шулкадәр бетеренәсең, сине бит хурларга да, җәберләргә дә җыенмыйлар. Син Мәскәүдә дә шулай ук падишаһ кебек булырсың. Син яшь, гүзәл һәм чибәр. Картаеп беткән Шаһгалинеке (Касыйм ханы) булмассың, тиңнәреңне табарсың. Ниһаять, Сөембикәне утырткан арба Казансу буена – патшаларны йөрткән, алтын-көмеш белән бизәлгән көймә янына килеп туктый. Андагы халык! Яше дә, карты да, ир-атлар да, хатын-кызлар да, берсе дә калмаган! Халык ханбикәсе белән хушлашырга килгән.

Бу вакыйгаларны тасвирлаган рус елъязмаларында, халыкның, аңа мөнәсәбәте турында күп язылган. «Ул киткәннән соң да халык ел буе аны сагынып елады», – диелә шушы елъязмаларда. Ханбикә арбадан торып, халыкка баш ия. Халык исә шунда ук җиргә егылып, аның каршына тезләнә. Көймәдәге ханбикә гүзәл Казанына, үзен озата барган халыкка карап, күз яшьләрен агыза-агыза алар белән хушлаша: «Хуш, моңлы һәм канлы шәһәр! Синең башыңнан таҗың төште. Син ятим калдың. Көчле һәм гайрәтле ханың гүргә керде. Хәзер синең гаярь патшаларың да, куәтле гаскәрең дә юк! Эх, янымда кеше теле белән сөйләшердәй кош булса икән. Ул әтием Йосыф морзага минем фаҗигамне җиткерер иде. Казан өстенә төшкән афәтне сөйләр иде. Юктыр шул, миңа туган илемдә, йә патшалык кылган җиремдә үләргә насыйп булмаган, күрәсең. Раббыбыз миңа чит-ят җирләрдә – коллыкта, илемнән, җиремнән аерылып яшәү фаҗигасен язган, күрәсең!»

Йөзеп, канлы яшь белән сугарган Сөембикә ханбикә 1551 елның 5 сентябрендә Мәскәүгә китерелә. Сөембикәнең, дошман Казанны юкка чыгарганчыга кадәр ниятеннән ваз кичмәячәк диген фаразы дөрес булып чыга. Ханбикә үзенең фаҗигасен ил фаҗигасе итеп күзаллый. Һәм, кызганычка каршы, хаклы булып чыга. Казанның егылуына бер елдан аз гына артыграк вакыт калган була. Җиңелү сәбәбен Казанның эчке халәтеннән дә эзләргә кирәк. Монысы инде бөтенләй башка тема. Тик шунысы махсус игътибарга лаек. Колшәриф хәзрәт 1552 елның Казан фаҗигасенең соңгы көннәрендә дә үз-үзен аямастан, шәкертләре белән дошманга каршы чыгып, актык канына кадәр сугышып, ватан өчен шәһит була. Сөембикәне үз теләгенә каршы Касыйм ханы Шаһгалигә хатынлыкка бирәләр. Ханбикә аны яратмый. Шаһгали дә аны өнәми. Хәтта физик җәзаларга да тарткан диген фаразлар бар. Ләкин гади халык аны анда да Казандагы кебек үк яраткан. Ул анда да халык өчен булдыра алганның барысын да эшләгән.

Ләкин ул үзен иректә түгел, читлектәге кош кебек тойган.

Индус ТАҺИРОВ,
тарих фәннәре докторы

СӨЕМБИКӘ АТЫМ...



Фәнзилә
МОСТАФИНА

ШАҺГАЛИ АНЫ ЯРАТМАГАН. ХАТЫНЫ ИТЕП ТҮГЕЛ, ӘСИРЛЕККӘ ТӨШКӘН КОЛЫ ИТЕП КЕНӘ КАРАГАН.

Сөембикә вафат булгач, кайчандыр җир йөзендә аның яшәгәнлеге кешелек хәтереннән бөтенләйгә җуелсын дип, кабер ташына исемен дә яздырмаган... Автобус тизлеген арттыра, Сөембикә ханбикәнең гомер җебе өзелгән Касыйм шәһәре аның саен якыная бара. Юлдашларым, олпат галимнәр, милләт анасы турында тарихи фактларны, әдәби әсәрләрне, риваятьләрне барлый. Шуларның берсе башка кереп утырды да тәгәрмәчләр йөгергән көйгә зыр-зыр әйләнеп бара: яратмаган хатынына исемсез таш куйдырган...

Ханкирмән диләр аны...

Касыйм безне биткә бәреп яуган юеш кары белән каршы алды. Бәлки, Сөембикәне Мәскәүдән бирегә китергәндә дә нәкъ шундый шыксыз көн булгандыр. Кызганыч, анысы турында мәгълүмат юк. Тарих, гомумән, күп сорауларны җавапсыз калдыра. Сөембикәнең Җангалидән туган һәм Касыйм ханы Шаһгалигә асрамага бирелгән кызының язмышы хакында да дәшми ул. Ханбикәнең Касыймда яратмаган ир янәшәсендә үткәргән соңгы көннәре турында да әллә ни мәгълүмат юк. Хәтта кайда күмелгәнлеген дә төгәл генә итеп әйтми.

Шулай да тарихның Сөембикә турында хатирәсе бар. Нугай даласының сөекле кызы 14 яшендә (кайбер чыганакта – 17) Казан ханы Җангалигә кияүгә чыга. Татар халкы аны Сафагәрәйнең сөекле хатыны, ә ул вафат булгач, балигъ булмаган улы Үтәмешгәрәйнең опекуны сыйфатында ил башы булып калган кыю ханбикә, Явыз Иван белән тартышкан милли каһарман буларак белә.

Халык хәтерен яңарту ниятеннән, Касыйм шәһәрендә «Сөембикә – атаклы хатын-кыз һәм идарәче» дип аталган Россия күләмендәге фәнни конференция уздырылды да инде. Рязань, Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Архангельск шәһәрләреннән галим-голәмә җыелды анда. Шунысы куанычлы: бу чараны оештыруда Татар федераль милли-мәдәни мохтарияте, Татарстан мәдәният министрлыгы, проект авторлары Әлфия Рәхмәтуллина, Илдар Бикуевлар гына түгел, Касыйм татарлары үзләре дә башлап йөрде. «Биш ел элек шундый конференция уздырачаксыз, дисәләр, ышанмаган булыр идек», – диде алар. Менә Сөембикәне дә олыладылар. Касыйм шәһәре туристик маршрутка кертелсә (конференциядә бу хакта да сүз булды), бөек ханбикәнең язмышына игътибар тагын да артыр әле.


Һәр ташында сер яшерелгән Касыйм шәһәре турында бик аз беләбез әле.

Мәскәү белән Казан багланышларында зур роль уйнаган Ханкирмән – рус патшасы Василий Касыйм ханга бүләк итеп биргән кала. Тарихчылар әйтүенчә, 1152 елда нигез салынган Городец Мещерский 1376 елда янып көлгә әйләнгәч, ерак та түгел яңа кала калка – Яңа Түбән Шәһәр. Казан ханы олуг Мөхәммәтнең Мәскәүгә качып киткән улы Касыйм килеп урнашканнан соң, шәһәр аның исеме белән йөртелә башлый. Шулай итеп, тагын бер татар ханлыгы барлыкка килә.

Татар ханлыгы дип аталса да, Мәскәү куенындагы ханлык була ул. Явыз Иванның тугры колы – «курчак хан» Шаһгали мисалыннан да беләбез моны. Ханлык-







PRESSA.RU

ның соңгы идарәчесе Фатыйма-Солтан, христиан динен кабул итәргә уйлаганда, сарай әһле тарафыннан үтерелгән дигән фараз да бар. Моңарчы да Мәскәүгә карап яшәгән ханлык 1681 елдан статусын югалта.

Шәһәр үзе кала. Ни гаҗәп, хәтта совет елларында да аның исеме үзгәртелми.

Бай татар китапханәсе дә, татар мәктәбе дә тарихта гына калган.

Касыйм – татар дөньясына танылган шәхесләрне байтак биргән шәһәр. Гомәр Дәвишев – беренче профессиональ татар режиссеры. Сара Шакулова – татар хатын-кызларыннан беренче математик. Мөслимә булу сәбәпле, Россиядә югары белем ала алмый, шунлыктан атаклы Сорбонна университетына барып укый. Мәскәүдәге Асадуллаев йортында ачылган беренче татар мәктәбенең директоры буларак та билгеле әле ул. Әшрәф Синяева – «Сәйяр» труппасы актрисасы. Беренче адымнарын Мәскәүдә – рус театрында ясый, 1917 елда «Сәйяр»гә алына, соңыннан Казанда Кызыл Октябрь исемендәге беренче татар дәүләт үрнәк драма театрында эшли. Сәгъдия Булатова – Касыймда кыз балалар өчен беренче мәктәп ачкан мөгаллимә, 30 нчы еллар ахырындагы сәяси золым корбаны. 1955 елда, үзе вафат булганнан соң гына исеме аклана. Касыйм татарлары турында билгеле мәгълүматның күбесен укытучы Әхмәт Ишимбаев туплап калдырган. Касыймлылар бүген аның үзен дә зур хөрмәт белән искә ала – элеккеге мәдрәсә бинасында Ишимбаевның музей-почмагын да булдырганнар.

Бүгенге Касыйм

Имам белән яңа мәчеткә дә кагылып чыктык. Яңа, дип, 1906 елда салынган инде ул. Совет заманында манарасы киселгән, үзе клуб булып үзгәртелгән. «Шул клубта биегән әбиләр хәзер намаз укырга килә», – ди Морад хәзрәт. Аннан соң мәчет бинасында азык-төлек комбинаты, соңыннан кинопрокат булган. 2002 елда гына кабат манарасы торгызылган әле аның, ай куелган. Монысын инде Морад хәзрәт укып кына түгел, күреп тә белә: үзе дә шунда кайнашкан, кирпеч ташыган, измә болгаткан.

Җомга намазына утызлап кеше килә икән. Ә гает көннәрендә кеше саны 400 гә җитә ди. Мәчеткә генә сыймыйча, урамда да басып торалар икән. Шәһәргә 15 километрда гына урнашкан Подлипка авылында да мәчет торгызылган. Гомумән, Рязань өлкәсендә сигез мәчет бар, диделәр.

Наилә Дәвишева мәчет караучы булып эшли. Аллаһ йортын карап чыкканнан соң, аның «биләмәсе»нә – җыйнак кына аш-су бүлмәсенә кердек. Милли-мәдәни автономия әгъзалары еш кына монда җыелып, Наилә апа пешергән тәм-томнардан авыз итеп, гәпләшеп утыра.

«Мәчеткә кергән кешене чәй эчерми җибәрмим мин. Һәрвакыт бирәр тәм-томым әзер була», – дип, Наилә апа безне дә өстәл янына чакырды. Кечкенә генә гәүдәле бу апаны 90 нчы елларда Касыйм татарларының хәмер белән дуслашуына каршы көрәшкәндер димәссең дә. Ә ул көрәшкән!

«Сөембикә ханбикәнең дә заманында Касыймда яшәгәнен белеп үстегезме соң?» – дим. Әңгәмәдәшемнең күзләрендә очкын кабына – белмәскә инде! «Без үскәндә Сөембикә турында кычкырып сөйләү юк иде. Шулай да Касыймда аның эзләре калганын белеп тордык», – ди.

Галимнәр белән татарча сөйләшеп торуыбызны ишетеп, яныбызга Равил исемле бер абзый килде: «Менә тыңлап торам сезне, тик бер сүзегезне дә аңламыйм. Оят. Җиде яшемә кадәр авылда әби белән үскән малай бит мин. Ә әби русча бер авыз сүз белми иде. Мин дә беренче сыйныфка кергәч кенә өйрәндем аны. Аннары Касыймга күчеп килдек. Урамда гел русча аралашу инде, ничектер өйдә дә татарча сөйләшмәдек. Тел онытылды. Татарга өйләндем, тик ул да телне белми. Кызыбызга Марина дип исем куштык. Кызыбыз соңгы арада татар тарихы белән кызыксына: «Нигә татарча өйрәтмәдегез?» – дия башлады. Тиздән туачак оныгыбызга Марат дип исем кушарга һәм, аның теле ачылгач, бергәләп татарча өйрәнә башларга җыена».

Хан чорына кайттык

Татар урамы буйлап Ука елгасына таба төшәбез. Монда татар байларыннан калган ике катлы – аскы өле-







ше шома ак таштан, өске каты нык бүрәнәләрдән салынган йортлар шактый әле. Янәшәдә генә бер катлы кечкенә өйләр дә бар – анысында хезмәтчеләр яшәгән. Йортлар, тыштан нык күренсә дә, шактый бетерешкән, җиргә чүккән инде. Акка буялган агач тәрәзә йөзлекләре генә кичә ясалгандай, балкып утыра.

Урамны үтеп, ачык мәйданчыкка килеп чыгабыз. XV гасырда монда хан биләмәләре булган, соңрак татар бистәсе барлыкка килгән. Шактый озын бистәне ермак аерып торган. Ермак хәзер дә үз урынында, татар бистәсе генә юк.

Хан биләмәсенең иң матур, бөтен яктан күренеп торган җирендә борынгы таш мәчет утыра. Аның беренче каты Екатерина II заманында торгызылган, 180 ел элек, өстәп, икенче кат та эшләнгән. Ә манарасы мәчет төзелгән 1467 елдан бирле тора. Алты гасыр эчендә җил-яңгыр да, кеше кулы да тимәгән аңа.

Бу мәчеттә туган якны өйрәнү музее урнашкан заманны да хәтерли әле Касыйм халкы. Ул вакытта, ичмасам, даими рәвештә төзекләндерелеп тора иде дип уфтаналар. Хәзер шәһәр хакимияте тарафыннан ремонтка акча бүлеп бирү туктатылган, ишегендә – йозак.

Касыймга килеп, алты гасырлык тарихы булган манарага менми китү эшмени – текә баскычтан күтәрелгәндә шуны уйлыйм. Баскыч шулхәтле тар ки, кара-каршы ике кеше очрашса, үтәрлек тә түгел. Алтмыш басманы санап, ниһаять, кечерәк кенә мәйданчыкка килеп чыгабыз. Бөтен Касыйм – уч төбендә. Менә элеккеге татар бистәсе, әнә генә мәдрәсә, Шаһгали төрбәсе... Нәзек тасма булып Ука җәйрәп ята. Хозурлык!

Манарадан аска карасаң, хан чорыннан калган икенче архитектура истәлеге – Шаһгали төрбәсе (касыймлылар төрбә дими, тәкия дип атый аны. – *Авт.)* күренеп тора. Сөембикәнең кайда җирләнгәне төгәл билгеле түгел. Шулай да касыймлылар юрганны үзләренә тарта: ханбикәнең кабере Касыймда, диләр. Шаһгали әле үзе исән чакта ук, 1555 елда, таштан тәкия салдыра, үзен, якын кешеләрен шунда җирләргә боера. Эре таштан дүрткырлы итеп салынган, тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган төрбәгә узабыз. Башкаларга сиздерми генә гасырлар тузаны сеңгән ташларга кагылып алам.

Менә бормалы гарәп хәрефләре белән чуарланган кабер ташлары. Чынлыкта, төрбә ике катлы. Беренче катында кабер ташлары гына, ә җәсәдләр аскы каттагы җиргә җирләнгән. Монысы Шаһгалинең ташы дип күрсәтә өлкә мөхтәсибе Рәшит Бултачеев. Ә бер кабер ташы башкалардан аерылып тора: үзе озынча, тар, үзе исемсез. Яратмаган хатынына исемсез таш куйдырган микән?

Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков 1983 елда Касыймга беренче тапкыр килүен искә алды: «Ул вакытта безне озатып йөрүче булмады. Тәкияне үзебез эзләп таптык. Ишеге ачык, эчендә сарыклар йөри иде. Казанга кайткач, бу хәлдән зарланып хат яздык, шуннан соң гына төрбәне чистарттылар, бикләп тота башладылар».

Төрбәдән – мәчеткә, ә аннан елгага таба җир асты юлы булган, диләр.

Төрбәдә җирләнгәннәрнең рухына дога кылдык. Сөембикәне дә онытмадык. Монда җирләнгәндермеюктырмы – анысын галимнәр ачыклар, тик аның мәңгелек урыны кайда икәнлегә бәхәссез – һәр татарның йөрәгендә ул. («Архангельск» музеенда Юсуповларның нәсел тамырлары турында язылган китап саклана. Музейның директор урынбасары Людмила Гринева үзе алып килде аны. Сак белән! Сөембикә турында да юллар шактый анда. Ул болай тәмамлана: «Ханбикә каберендәге ташка исеме язылмаган. Аның өстендә һәр ел саен шомырт һәм сиреньнәр генә чәчәк ата...»)

* * *

...Шаһгалинең нияте тормышка ашмый. Сөембикәнең эзе җуелмый, киресенчә, елдан-ел хәтергә ныграк уела бара. Конференциядә катнашучылар Касыйм каласында ханбикәгә һәйкәл кую турында карар да кабул итте әнә. (Ә без дүрт күз белән шундый һәйкәлнең үзебездә – Казанда булуын көтәбез.) Хан мәчете урнашкан тау битендә – сөймәгән иренең төрбәсеннән уң кул якта урын алачак ул. Горур карашын Ука елгасына төбәп, бөтен барлыгы белән үзенең бөеклеген күрсәтеп торыр Сөембикә. Милләт анасы турында тарихның әйтер сүзе тагын табылыр әле.

Казан–Касыйм–Казан.



■ Заманында Касыймдагы Кастров мәдрәсәсенең даны еракка таралган була. 1808 елда хан мәчетенең имам-хатыйбы Габделвахит Дәүликамов башлангычы белән нигез салынган аңа. Соңыннан имамның улы Фазлулла 20 ел әлеге мәдрәсәдә шәкертләргә белем биргән. Башта мәдрәсә Дәүликамовларның йортында урнашкан була, 1818 елда Салих Шакулов төзеткән берсе таштан, икенчесе бүрәнәдән салынган биналарга күчә. Ә 1868 елда Сәйфулла Кастров исемле бай мәдрәсә өчен хан мәчетеннән ерак түгел таш бина салдыра. Әлеге бина бүген дә исән. Бүген ул милли-мәдәни автономия карамагында. Җәдитчә укыту да иң элек шушында башланган. Рязань, Тамбов, Пенза, Сембер, Казан, Әстерхан, Уфа губерналарыннан да килеп укыйлар анда. Язучы Закир Һади дә шушы мәдрәсәдән чыккан. Бинаның эчендә татар көнкүрешенә, Касыйм татарларына, халыклар дуслыгына багышланган музей-почмаклар урын алган. Татар теленнән кала, гарәп теле, пәйгамбәрләр тарихы да өйрәтелә икән монда. «Йөрүчеләр шактый, олылар да, кечеләр дә килә», – диде Морад хәзрәт. Моннан соң Коръәнне үзебезчә укый башларлар дип ышанасы килә – Россия Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов касыймлыларга Изге китап бүләк итте.

PRESSA.RU

Кавказ тауларына сыенып утырган Кабарда-Балкар Республикасында – таулар илендә тугандаш төрки халык балкарлар яши. Әлеге горур, хөр халык чал Эльбрустан, йөгерек Терек суларыннан, мәгърур Чегем тарлавыгыннан, карлы тау түбәләреннән, чәчәкле үзәннәрдән үзенә илһам, көч-дәрман ала. Холыкта, хисләрдә, сүзләрдә чагыла ул. Балкар шагыйрәләре Тәнзилә ЗУМАКУЛОВА, Сәкинәт МУСУКАЕВА, Сәфәрият ӘХМӘТОВА шигырьләрен Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА тәрҗемәсендә тәкъдим итәбез.

ҖЫР КАЛАЧАК ТАУЛАРДА

Сәкинәт МУСУКАЕВА

Ничек кыска бу гомерләр

Якын, ерак ханлыкларны,
Күп, аз санлы халыкларны,
Вакыт тели тигезләргә.
Безне дә ком-тузан итеп
Җәяр таулар түбәсенә,
Сибәр тиңсез диңгезләргә.

Ни калырмы? Калачак җыр,
Нигезендә калачак чор,
Җыр калачак бу тауларда.
Сәлам әйтәчәк сауларга
Киткәннәрдән, үткәннәрдән,
Шунда гомер иткәннәрдән.

Ничек кыска бу гомерләр,
Кеше булып үтү өчен!
Йолдызларның ераклыгы,
Мөмкинлекләрнең азлыгы,
Бер җырлата, бер елата,
Күккә дисәң, җиргә ата.

Йолдыз кыйпылчыгы янганда

Оялгандай болыт артына
Кереп качкан күктә йөзгән ай.
Мин баралмам синең янына,
Сөю янып беткәч шушылай.

Ә өемдә – кара мендәрдә
Йолдыз кыйпылчыгы янамы?
Әрнүләрен тирән яшереп
Елый – җаны тоташ ярамы?

Көтелмәгән кунак шикелле,
Нурга манып тәрәз күзләрен,
Кояш керде минем бүлмәмә,
Һәм көч алды шуннан сүзләрем.

Караңгылык куган Өметем
Минем өйгә кайтты яңадан.
Адашкан Хыял – Өмет юлдашы.
Араладым кабат карадан.

Юк, алардан берни сорамам,
Ә сорарга кирәк, ди, нигә?
Мин куанып чыгам матәмнән,
Алар икәү бергә килгәнгә.

Пәлтәләрен чөйгә эләмен,
Башмак бирәм, сез, дим, ни хәлдә?
Баллап чәйләр эчәрбез аннан,
Җанга җиңел булыр шул мәлдә...

Туган җирем дисәм

Ак томан изрәткән иртәдә,
Авылым уянган чагында,
Тауларга юнәлде әтием.
Бу – күптән... Юнәлде атында...

Ә таңда тик тояк тавышы,
Әнием тәрәзә катында.
Атамны озатты карашы,
Төбәлде җилдергән атына.

Әбием намазлык өстендә,
Кадерле дисбесе кулында.
Берни дә кирәкми иде күк:
Алар бар гомерем юлында!

Уянсам – төньягым бик якын,
Бер сурәт кышын да, язын да.
Күземдә кояштан өзелгән
Яфраклар минем бар ягымда.

Ул кояш нурлары өемдә,
Сузылып үрелеп аласы.
И көлде әнием: «Кояшның
Нурларын тотмакчы, карачы!»

Тәрәздән үрелсәң – алмалар,
Шафран алмалары татлы ла!
Бакчада өрекләр, шәфталу,
Һәммәсе – хатирә, якты ла...

Күр, ялантәпием чыланды,
Майларның и җылы яңгыры!
Бу кызның чәчләре, толымы
Би-и-к озын үссен дип ягуыры!.

* * *

Сине күргәч, таш йөрәк тә эрер,
Сараннар да изгелектә йөрер,
Яхшылыкның булып өлгесе.
Сине күргәч чыдармы икән дисең,
Матурлыкның чын бәһасен белгән
Патша кызларының көзгесе?!

Синең кебек чибәрләр аз җирдә.
Ялган белән хаклык атлар бергә,
Гүзәллеккә синең алданып.
Ә югыйсә яшәү кыйммәте – син,
Кемдер йолдыз эзләр сөюгә тиң, –
Мәхәббәт дип торыр ул янып.

Сине күргәч, Кояш иңеп китәр,
Һәм аклану эзләр моннан битәр,
Ай да батмас, күрер бик азлар.
Сары йөзе белән җиргә багар,
Икесенә бер юаныч табар,
Алан итәкләрен җил назлар...

Сине күргәч, картлык та адашыр,
Заман белән аннан ул талашыр,
Яшьлек исә һаман ялгышыр.
Гашыйкларның юлы –
каһарманлык,
Нарталарда сәфәр чыккан гашыйк
Дан яулыйсы килеп ярышыр.

Сине күрсә суын ташлап чабар,
Сиңа таба чишмә бер юл табар,
Куак чәчәк атар кышларын.
Җир йолдызга үрелер – хыял биек!
Яшәү ничек матур икән, диеп,
Йөрәк кертмәс хәсрәт-моң карын...

Сәфәрият ӘХМӘТОВА

* * *

Гөл бәйләме китерде җил.
Китерде яшь кәләшкә.
Егылды, чәчелде гөле,
Җилне монда кем дәшкән?

Мин бәхеткә тиендем күк,
Төштәге күк яшәрдем.
Бу гөлләр миңа түгел шул,
Дигән уем яшердем...

* * *

Мине кадерләгән сөйгән ярым,
Кагылып кына киткән кулларыңның
Нәфисләгеп тоеп һушны җуйдым.
Күкрәгемдә ике ак төнбоек
Сөюемнән тибрәнепләр куйды...

* * *

Бар минем моңлы гитарам –
Биш тарлавыгы илемнең.
Кыллары – көмеш елгалар,
Тар сукмак – юлы каләмнең...

* * *

Яшәү, ничек сәерсең син,
Кояш чыкты да батты.
Таңда балкыган нурлардан
И күзләрем камашты.

Көнем, бигрәкләр сәерсең:
Күренден дә югалдың.
Гүя канат җилпегәндә
Кызыл гөл үрелеп алдым.

Гөлне кулыма тоттым да
Карадым нур-күзенә.
Ул йөрәктә мәңгелеккә
Урын алды тиз генә.

И гөлем,
Сөйләш минем белән,
Чәчкә сөйләшкәндәй җил белән...

* * *

Яуган карга исемем язган кебек,
Дәфтәреннән сызар замана.
Шуннан карда умырзая шытар,
Яшел үлән чыгар – өр-яңа.
Бик килсә дә мәңге каласы,
Таңга кадәр шунда колач җәеп
Биер бары Үлем Алласы.

Тәнзилә ЗУМАКУЛОВА

Тау кызы җыры

Тау ягының төне –
Кара толымнарым.
Төннәр бирде миңа
Бүләк итеп барын.

Сабыр гына аккан
Изге агымнары
Тау кызына садә
Күңел бирде бары.

Күзләремә минем
Юмарт таңнар бакты.
Алсулыгын алар
Битләремә якты.

Илем бирде миңа
Нәфис гөл аклыгын.
Ташлар ныклыгын һәм
Болыт йомшаклыгын.

Кардан да ак тәнем!
Йә, ни диим моңа?!
Кошлар җырлый-җырлый
Моңын бирде миңа.

Күгәрченнән игелек
Алдым мин – тау кызы.
Бөркет горурлыгы
Иңде барын узып.

Үз илемнең төсе,
Бар байлыгы миндә.
Юмарт бүләкләде.
Тик бик азга инде...

Кара толымнарым,
И актан-ак тәнем,
Барысын да кире
Бирәм, – бөтен ямем.

Бөтенесен бирәм,
Яшьлек белән алдым.
Таңнан, күгәрченнән,
Таштан, бөркет данын.

Чишмә буенда син
Утырырсың беркөн.
Суда садәләгем
Чагылыр дим, бәлкем...

* * *

Әле буран, әле җиле –
Кыш алып килгән золым.
Бишегеңә иелдем дә,
Миңа шулкадәр җылы.

Ә тышта этләр өрәдер,
Этләр беркемне көтми.
Бишегеңә иелдем дә,
Мине беркем өркетми.

Кемнәрне генә күрмәдем,
Дип хәзер искә алам.
Хәер, барысын онyттым,
Күкрәккә кыскач балам.

Елмаеп кына куйдың да,
Җаныма нур уралды.
Үрелдең дә миңа, балам,
Хәсрәтләрем таралды.

Йоклыйсың, ак бишегеңнән
Өйгә җылы нур сибеп.
Җирдә золым да, кайгы да
Һәм буран да юк кебек.

* * *

Бик кычкырма инде
йотлыгырсың,
Абынырсың, диләр, ашыкма.
Сүрән генә юеш үлән төти,
Коры үлән яна ачыкта.

Юк, аларга һич охшыйсым килми,
Ә башка юл бармы, уйласаң?
«Беркемне дә җылытмыйча җирдә
Пыску нигә?» – дигән уй баса.


Зәринә Идрисова,
Томск


Анжела Абдрәшитова,
Төмән


Тәнзилә Смелова,
Түбән Новгород

ГЫЙНВАР

Д		4	11	18	25
С		5	12	19	26
Ч		6	13	20	27
П		7	14	21	28
Ж	1	8	15	22	29
Ш	2	9	16	23	30
Я	3	10	17	24	31

ФЕВРАЛЬ

1	8	15	22	29
2	9	16	23	
3	10	17	24	
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	
7	14	21	28	

МАРТ

	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	

ИЮЛЬ

Д		4	11	18	25
С		5	12	19	26
Ч		6	13	20	27
П		7	14	21	28
Ж	1	8	15	22	29
Ш	2	9	16	23	30
Я	3	10	17	24	31

АВГУСТ

1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	
7	14	21	28	

СЕНТЯБРЬ

	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	
4	11	18	25	

2016

«Сөембикә» — сезнең журнал,



Алия Әпсәләмова,
Чиләбе өлкәсе


Юлия Юртеева,
Чиләбе өлкәсе


Алисә Әхмәтҗанова,
Ижау



Алинә Аптукова,
Пермь крае



Алсу Алтынбаева,
Кемерово өлкәсе



Миләүшә Морзаханова,
Татарстан, Түбән Кама

«Татар кызы-2015» Бөтенроссия гүзәллек бәйгесендә финалга чыккан сылулар

АПРЕЛЬ

	4	11	18	25
	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	

МАЙ

	2	9	16	23	30
	3	10	17	24	31
	4	11	18	25	
	5	12	19	26	
	6	13	20	27	
	7	14	21	28	
1	8	15	22	29	

ИЮНЬ

	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	
4	11	18	25	
5	12	19	26	

ОКТЯБРЬ

	3	10	17	24	31
	4	11	18	25	
	5	12	19	26	
	6	13	20	27	
	7	14	21	28	
1	8	15	22	29	
2	9	16	23	30	

НОЯБРЬ

	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	

ДЕКАБРЬ

	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	

туташлар һәм ханымнар!


Язылу индексы: 73002



Альбина Хаматова,
Башкортстан, Туймазы



Ләйсән Усманова,
Ульяновск



Ралина Галимьянова,
Мари Иле, Йошкар-Ола





Ландыш
ӘБҮДӘРОВА

PARDONNE MOI яки ПАРИЖДА ОЧРАШЫРБЫЗ

(Хикәя)

Диана йолдызлар арасында калды. Трактор арбасына төялгән яңа печән: исе тәмле, үзе түшәк кебек йомшактыр инде. Шулкадәр арылган, аның җеп өзәрлек тә хәле юк. Бүген алар печән эшен төгәлләп кайтып баралар. Соңгы йөккә печән күп калган, арбага сыйдырабыз дип, таптый-таптый озаклап төяделәр, йөк авыр, биек. Караңгыга да калынды. Тигезле-тигезсез бормалы-сикәлтәле кыр юлыннан трактор, арбасы-ние белән бер яктан икенче якка авыша-авыша, акрын гына кайтып килә. Печән бетте! Шушы уй Дианаңың күңелен дә, тәнен дә җылыта, соңга калынса да, көне буе эссе кояш астында кибән өстендә торып, кичкырын йөк төягәндә, трактор арбасында таптанырга туры килсә дә, ул зарланмады, түзде. Менә хәзер йөк өстендә чалкан ятып, бәллүдәге кебек тирбәлә-тирбәлә кайтып бара. Ире Фәрит кабинага утыр дигән иде, үзе баш тартты. Күк йөзе аяз, яңгыр яварга җыенмый, ятып, ял итеп кайтам, диде. Фәрит тракторны әйбәт йөртә. Ашыкмыйча, җайлап кына кайтыр, бу юлларны ул төнлә күзен бәйләп җибәрсәң дә үтә аладыр – ел саен йөзләрчә мәртәбә үткән юлы ул аның.

Төн аяз бүген. Йолдызлары чекерәеп тора. Романтикага биреләсе килә, хыялларга чумып аласы. Әле тагын кайчан шушылай бөтенесеннән биек булып, йолдызларга якынаер иде? Үрелсәң, чүпләп алырга да була бит. Кулны гына сузасы. Ләкин шулкадәр арыткан икән, бармак та селкетәсе килми. Бары тик эреп югалганчы изрисе генә килә. Эх! Парижда Эйфель манарасының иң очында да йолдызлар шушылай якындыр инде. Менә хәзер могҗиза булсын, әйтик, каршыга әкияттәге Җен килеп чыксын иде дә: «Иң зур теләгеңне әйт!» – дисен иде. Диана әйтер иде, икеләнеп тә тормыйча бер мизгелгә генә Парижга алып

барып кайт, дияр иде. Дигананың чынга ашмаган иң зур хыялы – Парижга барып, Эйфель манарасына менү. Могҗиза булышса гына инде... Диана үзалдына елмаеп куйды. Хәер, бик күп хыяллары чынга ашмый калды аның. Яраткан кешесе белән гомер кичерергә дә насыйп булмады, тәрҗемәче булып, илчелектә дә эшләмәде, төрле илләрдә сәяхәттә дә йөргәне юк. Аның каруы, бәхетле ул үзе. Һәрхәлдә, бәхетсез түгел. Кайчандыр: «Барыбер бәхетле булам!» – дигән анты үтәлде анысы. Кара әле, үз-үзенә шушы антын биргән көннән соң, нәкъ ун ел вакыт үткән инде. Париж хыялы юкка гына искә төшмәгәндер. Кайчандыр алар яшьлек мәхәббәте белән, ун елга бер тапкыр булса да, Парижда Яңа ел бәйрәмен каршыларга сүз куешканнар иде. Яңа ел бәйрәмен! Парижда! Һәм берничә карамыйча.

Ун ел үткән, ун тапкыр Яңа елны каршылаганнар, тик менә Парижда гына түгел. Парижга барып, Яңа ел каршылау түгел, Диананың Европага аяк басканы да юк әле. Кая ул, Казаннан да ераграк китә алганы юк. Әле менә җәйнең кап уртасында, төн караңгысын ертып, трактор арбасында кайтып бара. Өстендә вьетнам базарыннан кара эшкә киярга ярар әле дип алган арзанлы футболка белән ыштан, аягында – галошлар. Өстенә Фәритнең телогрейкасын ябынган. Дулкынланып торган озын чәчләре яулык астына төйнәп куелган килеш.

Ә ул нинди икән? Һаман да шыгырдап торган ак күлмәк белән кыйммәтле джинсы чалбар киеп йөриме икән? Урын-җире атлас-ефәктән микән? Беренче зур мәхәббәте, яратып-сөеп йөргән егете Руслан турындагы соңгы хәбәрне моннан тугыз ел элек ишеткән иде ул: Руслан Мәскәүдә, зур гына урында эшли, өйләнгән, диделәр. Шуннан соң Диана аның турындагы хәбәрләрдән ераграк яшәргә тырышты. Өйләнгән икән, өйләнгән. Диананы ташлаган икән, ташлаган. Узган эшкә салават, диләр; кат-кат актарырга әби сандыгы түгел лә ул хатирәләр, дип, ул яшьлек хисләрен күңеленең иң тирән түренә бикләп, шалтырап йөдәтмәсеннәр өчен ачкычларын яшереп куйган иде. Менә бүген саксыз кагылыпмы, арыганлыктанмы, кайчандыр бирелгән вәгъдә келт итеп искә төште: Париж...

Ун ел элек Диана Русланга кияүгә чыгарга тиеш иде. Икесе дә шәһәр балалары, интеллигентлар гаиләсеннән. Ипинең иген кырында үскәнен белгәнчегә кадәр, Диана опера һәм балет театрының репертуарын яттан белә иде. Руслан да сәнгать белән кызыксына торганнардан. Ул сынлы сәнгать белән мавыга. Дианага да ул рәссам күзләре белән гашыйк булган иде. Озын, нечкә буйлы, җиңел гәүдәле, ак йөзле, зур күзле, йомшак карашлы кызны бер күрүдән ошатты егет. Кыз да чандыр гәүдәле, чибәр йөзле Русланны бик тиз үз итте. Егеткә ул торган саен ныграк тартыла иде, икесе дә сәнгать тирәсендә йөргәч, еш очрашалар. Тора-бара очрашуларны эзли башладылар, берничә тапкыр күрешкәннән соң, Диана Русланга үлеп гашыйк булды. Чит телләр факультетының соңгы курсында укып йөри, эш эзләргә вакыт җиткән, киләчәкне кайгыртырга кирәк иде инде ул елны. Диана Русланнан җитди адымнар көтте, егет белән үткәргән романтик кичләр Дианага аяз күкле бәхетле гомер вәгъдә итә иде. Соңгы елда кыз ваемсыз сәнгать тормышына шулкадәрияләште ки, башка төрле яшәргә туры килер дип башына да китермәде. Шуңа да Эйфель манарасы янында сәгать телләре артыннан уникене санап бару берничек тә чынга ашмастай хыял категориясенә эләгә алмый иде. Аның өчен башка тормыш мәгънәсез һәм төссез, гомумән, ул юк иде. Тормыш ул дигәнчә генә бара, аның шулай булуы табигый да: әти-әнисе аны кечкенәдән иркәләп кенә үстерде, кулы авыр эшкә тимәде, нәрсә ашыйсы килсә, шуны ашады, нәрсә киясе килсә, шуны киде, барасы килгән җиренә барды – Диана бу тормышта күкәй сарысы кебек кенә иде әле. Йомырка кинәт ватылды, күк йөзен яшен телгәләп үткән кебек, Диананың дөньясы да чатнады. Әллә нәрсә булмады да кебек, ләкин Диана өчен дөнья бетүгә тиң иде ул: аны Руслан ташлап китте. Аңлатып-нитеп тормады, шулай кирәк, диде дә китте. Диана туй күлмәге тектерергә дип алган ак ефәкләр арасында тораташ булып басып калды. Ул мизгел Диананың хәтерендә бер картина булып истә калган. Ун ел элек тә Диана үзенә шулай читтән карап торган иде. Картина бер дә үзгәрмәгән, төсләре дә уңмаган, Руслан картинасы... Мәхәббәт бетте, ә гомер дәвам итә иде әле. Көннәрдән бер көнне Диана дөньяга күзләрен күтәреп карады һәм үзе артыннан йөрүче Фәритне күреп алды. Бу егет аңа күптәннән күз атып йөри иде шикелле. Руслан барында кыз аны күрмәде дә, белмәде дә. Диана яши торган йортта бер фатирга кергән ул, акча түләп тора. Авылныкы булып чыкты. Җебеп тора торганнардан түгел икән үзе, кызның ялгызы гына кайтып-китеп йөрүен абайлап алу белән, беренче булып сүз катты. Фәритнең гаҗәпләнүенә каршы, кыз ялындырып тормады, очрашырга ризалыгын бирде. Йортта имеш-мимеш тиз таралды, Диананың әтисе белән әнисе гаҗәпләнебрәк калсалар да, кызларының авыр карашы аларны тиз күндерде. Фәрит артык күп сүзле түгел, әмма көр күңелле чын авыл егете. Өстәвенә, баш югалтырлык дәрәҗәдә Дианага гашыйк. Ул да быел укып бетерә, агроном булачак. Димәк, авылга кайтасы кеше... Ә иң мөһиме – ул беркайчан да, беркайчан да аны ташламаячак. «Син мине ташлама», – ди ул кич саен Дианага, кызның нечкә озын бармаклы кулларын җылы, көчле учларына алып. Аның көчле куллары, тыгыз тәне чем-кара ыспай костюмы аша да беленеп тора. Диана янына ак күлмәктән генә килә. Аяк киеменә дә тузан кундырмый. Зәвыклы итеп киенә белә үзе. Көн саен чәчәк бүләк итә. Хәтта бер тапкыр балетка да алып барды. Дөрес, көч-хәл белән түзде, театрның йомшак урындыгында йоклап китмәс өчен тырышырга туры килде

PRESSA.RU

үзенә, әмма түзде бит! Диплом алган көнне Дианага тәкъдим ясады, һәм кыз, шуны гына көткән кебек, риза булды. Диананың тешләрен кысып: «Мин барыбер бәхетле булам!» дигән антының беренче адымы шушы булды.

Күкрәгендәге утлы ташны учына кысып, кияүгә чыкты да авылда яши башлады Диана. Әти-әнисе башта каршы төшеп караган иде. Фәрит кызларын сорарга кергәч, әнисе Лилия ханым кызын аш бүлмәсенә алып чыгып китеп сөйләште: «Үзең турында гына уйлама, егет акыллы, төпле күренә. Аның тормышын җимермисеңме? Ныклап уйладыңмы?» – диде. Диана дәшмәде. Бәхетле булыр өчен кичектермичә ниндидер адым ясарга кирәк иде бит инде, алдагысын күз күрер, дип карар итте ул. Әтисе Фәриткә сүз катып карады. «Син – авыл егете. Авылдан китмим, дисең. Диана – шәһәр кызы, авыл тормышына күнекмәгән. Күнекмәгән дию генә аз, ул хәтта кер дә чайкый белмидер әле», – дип сүз башлаган иде, Фәрит көлде генә. «Анысы өчен борчылмагыз, кер юу машиналары безнең авылны гына урап узмады, су өйгә үк кергән, җылысы да бар. Бәдрәф, мунча дип тә тышка чыгып йөрисе юк», – дип күндерде. Лилия апа кызының кайнана белән торасын белгәч, янә бер уфтанган иде, булачак кодагыйны күргәч, тынычланды тагын. Кодагый тиешле кеше бик күркәм холыклы хатынга охшаган, күзләрендә әллә нинди эчке бер сабырлык бар. Диананы җәберсетмәс, яхшы кайнана булыр, дип, барысын да Ходайга тапшырды...

Цивилизация дисәң дә, авыл авыл шул инде. Беренче көннәрдә Диана үзе өчен бу ят дөньяны өйрәнеп кенә йөрде. Ошый идеме аңа, әллә тормышына кинофильм итеп читтән карый идеме, шул кинода үзе героиня идеме – аңлашылмый. Шуңа да яшь хатын бу уйлардан качарга тырыша иде. Ире дә, кайнана белән кайната да яхшы, җайлы кешеләр. Шулай да Диана үзенең килен кеше икәнен онытмый, нинди эш бар, дип кенә тора. Аш пешерү аның өстендә. Тик көнгә өч тапкыр аш әзерләү туйдыра икән. Кайнанасы тыштагы эшне карый. Анда кошкорт та, мал-туар да бик күп. Өстәвенә, офыкка тоташкан бакча да бар әле. Көз җитеп килә, җиләк-җимеш ишелеп уңган, яшелчәләр чират тора. Авыл кешесе бу кадәр эшкә ничек өлгерә икән соң? Шаккатарлык бит. Яңача яшәп карау белән мавыгып, Диана күңелендәге бушлыкны да оныткандай була. Ләкин бу бетмәс-төкәнмәс эшләрнең озын чираты да аның күңелен әллә ни җилкетми: бертуктаусыз ихатада мәшәкатьләнеп яшәүнең ни мәгънәсе бар инде? Беркөн шулай казлар куарга дип урамга чыккан иде. Кояш баеган вакыт, офык куе кызыл. Күңелгә төпсез сагыш ярып сала торган кызыллык. Диана ул якка карамаска тырышып кына казларны куа башлады. Ләкин тегеләре нишләптер, яшь хатынны тыңлыйсылары килмичә таралдылар да беттеләр. Теге яктан куып карады аларны Диана, бу яктан – көтүне җыя алмыйча аптырап бетте. Ата казы усал, җитмәсә, ысылдарга гына тора. Якын килерлек тә түгел. Шул вакыт капка төбенә Фәрит кайтып туктады. Фәрит алдында сер бирмим дип, Диана казларга якын ук килгән иде, ата каз, талпына-талпына, үзе аңа һөҗүмгә күчте. Диана казлар яныннан чырылдап качты. Көлмәде дә инде югыйсә Фәрит үзеннән, киресенчә, Дианага ярдәмгә ашыкты, ләкин хатын шундый гарьләнде, иренә күтәрелеп тә карамыйча өйгә йөгереп кереп китте. Туп-туры бүлмәләренә керде дә, бикләнеп, үкереп елый башлады. Күз яшьләрен болай гына тыярлык түгел, ауныйауный елар вакыт җиткән иде, ниһаять. Кинонның беренче өлеше тәмам иде булса кирәк. Нишләде ул?!

Сабыр кайнана эшнең нидә икәнен тиз төшенде. Улын да бүлмәгә кереп барган җиреннән ым кагып кына туктатып калды, еласын – бушансын, дияе иде. Булачак киленнең йөрәгендә яра барлыгын бер караштан ук сизде ана кеше. Күңеле буш түгел бу багалмасының. Кызның Фәритен яратып чыкмавын аңлады, ләкин туйны туктатмады. Фәритенә каршы төшеп, өйләндерми калса, улы өйләнәм дип башка кайтмаячак иде. Нәселләре белән шундый алар. Атасы да шундый үзсүзле булды аның: Нәфисәне әнисенең ай-ваена карамыйча алып кайткан иде Камил. Фәрит үзе бик ярата хатынын, әлегә кадәр киленгә дә сүз әйтерлеге булмады. Яратам, дип, хисләр белән яшәмәсә дә, улын хөрмәт итә, торабара яратыр әле, яратмаслык түгел аның улы, дип сабыр итәргә булды. Аны-моны сиздермәде, канәгатьсезлек белдермәде. Ярар, казларны гына ябардай кеше табылыр әле, сыерын да үзе савар, көтүен дә куар Нәфисә. Авылда аның килененә «иностранка» дигән кушамат тагарга өлгергәннәр бит инде, мәктәптә чит телләр укытачагын белгәнгәме, әллә Диананың кыяфәтенә, үз-үзен тотышына, киенү рәвешенә карапмы икән – боларын төпченеп тормады ул. Ярар, тора-бара күз күрер, Фәрите генә бәхетле булсын, ник шунда «инопланетянка» димиләр дип юанды кайнана.

Фәрит исә көтте. Диананың күзләрендәге салкын сагыш аны өшетә иде, ул хатыныннан җылылык көтте. Атналар үтте, айлар... ел үтеп бара. Хатын буларак бер тамчы да үпкә-кинәсе юк аның Дианага карата. Башканы яратасың, шуңа миңа игътибар итмисең, дип әйтерлеге дә юк. Диана ирен игътибарсыз калдырмый, һәр адымын башта ире белән киңәшә. Ләкин бу ярату түгел, бу ихтирам итү генә. Бер тапкыр да «яратам» дип әйткәне юк бит әле аның. Карашлары һаман җылынмый. Көннәрдән бер көнне шактый гына «җылынып» кайтты. Ул көнне салкынлык ничектер сизелмәде кебек. Тора-бара кызмача кайтулары ешайды Фәритнең – үзенә юанычны шешәдән тапты ул. Диананы кызганса да, үзен-үзе тыя алмады. Күршеләрендәге Илнар белән Гөлнара кебек түгел шул алар: тегеләре исә бер көнне савыт-сабаны шалтырата-шалтырата талаша-

лар, икенче көнне инде күгәрченнәр кебек гөрләшәләр. Кайчак Фәритнең башына да кыздырып алу турындагы гөнаһлы уйлар кергәли. Бигрәк тә салмыш килеш кайтса. Ләкин хатынын күрүгә тыелып кала – Диана башка шул ул, бер тапкыр кул күтәрәсең икән – беренчесе һәм соңгысы шул була инде. Ул Гөлнара кебек сугарга күтәрелгән кулны каерып ала торганнардан түгел, күгәргән урыны булса, Гөлнара кебек, медаль таккандай да йөрмәс.

Диана исә үзен гаилә тормышының бар ягына да әзер дип уйлаган иде. Ялгышкан булып чыкты. Фәритне аракы белән дуслашып китәр дип һич көтмәгән иде ул. Гаиләләрендә дә эчкән-ниткән кеше юк бугай. Гаепнең үзендә икәнен яхшы аңлый, ләкин нишләргә белми иде Диана. Кайнанасыннан уңайсыз, ярый ла анысы әлегә дәшми. Аның, гомумән, исерек кешеләр белән аралашу тәҗрибәсе юк. Руслан белән очрашкан вакытта эчештерә торган дуслары бар иде барлыгын, ләкин алар башка иде – «культурный алкоголиклар»... Эчәләр-эчәләр, эчкән саен күңелләләнә генә баралар. Фәрит исә эчкән саен йомыла, онытылыр өчен эчә. Эчеп кайта да, өйгә кермичә, баскыч төбендә башын иеп утыра. Әнисе чыгып дәшә, Диана чыга. Шуннан соң күпмедер вакыт үткәч кенә керә. Хатыны ул кергәндә утларны сүндереп яткан була инде, ләкин Фәрит кереп ятмыйча керфек тә какмый. Шулай да йокламаганын сиздерми, күбрәк аркасын куеп ята. Иртә белән Фәрит аны-моны аңлатып тормый, таң белән эшкә китә. Мондый кичләр ешрак кабатланган саен, Диананың чарасызлык хисе көчәя генә. Чарасын күрергә кирәк, чыгу юлын табарга кирәк бит инде бу бәҗрадан?! Нигә эчәсең син, дип сорар иде ул Фәриттән, җавабын үзе дә белә кебек. Һәрхәлдә, гоманлый. «Син», – дияр Фәрит. «Мин китсәм, туктарсыңмы соң?» – дип сорар ул. Фәрит ни дияр икән? «Ташлама», – дияр микән элекке кебек? «Кит», – дисә? Ул чагында Диана нишләр? Китәр дә, тормышын яңадан башлармы? Тагын килеп чыкмаса? Әйткән иде аны әнисе... Шундый кичләрнең берсендә ул Фәриткә таба борылып ятты. Фәрит, кереп, шыпырт кына ятарга җыенып йөри иде, Диана кече утны алдырды. Сискәнеп китте ире. «Фәрит, әйдә, җир алып, шунда үз эшебезне башлап карыйк әле», – дип сүз катты яшь хатын иренә. «Нигә эчәсең? Башка эчмә», – дип акыл сатмады, үгетләмәде, ялынмады, күз яше түкмәде. Аның каруы, иртән Фәрит фермер булачакмын дигән ныклы карар белән уянды. Ходай рәхмәте, аракы белән дә дуслыгын өзде шул көннән соң.

Диана менә ун ел инде үзенә килен буларак та, ир хатыны буларак та тел-теш тидертми. Кияүгә чыгып ике ел үтүгә малай алып кайтып сөендерде. Авырлы икәнен белүгә башта аны янә чарасызлык хисе биләп алды. Бетте, дип уйлады ул, Париж да бетте, кино да... Соңыннан гына, йөклелек халәтенә



Рәсем: Гөлнарита Камалова

PRESSA.RU

иялəшкəч кенə бу хислəреннəн оялгандай итеп йөргəн иде. Тормыш дəвам итə икəн бит, ул телəгəнчə үк булмаса да, бəхетнең дə, мəхəббəтнең дə башка төсмерлəре була икəн. Аның каруы, Фəриткə канатлар куйдылармыни? Очып кына йөрде яшь ир. Дəү əтисенең башы сөенеченнəн күккə тиде. Дəү əнисе улының бəхете түгəрəклəнгəнен күреп, күз тидерүдəн куркып, кычкырып шатланмады, эчтəн генə Ходайга рəхмəт укып йөрде. Айрат дип куштылар. Кулларыннан да төшермичə диярлек үстерделəр баланы. Үзе дə елак булмады, ачык йөзле, көлеп кенə тора торган түп-түгəрəк малай. Диана да ешрак елмая башлады, кайчак күңелендəге боз эрегəн дə кебек була иде. Тырышты-тырмашты яшь хатын, авылда яшəргə өйрəнде – токмач кисеп аш пешерə, кышка баз тутырып кайнатма ясый, яшелчə тозлый, как киптерə... Шул ук вакытта үз йөзен дə югалтмады. Өйлəренə ремонт ясар вакыт җиткəч, ремонт эшлəрен үз кулына алды. Прованс стилендə булачак, дип, каталоглар кайтартты, шулардан үзенə ошаганын сайлап алып, интернет аша заказлар бирде. Авылча да, заманча да булды. Бакчаны гөллəргə күмде. Ире агроном бит, Диана идеялəрен əйтеп тора, Фəрит тормышка ашыра бара. Түбəсенə калын пыяла җəйдереп, өйгə терəп терраса төзеттелəр. Кышкы бакча ясадылар. Анда оранжерея тота башлады Диана. Тора-бара авыл күркенə əйлəнде яшəгəн ихаталары. Авылда да яраттылар «иностранка»ны. Кием-салым турында сөйлəшергə булса да, ремонт ясый башласалар да, киңəш-табышка аңа гына килəлəр. Каршы килми Диана, өйрəтə. Кеше күп керə аларга, ире Фəрит фермер булгач, районнан түрəлəр дə килə. Килгəн берен кунак итеп җибəрəлəр, кышкы бакчада хозурланып, хуҗаларның уңганлыгына, бигрəк тə «иностранка» Дианага сокланып китəлəр. Андый вакытта Фəрит үзе дə хатынынннан күзен ала алмый. Тик Дианаyың күңелендəге бозны һаман да булса эретə алмавына гына эче поша. Диана, Диана... Аның өчен таулар күчерергə əзер бит Фəрит. «Кулыңнан килə, əйдə, фермер бул», – дигəч, Дианаyың сүзен тыңлап фермер булып китте – отырмады. Җир алып, җир эшкəртə башлады. Əйдə, теплица куеп, шунда кыяр-помидор үстереп кара, син агроном бит, технологиялəрен белəсең дигəч, теплицада яшелчə, үлəн үстереп сата башлады. Аннан да уңды. Яшь, булдыклы фермерга район хакимиятендə дə игътибар итə башладылар. Семинарларга чакыралар, тəҗрибə уртаклашырга делегациялəр килсə, Фəритнең хуҗалыгына алып килеп күрсəтəлəр. Эшлəре уң Фəритнең, көнне төнгə ялгап чаба да чаба. Тик менə Дианаyы гына аңлап җиткерə алмый. Зарланмый, ачылып китеп сөйлəшми ире белəн. Ышанмый микəн əллə? Əле Айрат тугачы, теге вакытта өзгəлəнеп елагач, бер сөйлəшү булган иде анысы.

Диана Фəритне Парижда Яңа ел каршыларга үгетлəп карады. Яшь ир Дианаyы ул вакытта аңламады. Аңламады инде. Берничек тə. Ул трактор алырга йөри, ə хатыны Париж турында сөйли. Җитмəсə, Яңа елны шунда каршылыйсы икəн əле. Нəрсə калган анда? Яңа ел ул – гаилə бəйрəме, аны өйдə каршыларга кирəк, үз өеңдə, гаилə учагы җылысында. Тамырсыз агач кебек, җил кайсы якка куса, шул якка тəгəри торганнардан түгел шул ул. Боларын Дианага əйтеп тормады, ярар да, юк та димəде Фəрит. Яңадан бу сөйлəшүгə кайтмады да. Диана да кабат исенə төшермəде. Хəтта салгалап йөргəн вакытында хатынның ачуы килгəндə дə «ичмасам, бер үтенечемне дə үтəмəдең бит», – дигəне булмады. Кат-кат сорамагач, каприз гына булгандыр, шəһəр кызы бит, иркəлəнəсе килгəндер, дип уйлады Фəрит. Һəм шуның белəн онытылды ул Париж. Тагын берничə елдан соң Диана, кирəге чыгар дип, өчесенə дə чит ил паспортлары ясатып куйды. Фəрит «тагын Париж» дип сискəнеп куйса да, хатыны авызыннан ул сүзне ишетмəгəч, тиз тынычланды. Париж белəн Дианаyың күзлəрендəге тирəн сагыш арасында ниндидер бəйлəнеш барлыгын тоя иде ул, шуңа да бу теманы кузгатмаска тырышты. Яңа ел бəйрəме җитə башласа, Дианаyың күзлəренə карамаска тырыша иде тагын. Бəйрəм үтүгə җиңел сулап куя. Лəкин моның бер чиге булырга тиештер бит инде?

...Диана үзе дə Париж турындагы хыялдан баш тарттым дип уйлаган иде инде. Менə бу йолдызлы төн янə барысын да үз урынына кайтарып куйды. Еллар үтə дə үтə. Җəйлəр, көзлəр, кышлар һаман бер көйгə ага да ага. Күңеллəрне җилкендереп Яңа ел бəйрəме килə, лəкин ул да могҗизалар вəгъдə иткəн кебек була да, гыйнварның беренче иртəсендə үк бу ашкыну иллюзиялəр җимеше генə булып чыга.

«Живи еще хоть четверть века,
Все будет так – исхода нет», –

дип, Блок сүзлəре белəн уйлап куйды Диана. Бүгенге йолдызлы күк кенə башка, əллə нинди серле. Эйфель манарасыннан да бу йолдызлар шулай якын күренəме икəн? Ə нишлəп əле аны Диана үз күзлəре белəн барып күрə алмый соң? Нəрсə комачаулый? Ул инде Париж хыялының чынга ашуына мең кат лаек, мең кат сабырлык белəн түлəде инде ул аны. Анда барырлык кына мөмкинлеклəре бар аларның. Фəритне тагын күндереп булмас инде. Быел əнə тагын теплицаны киңəйтергə дип кредит алырга йөри. Печəн эшлəрен генə бетерəм дə, дигəн иде. Печəн дип, соңгы елларда алар печəнне трактор белəн генə эшлилəр иде, быел җəй гел яңгырлы килеп, түккə кыстыра алмадылар. Шуңа кибəнгə өяргə туры килде. Калганын төяп алып кайтып баралар. Һəм тагын чирек гасырмы, аннан да күбрəкме шулай үзгəрешсез дəвам итəр микəнни бу тормыш? Тукта, үзгəртер ул аны, үзе генə булса да барып кайтыр ул Парижга. Үпкəлəсə үпкəлəр Фəрит. Париж дип авыз сугын корыта иде Руслан. Менə Диана үзе барып күрер: нəрсəсе бар икəн ул Парижның? Бəлки, шунда ул үзен ун ел буе

газаплаган сорауга җавап таба алыр? Вәгъдәләр тикмәгә генә бирелми.

Әйе-әйе, һичшиксез, барырга кирәк. Иртәгә үк виза турында белешергә кирәк. Кунакханәләрнең бәйрәмнәр вакытында ничек эшләвен карарга. Айратны Казанда, әниләрендә калдырып торыр. Кышкы каникулына туры килә бит, кунак булыр.

* * *

«Фәрит, кичерә алсаң, кичерерсең. Pardonne Moi Ce Caprice D'enfan. Диана». Шундый язу гына тапты Фәрит кич эштән кайтуга. «Казанга киттеләр, – диде әнисе, улының сораулы карашына җавап итеп. – Килешнең бер тапкыр булса да Яңа елны әти-әнисе янында Казанда каршылыйсы киләдер бит инде, аны да аңларга була, шәһәр кызы бит ул», – дип юатты улын ана кеше. Ләкин әллә нинди шом калдырып киткән иде Диана. Кайнана язуны күрмәсә дә, нидер сизенә иде, хәерлегә генә булсын инде дип көрсенде.

Фәрит исә төн буена йокы күрмәде. Йокымсырап китсә, күз алдына Диана килеп баса да, кул болгый-болгый, саубуллаша башлый. Фәрит аны кичерә алмастай нәрсә эшләде икән соң ул? Бу чит телдәге җөмлә нәрсәне аңлата инде тагын? Үзе телефонын сүндереп куйган. Айрат йоклыйдыр инде, дип, аңа шалтыратмаган иде. Казанда да телефонны алмыйлар. Нәрсә булды икән соң? Әллә Диананың теге егетеннән хәбәр булганмы? Көнчелек кортына ун ел буе баш калкытырга форсат чыкмаган иде, әллә чыктымы? Җитте ул «Яңа ел бәйрәме»... Фәрит таң беленә башлаганчы ятты-ятты да, аптырагач, торып теге язуны кулына алды. Һәр хәрефеннән мәгънә эзләп, кат-кат укыды. Теге чит телдәге җөмләне аңларга тырышып карады. Француз телендә язылган. Ул телефонын алып, «Гугл»га әлеге җөмләне кертте. Күренекле француз җырчылары Мирей Матье белән Эдит Пиафның шушы исемдәге җыры, тәрҗемәдә «Балалык капризымны кичер» – дигәнне аңлата. Матьеның башка җырлары да бар, мәсәлән, «Париж күге астында» дигәне бик популяр икән... Париж!

* * *

Диана Казанда кунып, Мәскәүгә, аннан Парижга очты. Париж!.. Кунакханәнең дә яхшысын сайлаган иде ул. Ун ел элек Руслан белән Париж турында вәгъдәләшкәндә, ул барысын да лакшери класслы итеп күзаллаган иде. Шуңа күрә сер бирмәскә булды Диана. Париж урамнарында җәяү генә йөрер, моның өчен уңайлы үкчәле итекләрен алып килгән иде, Шанель стилендәге күлмәген кияр. Кунакханәдә вакыт әрәм итмәскә кирәк дип, ул көзгедәге сурәтенә кат-кат күз йөгерткәч, канәгать калып, урамга чыкты. Аяклар үзеннән-үзе Елисей кырларына, Эйфель манарасына таба атлады. Париж – кияүгә чыгарга әзерләнгән кызлар кебек: бәйрәмчә рух, әллә нинди ашкыну сизелә. Нәкъ ун ел элекке Диана кебек. Менә хәзер... берничә минуттан, берничә адымнан соң ул үзен газаплаган сорауга җавап табачак. Ни өчен, ни өчен ун ел элек мәхәббәт дигән олы хис аны ташлап китте? Ни өчен ул башка берәүне дә ярата алмаслык хәлгә килде? Ни өчен Аллаһ аны бу газапка дучар итте?

Париж үзе, чыннан да, сәнгать әсәре кебек икән. Монда иҗат итәсе килә, монда бәхетле буласы килә. Романтикага биреләсе килә. Ә иң гаҗәбе – монда гашыйк буласы килә. Башны югалтырлык итеп. Руслан юкка гына ун ел саен бирегә килү турында сүз кузгатмаган: монда мәхәббәт хисе ялангач кала икән. Эх, менә тагын ялгышты инде Диана, бирегә ялгызың гына килергә ярамый икән бит. Ул әйләнәтирәсендәге кешеләргә күз салды: ялгызлар бик сирәк... Әле генә җете төсләр белән балкыган Париж тоныкланып калды. Бәйрәм рухы әллә кая юкка чыкты. Диананың кинәт кенә өйгә кайтасы, гаиләсе янында буласы килде. Өйдә булса, ул хәзерге минутларда телевизордан «Ирония судьбы» киносын карый-карый, йөгерә-йөгерә мичтә каз пешерер, бәйрәмгә салатлар ясар, бокалларны кат-кат сөртеп өстәлгә тезәр иде. Кунакханәдә калган шампан шәрабы белән пар бокал күз алдына килде.
Яңа елны шулай каршылыйлар димени? Аны гаилә белән, өйдә каршыларга кирәк... Әйе, менә хәзер аңа Париж кирәк түгел инде, аңа Руслан да кирәк түгел. Әгәр Яңа ел могҗизасы булып, аннан: «Янәшәңдә кем булсын иде?» – дип сорасалар, ул... Фәрит кирәк дияр иде. Әллә кайда, яшьлектә калган хисләргә алданып, ул бәхетеннән ваз кичеп ята икән бит! Фәрит – менә аның кичәгесе дә, бүгенгесе дә, әгәр хаталарны төзәтү мөмкинлеге булса, киләчәге дә. Тик Фәрит аны кичерә алырмы соң? Тукта, ул менә әле генә Фәритне югалтты түгелме соң? Нишләде ул?!.

Диана, төш күрәмме әллә, дип, чытырдатып күзләрен йомды, ике учы белән чигәләрен уды. Париж, шушымы синең җавабың? Шушы җавап өчен син үзеңә ымсындырып, чакырып китердеңме? Соң бит инде... Бәлки, соң түгелдер дә әле? Диана кайтыр, горурлыгын читкә куеп, Фәриттән гафу сорар. Узган гомер хакына, улыбыз хакына һәм киләчәктәге бәхетле озын гомеребез хакына дип сорар. Ул бәләкәй сумкасыннан телефонын алды. Һәм ашыга-ашыга Фәритнең номерын җыйды. Бер чакыру китте, икенчесе... Колагына таныш көй ишетелгәндәй булгач, юләрләнәм, ахры, дип, тизрәк телефонын сүндереп куйды. Могҗизалар алай тиз генә була алмый! Монда каян татарча көй ишетелсен инде: «Гашыйк итә алдың мине, гашыйк итеп сакла син...» Көй тынып калды. Аңына килеп, янә Фәритнең номерын җыя башлады. Янә шул көй. Бу юлы көчлерәк тә ишетелә әле. Ул куркып кына як-ягына карана башлады һәм үзеннән биш-алты адымда гына Фәритне күреп алды. Бу мизгелдә аның иреннәре бер генә җөмлә әйтә алды. Фәритнең еллар буе тилмереп көткән сүзләре иде ул: «Яратам мин сине!»

PRESSA.RU



ЮК КИЛМӘГӘН ҖИРЛӘРЕ...



Мәдинә
АВЗАЛОВА

ЭШНЕ 20–25 БАШ ТЕРЛЕК БЕЛӘН БАШЛАП ҖИБӘРГӘН ГАРИФУЛЛИННАР...

һәм туктаусыз мәшәкатьләрдә узып киткән дүрт-биш ел эчендә республикада «Иң яхшы гаилә фермасы» булырга да, «Һөнәре буенча иң яхшы» исемен алуга да ирешкәннәр.









крен генә, җайлап кына барганда Казаннан өч сәгатьлек юл инде ул. Кайчандыр Кама елгасы аркылы салып куйган күперне, шуннан элдереп узып киткән саен, «гасыр төзелеше» дип уйлап куясың. Күпме вакытны янга калдыра, араларны ничек якынайта бит ул! Яңа Чишмә районына кереп, Акъяр авылын узуга, уңга борылгач та – Шахмай авылы...

Урамнары киң булгангамы, еракта бик зур авыл сыман күренсә дә, 150 хуҗалыгы булган бу авыл кайчандыр, чыннан да, булыр-булмас район үзәгенә торырдай булган. Авыл кешесе дә бүгенгедәй: «Кая китим? Кайда эшлим?» – белән баш катырмаган. Чөнки ул республикада данлыклы миллионер «Татарстан» колхозына кергән. Хәзер ул вакытларны шахмайлылар сагынып кына искә төшерә. «Их-х, эше юк бит аның, эше...» – дип сыкранып та куя, яшьләрнең авылда калмау сәбәбен аңлатып.

Кайчан һәм ни өчен миллионер хуҗалык таркалган?! Бу сорауга төрле җаваплар ишетсәм дә, сүз бер тирәдәрәк барды: «Вамин»га сылтый алар хәлләрнең мөшкелләнүен. Кем әйтмешли, «үзләре дә эшләми, кешегә дә ирек бирми». Кистереп, болай дип әйтү дә урынлы булмас. Ник дигәндә, җирне Ходай биргән алтын хәзинә итеп күргән авыл кешесе кул кушырып, күктән яуганны көтеп утырмый. Ничек тә эшләргә, табарга тырыша.

2011 ел Шахмай авылында көн күреп ятучы Гарифуллиннарның гаиләсенә дә җитди төзәтмәләр кертә, зур яңалыклары белән утлы табага «бастыра».

Дөресен әйткәндә ниятебез – республиканың агросәнәгать комплексы яшьләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» бәйгесендә җиңеп чыгучы үзе укытучы, үзе иң шәп терлекче Раилә Гарифуллинаны күрү иде. Әмма Гарифуллиннар гаиләсенә аяк басуга ук, без инде бу яшь чибәр ханымны, ире, баласыннан башка да, кайнанасы белән кайнатасыннан аеры да күз алдына китерә алмадык. Алар бер йодрык кебек. Сөйләшә, фикер алыша, дөнья хәлләре турында сораштыра башласаң да, сүзләре бер, эшләре бер, максатлары бер аларның.

Тыйнак килен, өлкәннәр янында, телен тешләп, сабыр гына үз чираты җиткәнен көтеп утырды. Без, мичтән пешеп кенә чыккан тәмле бәлеш, чәй янында, ашыкмыйча гына: «Ничек шулай булдыралар?» дигән сорауга бергәләшеп җавап эзлибез.

«Үзеңә ышансаң гына»

– Гаилә фермасы – ул безнең өчен эшне колачлап дәвам итүгә бер этәргеч кенә булды, – дип искә ала ул вакытларны гаилә башлыгы Илһам Гарифуллин. – Ә болай... Ни дип әйтим, кечкенәме-зурмы фермабыз бар иде инде. Сарайда 25 ләп терлек, каз, тавык, үрдәк... Дәүләт шундый мөмкинлекләр тудырганда, нигә әле безгә дә гаилә фермасы булып эшләп карамаска?! Барыбер шул ук эшләр, барыбер таңнан күз ертып торасың да, төн уртасында урынга менеп авасың. Малай гаиләсе белән Чаллыда иде. Атна саен кайтып, миңа булышып йөри торгач, туйды, ахрысы, дип йөри идем... Берзаман кайтып төшмәсеннәрме?! Илдар кайткач, дилбегәне үз кулына алды, без инде «гаилә фермасы» дип йөртелә башладык. Дәүләт вәгъдәсендә тормады, булышмады, дип әйтә алмыйм. Ул, чыннан да, булышты. Сатып алган җиһазлар өчен күпмедер процентны кире кайтарып бирде бирүен. Мин – механизатор. Бу йортны, бу ферманы күтәреп куйгач, үземне төзүче дип тә саныйм.

Әйе, җырдагыча... Алар – дүрт кеше – бөтен эшне үзләре эшли: сөрә, чәчә, уңыш җыеп ала, ферма тота. Барына өлгерә!

– Шулай, шулай... Белмәгән эше юк, – дип дәвам итә иренең тормышта ышанычлы терәк булуына адым саен шөкрана кылучы Рәсимә ханым. – Ул – эретеп ябыштыручы да, ташчы да, тракторчы, комбайнчы да... Кеше яллап эшләтергә акчабыз юк. Шуңа барын да үзләренә эшләргә туры килә. Малай да шундый безнең. Мин инде хәзер алардан шуны беләсеңме, моны беләсеңме дип сорамыйм. «Бел-

Фото: Газинур Хафизов









PRESSA.RU

мим» диюләренә бик гаҗәпләнер идем. Без барыбыз да берничә төр һөнәр иясе. (Ул рәхәтләнеп көлеп җибәрә.)

– Аңладык инде: иң шәп терлекче дә, иң шәп укытучы да... Балаларга гына түгел, яшьтәшләренә дә һөнәри сабак биреп кайткан әнә, – дибез, киленгә ишарәләп.

«Сөтнең бәясен күтәрсәләр, безгә субсидия дә кирәкми. Бөтен эш җайланачак», – ди алар.

«Авылны яратсаң гына...»

– Бәйгегә икәүләп барасыз дигәч, бермәл югалып калгандай булдым, – дип әләктереп ала сүзне Гарифуллиннарның улы Илдар. – Һөнәре буенча укытучы кеше бит ул. Тик юкка борчылганмын. Ул шундук ризалыгын бирде. Кыю-үткен ул минем хатын. Дөресен әйтим, җиңәр дип уйламаган идем. Республика күләмендәге бәйге ич. «Иң яхшы терлекче – бозау караучы» дигән исемне алып кайтты шул. Безнең өчен көтелмәгән күңелле яңалык булды ул!

Раилә белән тормыш башлап җибәрүебезгә дә биш ел була хәзер. Без аның белән февраль аеның җилле-буранлы кичендә таныштык. Мин – Чистайдагы агросәнәгать комплексы менеджерлары әзерли торган институтның соңгы курсында, ул урта мәктәпне миннән бер елга соң тәмамлаган иде – 4 нче курсында. Кышкы ялга авылга кайткач, клубка чыккан идек. Мин аңа: «Әйдә, йөреп карыйк», – дидем. Нәкъ өч ел дигәндә, өйләнештек аннары. Үкенмим, монда кайтуыма да үкенмим.

Институттан соң Чаллыга киткән идек. Эшләгән кешегә кайда да урын табыла ул. Эшсез йөрмәдем. Тик ял саен әтигә булышам дип авылга кайтып йөри торгач, авыл тартты. Кайткач, эш эзләп йөрмәдем. Өйдә җитәрлек иде. Гаилә фермасы турында ишеткәч, бик кызыктым. Киләчәген күз алдына китердем. Авыл баласына ни кирәк тагын?! Безнең бүген 62 баш эре мөгезле терлек бар. Аның кайсын Мамадыштан, кайсын үзебезнең якын тирәдәге авыллардан сатып алдык. Шуларның 24 е – савым сыерлар. Көн саен якынча 300 литр сөт савып алабыз. Сөтне иртән әни, кичен хатын сава. Читтән килеп эшләүчеләр юк. Әлегә барына да өлгерәбез. Гомумән, бу тормышта бары үзеңә ышанырга кирәк. Шуңа да кирәкле бөтен һөнәрне үзләштерергә тырышабыз. Читтән ярдәм көтеп утыра башласаң, булганыннан коры калуың ихтимал. Бүген чәчүлек җирләребез генә дә 162 гектар. Үзебез чәчәбез, печәнне үзебез җыеп алабыз, үзебез төргәкләп куябыз. Әни әйтмешли, тракторга да, комбайнга да, машинага да утырып чабарга туры килә. Хәтта шушы ферманы да туганнар белән бергәләшеп үзебез салдык. Тәҗрибә бар, дип әйтүем.

Укытучы да, иң яхшы бозау караучы да...

Ул Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлаганнан соң, авылларыннан ике чакрымдагы Акъярда ике ел тирәсе инглиз теле укыткан.

– Аннары үзебезнең Шахмай мәктәбенә кайттым, – ди бу ямьле йортның булдыклы килене Раилә. – Балалар яратам, алар белән эшләргә яратам. Малларымны да яратам (шулай дигәндә аның күзләрендә очкын кабынып куйгандай була). Иртән – мәктәптә, кичкырын – үзебезнең фермада. Безнең дүрт яшьлек улыбыз Әнвәр бар. Әни бала карап тора, мин сыер савам. Сүз дә юк, эш күп, башкасына вакыт әллә ни калмый да. Каядыр кунакка китсәк – әниләргә, әниләр китсә, безгә авыр кала. Шуңа барын уйлыйсың да, эш күп, дип, кайбер нәрсәләрдән баш тартырга да туры килә.

Педагог буларак, аны балалар язмышы, авылның киләчәге борчый. Шахмай урта мәктәбендә 100 гә якын бала белем ала. Ел саен дистәләгән егет һәм кыз шул мәктәптән канат очыра. Аларның кайсы техникумга, кайсы институтка укырга керә. Кайтырлармы алар туган якларына, шәһәрдә калырлармы? Кайткан очракта, нинди эш көтә аларны? Халык авылны үстерү, киләчәкле итү өчен мәктәп белән балалар бакчасы гына җитмәвен аңлый хәзер.

Гарифуллиннар белән саубуллашып, авылны чыкканда бу яклардагы юлларга да игътибар итмичә калмадык: мондый юллар да булыр икән, ә?! Биредә яшәүчеләрнең кайберсе: «Рус авылларына асфальт җәяләр, ә безгә – таш», – дип, ярым шаяртып, ярым җитди канәгатьсезлек белдереп алды.

Гарифуллиннар йорты белән янәшә диярлек урнашкан фермага кереп, безне бар дип тә белми силос, печән белән юанган малларны да карап чыктык.

– Аена 50 меңләп кредит түләгәч, нәрсәдер алырга, нәрсәнедер бетәйтергә акча калмый, – ди Рәсимә ханым, янында буталып йөргән бәләкәй Әнвәрне күз алдыннан ычкындырмыйча.

Әнвәр әле песи малае белән уйнап килә, әле ферма артындагы комга яшереп куйган уенчыкларын табып куана. Яныбызда бөтерелеп йөри, йөри дә: «Әнә, ул минем тракторлар», – дип, хуҗаларча кистереп куя. Без көлешәбез. Бөтен эшкә кулы ятып торган бабасы, әтисе янында үскән бәләкәй Әнвәрнең кем буласы билгеле инде...



Асия
ЮНЫСОВА

УҢГАН ХАТЫН УЛ ТАБА, БӘХЕТЛЕСЕ КЫЗ ТАБА, ДИГӘН КАНАТЛЫ ГЫЙБАРӘ БАР. ӘЙ АНЫСЫ, АНА КЕШЕ БАЛАНЫҢ КАЙСЫСЫН ДА ШАТЛАНЫП ҖЫЛЫ КОЧАГЫНА АЛА, СӨЕП-НАЗЛАП ҮСТЕРӘ. БАЛА БИТ УЛ! БАЛЧЫК ЯЛАТСА ЯЛАТСЫН, БУЛСЫН ГЫНА. БАЛАСЫЗ ДУАДАКЛАР КҮПКӘ КЫЗГАНЫЧРАК.

КЫЗ БАЛА

Рабига үзе ишле гаиләдә үсте. Үзеннән соң туган биш балага апа булып. Энесеңелләрен карап үстерешкәч, үзенең туар балаларын багарга тәҗрибәсе җитәр кебек иде. Җитмәслек кенәмени соң? Аларны тирбәткәнуйнаткан да, чәчләрен тарап үргән дә, мунчасын керткән дә Рабига булды. Торып-торып, кайчагында уйлап куя: әллә соң кай арада «туйдым бу балачага чыр-чуыннан» дип әйткәләгән чаклары да булды микән? Чөнки кияүгә чыгып, үз тормышын коргач, Ходай Тәгалә аңа бала бирми йөдәтте.

Баштагы ике елда Рабига балага узмаганына һич борчылмады. Әле Габбасының игә килгәнен көтәсе бар иде. «Сиңа өйләнсәм, эчүне ташлыйм мин», – дип антлар эчкән ир кәмәше, салмыш халәтенә кайвакыт йодрыгын да өсти башлады. Имеш, көнләшә! Югыйсә Рабига эш белән өй арасыннан башкага гаме төшә торган бикәч түгел иде.

Габбас эчүен ташламас инде ул, менә, ичмасам, бала булсын иде дигән уй Рабиганың күңелен һаман ешрак бимазалый башлады. Төшләренә һаман бер кыз бала керә. Рабига аны коча, үбә, чәчләрен тарап үрә. Таң алдыннан төштәге бала югала. Уянып китүләре авыр була иде дә соң яшь хатынга. Хыялдагы баланы кулга алыр көн генә офыктагы рәшә кебек – алда һаман билгесезлек. Инде бергә яшәүләренә дүрт ел булып үтте, Рабиганың әле балага узып караганы юк. Ире белән якынлыктан да рәхәт чикми, ләззәт алмый.



Яме булмаган никахлары өзелгәннән соң да Рабига балалы хатыннарга гел кызыкты. Яңа ел бәйрәмнәре алдыннан хезмәттәшләренең балалары өчен күчтәнәч каплары тутырганда әй нәүмизләнә торган иде. Әле, җитмәсә, «сиңа да тиеш» дигән булып, аңа да Кыш бабай күчтәнәче биргән булып, ярага тоз сибәләр.

Бала дип, ничек кенә өзгәләнсә дә, хатын никахсыз элемтәләргә кермәде. Насыйп ярым очрамасмы дип яшәде. Очрады да. Кырык яшеннән узып барганда ул Гыйльметдин белән кавышты. Ике арада олы мәхәббәт иде. Мондый мәхәббәттән һичшиксез мәхәббәтле бала туасына ышана иде хатын. Габбаска ачылып китә алмаганмындыр дип уйлый иде. Төшләренә теге кыз бала тагын керә башлады. Күргән бер төшен иренә сөйли торган иде. Инде хәзер матур кыз бала багу турында икәүләп хыялланалар. Гыйльметдиннең беренче никахтан балалары бар барын, ир Рабига өчен көенә. Хатынына бик тә бала сөйдертәсе килә иде.

Ир белән хатынның кочаклары ничек кенә кайнар булмасын, Рабига бу юлы да якынлыктан рәхәтлек кичерә алмады. Тәҗрибәле ир пошаманга калды. «Ничек алай була инде ул? Син бит инде өлгереп җиткән хатын. Бер-бер нәрсә юк микән, табибка күренеп кара әле син», – дип көн саен үгетли торгач, Рабига күнде, ир сүзен тыңларга булды. Югыйсә чир тышка ныклап бәреп чыкмыйча табибка бара беләбезмени соң без? Моңа кадәр Рабиганың да гинеколог ишеген ачып кергәне юк иде. Гыйльметдинен тыңлады. Акыллы кеше ул, юк-бар киңәш бирмәс.

Гинеколог табиб бу тамашаның шаһиты булырга коллегасын да дәште: «Күрегез әле, уникаль очрак! Бу ханым икенче тапкыр кияүдә, ә үзенең кызлык пәрдәсе алынмаган!» Икенче табиб артык гаҗәпләнмәде: «Сирәк кенә булса да, очрый торган хәл. Кызлык пәрдәсе үтә сыгылмалы булган бу ханымның».

Проблеманы скальпель очы бик тиз хәл итте. Эх, табибларга элегрәк күренәсе калган дип үкенергә генә калды Рабигага. Хәзер инде бала табып сөенер вакыт узып киткән. Ул үзе белән булган шушы хәлне, башкалар да үкенә күрмәсен дип, язарга рөхсәт итте. Югыйсә бер җирем дә авыртмый бит әле. Тик торганнан табибларга барып йөрмим әле, дияргә яратабыз. Елына бер мәртәбә хатынкыз табибына күренә торган булыгыз, дигән алтын киңәшне санга суккан булса, Рабига да кызын төшендә генә түгел, өнендә дә сөйгән булыр иде.

PRESSA.RU



АХ УЛ ЙӨРӘК...

«Серле йөрәк» җыры күпләр өчен яңалык булды. Шигыре дә, көе дә... Шактый җырларым шагыйрь Фәннур Сафин сүзләренә языла иде бит. Бу Фәннурга да ошый иде. Ул чын-чынлап җырлар шагыйре иде. Аның белән эшләве шулкадәр җиңел иде... Шигыреңнең бер җире килеп җитми, ди идем кайчак. Фәннур, башын кыңгыр салып, тәмәке тарта-тарта йөренеп ала да, үзгәртә. 70 нче елларда «Хушлашырга ашыкма», «Ялгыз көймә»ләрне иҗат иттек шулай. Халык яратып җырлый иде. Фәннурны югалткач, үзем дә югалып калдым. Фәннурдан соң иң лирик авторым Нияз Акмал иде. Аның шигърияте дә җырлап тора... Һәм көтмәгәндә... Мөдәррис Әгъләмов! Юк, ул җыр язучы шагыйрь түгел, ул фәлсәфи шагыйрь, трибун шагыйрь. Җырны кабул итте, әлбәттә. «Мондый шигырьгә дә җыр язып буламыни соң?!» – дип бик аптырады хәтта. Чөнки ул шагыйрь күңелендә җыр тексты булып түгел, шигырь булып туган. Мин инде куплетларын алып, строфа, кушымталар ясап, көйгә салдым. Мине җыр язарга шигырь этәрә. Бу очракта да шулай булды. Мөдәррис Әгъләмовның шигырь китабыннан эзләп таптым мин аны. Шигырьдә мәхәббәтнең башка тойгыларын сиздем, һәм шул ук мизгелдә башымда көе дә яңгырап үтте. Җырның сүзләре кыз белән егетнең аңлашу, мәхәббәткә өндәү дуэтына туры килә, ләкин заманчарак. Ул елларда татар музыкасында синкопалар (ритмик һәм метрик акцентларның туры килмәве – *ред.*), секвенцияләр (мелодик фразаны башка югарылыкта кабатлау – *ред.*) ниндидер яңалык булып халык күңеленә тиз кереп китте. Мин бер шагыйрьгә дә: «Текст язып бирегез әле, бер көем бар», – дип йөрмәдем. Бар шундый авторлар да: көй туа да, моңа яраклы шигырь каян табыйм икән дип йөри башлыйлар. Ә мин сүзгә игътибар

Серле йөрәк

Миңа баккан күзләреңнән
Үбәм сине шашып...
Үбәм... миннән
башкаларга
Булмасын ул гашыйк.
Күзләрең белән берочтан
Керфегеңне үбәм...
Усал күзләр караганда
Алар төшсен түбән.

Кушымта:
Йөрәгеңнән үбәр идем,
Күренми шул йөрәк –
Ах ул йөрәк, серле йөрәк,
Яши тирәндәрәк.

Колак яфракларың синең
Кытыклансын, үбәм.
Беркайчан да усал сүзләр
Ишетмәсен миннән.
Күзләреңнән,
битләреңнән,
Маңгаеңнан үбәм –
Җыерчыклар алмасыннар
Минем гаеп белән.

Кушымта.

итәм. Чишмә икән – чишмә челтерәве ишетелеп торсын, тау икән – ул күтәренке булырга тиеш. Шигырь үзе уйландыра, илһамландыра, күңелне актара бит ул. Һәрбер шигырьдән яңалык эзлим мин. Кешедә кабатланмасын, бөтенләй үзгә булсын! Безнең татарда кулланылмый торган джаз элементлары әкрен генә кереп барган чак. Чит ил музыкасын тыңлыйбыз. «АББА», «Битлз»ларны... Ул пластинкаларны табып та булмый иде әле, каяндыр Балтыйк буе республикаларыннан алып кайта идек. Музыка училищесында укыганда шулар белән мавыга идем. Шулар ритмын үз җырларыма кертергә тырышам. Алай гынамы, мин үзем дә җырлый идем! 1982 елда Чуашстанда Татарстан мәдәнияте көннәре узды. Бу җырны сәхнәдән беренче тапкыр шунда баян белән җырладым. Фәннур да, Илдар абый Юзеев та безнең төркемдә иде. Алар аптырабрак калды, ничек инде син бу шигырьгә җыр яздың, диләр. Ә миңа нәкъ менә шулай ошый, шундый образ, дим. Хатын-кызга гашыйк булсаң гына, шулай язып була! Моның өчен үзгә бер халәт кирәк! Күп җырларымны Гөлзадә репертуары өчен яздым. Ул шигърияткә шулкадәр көчле тоя. Илһам абый Шакиров концертларын алып бара. Мин үзем татар мәктәбендә укымадым. Горький исемендәге клубка, Сара апа Садыйкова ансамбленә йөри башлагач кына татар музыкасына, шигъриятенә тартыла башладым. Шигырь китаплары укыйм. Хыял дөньясына кереп китәм. Илһамланып, көйләр язам. Шагыйрьнең, бәлки, тиешле дулкынына да эләкмисеңдер. Без, композиторлар, шагыйрь әйтеп бетермәгәнне дә әйтәбез. Өч художник – шагыйрь, композитор, җырчы – кабатланмас образ тудыра.

Япон магнитофоннары килеп кергән чак. Башта күңелдә туган музыканы магнитофонга яздырасың, тыңлап карыйсың: бу җире әйбәт, монысын бераз үзгәртәсе – эшкәртү бара шулай... Аннары нотага төшерәсең.

«Серле йөрәк»не Гөлзадә белән икәү җырладык. Җәй көне Чуашстанда бергә концертлар куеп йөргән идек. Беренче чыккан концерт иде ул безнең. Җырны радиога яздырырга да алдылар. Ләкин худсовет үткәрмәде. Фондка, гомумән, һәвәскәрләргә үтү кыен иде. Исемле җырчыларны гына уздырдылар ул елларда. «Кал моңнарым булып» ничектер кереп калды әле. Радиога «Серле йөрәк»не яңгыратуны сорап язган хатлар күпләп килә башлагач кына, җыр эфирда яңгырый башлады.

1985 елда Гөлзадә белән миңа Мәскәүдә Яшьләрнең һәм студентларның XII Бөтендөнья фестивалендә катнашырга туры килгән иде. Шунда без – Татарстаннан килгән делегация – бер көнне баян уйнап, татарча җырлап, «Россия» кунакханәсе янында бөтенесен үз тирәбезгә җыйдык. Әлбәттә инде, «Серле йөрәк»не дә җырладык! Күз алдына китерәсездер: мин баянда, Гөлзадә дәртләнеп җырлый, башкалар безгә кушыла... Әллә телебезне, әллә көйләребезне үз иттеләр: болгарлар, японнар, гарәпләр, төрекләр безгә сокланып кул болгыйлар, елмаялар, көч биреп торалар...

...Берзаман, унбиш еллар чамасы элек ишетәм: Айдар Галимов җырлый «Серле йөрәк»не! Үзенчәрәк, үз стиле белән. Урал Рәшитов аранжировка ясаган. Шунысы да кызык: ул аны бөтенләй бездән түгел, Питердан ияртеп кайткан! Шундагы диаспорадан отып алган! «Серле йөрәк»не җырлаучылар күп. Башкортстанда, Нефтекамада җыр бәйрәмендә берчак килеп: «И-и, сезнең җырмыни ул «Серле йөрәк»?! Без шушы җыр аркасында өйләнештек», – диделәр. Берәүләргә – мәхәббәт аңлатырга, икенчеләренә гаилә корырга сәбәп булган икән бу җыр. Гади халык шулай кабул итә. Халыкчанлык зур дәрәҗә ул.

Шушы җырга бәйле тагын бер вакыйга искә төшә. Кичен өйгә кайтып килә. Көз көне урамда тиз караңгылана, ләкин җылы. Бер ир-ат шәйләнә, әллә арыган, әллә бераз салган да инде шунда. Үзе җырлый... Тукта, «Серле йөрәк»не җырлый бит бу! Шулкадәр сөендем. Рәхмәт тә әйтәсем килә, сөйләшеп тә китәсем килә... Ләкин дәшәргә базмадым инде. Әйдә, җырласын! Менә шушы була инде гади халыкка көйләрең белән үтеп керү дип уйлап куйдым. «Хушлашырга ашыкма» кебек тагын бер биш җырың булса, син инде халык күңелендә калдың дигән сүз!» – дип әйткән иде Мәхмүт Хөсәен. «Серле йөрәк» тә халыкның яраткан җыры булып китте шулай.

Риф ГАТАУЛЛИН



ИМТИХАН

Мәрьям
ГАФФАРОВА

13 ОКТЯБРЬ, ҖОМГА КӨН ИДЕ УЛ. СЕҢЛЕМ ТЕЛЕФОННАН БИК АПТЫРАП: «МОНДЫЙ КӨННЕ ШУНДЫЙ ҖИРГӘ БАРАЛАРМЫ ИНДЕ?!» – ДИП ӘЙТСӘ ДӘ, КИРЕ БОРЫЛМАДЫМ. ЮК, АҢАРЧЫ БЕРНИНДИ ХОРАФАТЛАРГА ДА ЫШАНМЫЙ ИДЕМ МИН.

Онкология клиникасының ишеген дә тыныч күңел белән ачып кердем: күренәм дә чыгам – декрет ялым бетеп килә, эшли башлагач, вакытым булмаячак.

Күкрәгемдәге шешне үзем тапкан идем. Онкология дигән уй ялгыш та башыма кермәде: авылда үскән сау-сәламәт кыз, бер-бер артлы тупырдап торган ике бала таптым, икесенә дә күкрәк сөте имездем. Нәселебездә андый яман чирнең булганы юк. Әйтәм бит, тамчы да шикләнмәдем. Югыйсә үзем дә югары белемле табибә бит.

Клиникада танышларым эшли, туп-туры алар янына бардым. Күптән күрешмәгән идек, уйнап-көлеп сөйләшә-сөйләшә пункция алдылар да: «Ике сәгатьтән килерсең», – дип җибәрделәр. Алар әйткән вакытта клиникада идем инде. Танышымның берсе коридорда очрады, тик нигәдер янымда туктап та тормады: «Сиңа хәзер барысын да аңлатырлар», – диде дә, ашыгып кабинетына кереп китте. Ишек төбенә чират җыелган – вакыты юктыр инде, мөгаен...

Бүлек мөдире мине үзенә чакырды. Сүзне ул кыска тотты: «Сез үзегез дә табиб, шуңа күрә ничек бар – турысын әйтәм. Сездә – онкология... Шеш инде шактый зур, ашыгыч операция ясарга кирәк. Аңа кадәр бер атна нурланыш алырсыз, соңыннан химиотерапия узарсыз».

Юк, мин аның янында еламадым әле. Мондый хәбәр шунда ук башка барып җитми бугай ул. Тыныч кына тыңлап утырдым, барысын да аңлаган кебек булдым, ниндидер сораулар да бирдем. Аннан әкрен генә кайтырга чыктым. Тукталышка тимер юлны узып барасы бит анда. Сукмак буш – бер кеше юк. Биш катлы йортлар ишегалдындагы бер эскәмиягә барып утырдым. Тормышымның шушы көнне, шушы сәгатьтә икегә бүленүен шунда аңладым: моңа кадәр һәм моңардан соң... Үксеп-үксеп, шашынып-шашынып еладым мин

анда. Кычкырып түгел, эчемнән, өзгәләнеп-өзгәләнеп... Миндә яман шеш! Балаларым нишләр?! Берсеннән-берсе бәләкәй бит әле алар: олысына – дүрт яшь, кечкенәсенә ике генә. Аларны аякка бастыру насыйп түгелме икәнни миңа, Ходаем?!

Аннан соңгы хәлләр барысы да бик тиз булды: өн белән төш арасында узган кебек. Башта, эшкә барган кебек, көн дә нурланыш алырга йөрдем. Аннан операциягә кереп яттым. Операциядән соңгы халәтемне ничек, нинди сүзләр белән аңлатыйм икән? Юк, аны үз башыннан кичкәннәр генә ахыргача аңлар... Хирург пычагы астына кергәнче син зифа буй-сынлы, матур күкрәкле чибәр, сау-сәламәт хатын идең. Ә наркоздан гарип булып уянасың: бер күкрәгең урынында бары зур яра эзе, җөй... Бу урында алга китеп булса да, бер вакыйга сөйлим әле.

Берничә ел элек иремнең бер классташларына Яңа ел каршыларга бардык. Гел аралашып торган якын дуслар түгел: бер-беребездәге хәлләрне энәсеннән-җебенә кадәр белмибез. Ирләр тәмәке тартырга чыгып киткәч, хатыны, елый-елый, үзенең хәсрәтен сөйли башлады. «Миндә бит яман шеш таптылар, операция ясадылар. Хәер, син аңламыйсың, кешегә сөйли торган хәлләр түгел ул», – ди. «Кайчан ясадылар?» – дим. Өч-дүрт ай элек икән. «Ярый, бернәрсә дә булмаган, борчылма, узган да киткән. Миңа да ясаганнар иде», – дим. «Синеке гади генә операция булгандыр, минеке бит башка!» – ди ул өзгәләнеп. «Химия алдыңмы соң?» – дим. Юк, алмаган, кирәкми, дип әйткәннәр. «Алай булгач, тынычлан, димәк, куркыныч бернәрсә дә юк», – дим. Ә ул өзми дә куймый: «Юк, син мине аңламыйсың! – ди. – Хатын-кыз өчен күкрәген алдыруның нинди зур фаҗига икәнен күз алдыңа да китермисең, минем бит бер күкрәгем хәзер бөтенләй юк», – ди. «Күз алдыма китерә алам», – дим. Барысын да сөйләргә туры килде. «Сиңа да ясадылармыни?» – дип, ул өнсез калды. «Әйе! Һәм, күрәсеңме, мин һаман да исән!» – дим. Бик чибәр ханым ул, яман шеш диагнозы куелуы, күкрәксез калуы өчен өзгәләнә. «Операциядән соң яшисем килмәгән көннәрем күп булды...» – ди. Аның хәлен бик яхшы аңлыйм. Бүгенге көндә ул чын күңеленнән Аллаһы Тәгаләгә ышанып, теш-тырнагы белән тырмашып, авыруы белән көрәшә. Аның да кызларын үстереп аякка бастырасы, оныклар сөясе килә. Аның белән бер-беребезгә терәк булырга тырышабыз.

...Операциядән соң бер атна узгач, миңа утыз яшь тулды. Инде диагноз ахыргача тәгаенләнде: яман шешнең III стадиясе, ун лимфа төененең алтысы зарарланган. Бу инде метастазалар башланган дигән сүз... Моның ахыры яхшы булып бетмәячәге табиб булмаган кешегә дә мәгълүм.

Яман шеш диагнозы куелган авырулар барысы да минем кебек җавабы булмаган сораулар алдында калады. Аның иң беренчесе: «Ни өчен? – дигән сорау иде. – Бу чир нигә нәкъ миңа килде? Аллаһы Тәгалә мине нинди гөнаһларым өчен җәзалый?» Мин бит югыйсә беркайчан кара эчле, мәкерле булмадым, усал түгелмен, кулымнан килгән кадәр һәркемгә яхшылык кына кылырга тырышам. Йөрәгемне телеп-телеп алган икенче нәрсә: «Инде мин әни буларак, балаларыма бернәрсә өйрәтә алмаячакмын». Елый-елый үлгәнемне күз алдыма китердем. Авылыбыз зиратындагы каберемне... Иремә әйтеп калдырырмын инде: «Елга бер булса да балаларны минем янга, каберемә алып кайт», – диярмен. Хастаханәдә ятканда аларның икесенә атап аерым-аерым хат яздым. Елый-елый... «Унсигез яшь тулгач кына бирерсез дип әйтеп калдырырмын», – дип. Эчтәлекләрен бүген дә хәтерлим. «Улларым, газизләрем! – дип яздым мин. – Мин сезне бик яратам. Үзем сезнең янда булмасам да, мин барыбер янәшәгездә. Күңел җылымны сезгә бирергә тырышам. Сезне ташлап беркая китәргә теләмәсәм дә, менә ничек килеп чыкты... Сез тормышта бик көчле кешеләр булырга тиешсез. Тормыш булгач, төрле хәлләр була. Әмма мин сезгә бик ышанам. Сез начар булып үсмәссез. Үз урыныгызны табарсыз. Минем йөземә кызыллык китермәссез. Мин сезне аннан – ерактан һәрвакыт күзәтеп торырмын. Анда үземне ни көткәнен белмим, әмма кирәк чакта сезгә булышыр өчен ничек тә җаен табармын. Бер-берегезгә дус булыгыз. Холкы авыррак булса да, әтиегез дә сезне ярата. Икенче әни килер, аны да яратыгыз – минем теләгем белән җибәрелгән кеше булуы бар аның...» Хатлар озын иде, һәрберсе куш бит.

Без җиргә җаныбызны баетып, Аллаһы Тәгаләгә булган мәхәббәтебезне, яратуыбызны үстереп кайтырга килгәнбез.

Язмыштан узмыш юк, дип, үз-үземне ышандырдым. Димәк, үләм... Шушы ике баланы табарга гына килгән булганмын икән бу дөньяга. Аның каруы, яшь, матур килеш китәм. Үлем янәшәдә генә йөргәч, аның хакында уйламый чараң юк. Бергә дәваланучыларның бик күбесе китте бит. Палатада, гадәттә, алтышар кеше ятабыз, ике айдан кабат күренергә киләсең, анысы юк, монысы...

Елый-елый күз яшьләре кипкәч, мин... китап укырга кереештем. Бу кадәр тау-тау китапны студент чакта да укымаганмындыр. Эзотерикага, психологиягә, дингә кагылышлы китаплар... Укыган саен, бик күп нәрсәләргә карашым үзгәрә барды. Башта мин бу сынауны ниндидер гөнаһым өчен бирелгәндер дидем. Аннан нәселгә төшкән берәр гөнаһ өчен газапланамдыр дип уйладым. Күбрәк китап укый торгач, фикерем бөтенләй үзгәрде: юк, мондый сынау гөнаһыбыз өчен бирелми. Киресенчә, безне көчлерәк итү, авырлыклар аша җаныбызны Аллаһы Тәгаләгә якынайту өчен җибәрелә ул. Үзебезгә кыен булганда гына Ходай турында уйлый, аны аңлый башлыйбыз бит.

Яман шеш авырулары кичерелмәгән үпкә хисләре аркасында килеп чыга, диләр. Миндә дә бар иде алар.

Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU

Беренче чиратта, иремә карата. Мин ике бала белән өйдә утырганда, аның төннәр буе каядыр чыгып югалулары, кайтмаулары, булышмавы, кызу холкы, аңламаулары өчен, әлбәттә, үпкәле идем. Утсыз тәрәзәдән караңгы урамга карап, аны көткән төннәрем аз булмады... Әти-әнинең иремне кабул итмәүләре аркасында да шактый газап чиктем. Мин гел ике ут арасында идем: әти-әнигә иремне мактыйм, иремә – аларны... Китаплар фикерләремне үзгәртте. Авыруым дөньяга, тирә-юнемдәге кешеләргә булган үпкәләрем аркасында гына түгелдер, бу – мин үтәргә тиеш юл. Үләм, дип елап, өметсезлеккә бирелеп утырам икән, чыннан да китәчәкмен. Әмма әгәр тормышка карашымны үзгәртә алсам, тәнемдә дә нәрсәдер үзгәрәчәк. Менә монысы минем өчен зур ачыш булды. (Соңыннан, үз авыруларым арасында да күп күзәттем: кешенең психологиясе үзгәрә икән – авыртулары китә, бетә. Онкология генә түгел, гипертония дә, башкасы да. Күп чирләр үзеңне яратмаганнан, кабул итмәгәннән килеп чыга.)

Ул көннәрдә күңелемнән бик күп гафу сорадым. Гөнаһ – кеше үтерү, кеше рәнҗетү генә түгел, тәкәбберлек, масаю, «мин кем» дип йөрүләр яки мин булдыксыз, бернәрсәгә дә ярамыйм диюләр, миннән бернәрсә дә тормый, бернәрсәне дә үзгәртә алмыйм, дип, агым уңаена гына агу, төшенкелеккә бирелү дә гөнаһ бит. (Хәзер дә тормышымда берәр авырлык килеп чыкса, беренче чиратта Ходайдан «белеп һәм белми эшләгән гөнаһларымны кичер», дип гафу сорыйм.)

Юк, сынаулар мине сындырыр өчен җибәрелмәде...

Тирә-юнебездәге кешеләргә дә үпкә сакларга ярамый: безгә булган мөнәсәбәтләре белән алар безне чистарта. Бәлки, бу фәлсәфә дөрес тә түгелдер. Ләкин бүгенге көндә мине шул яшәтә.

Ирем ул көннәрдә миңа таяныч булмады дия алмыйм. Аннан соң да ничә еллар хатын итеп, тиң күреп яшәде. Теле белән дә, карашы белән дә кимчелекле хатын-кыз икәнемне миңа сиздермәде, яратуын күрсәтеп яшәде. Тормышта төрле вакытлар булды, әмма мин аңа күп нәрсә өчен барыбер рәхмәтлемен. (15 елдан артык бергә торгач, төрле сәбәпләр аркасында, без аерылыштык – бу да минем үтәсе яңа сынавым: «яраткан кешемне сынармын» дигән Аллаһы Тәгалә. Тормышымның бу борылышын да сабырлык белән, рәхмәтле булып кабул итеп, Аллага шөкер дип үтәргә тырышам.)

Ирем дә миңа сынау өчен җибәрелгән кеше. Әйткәнемчә, гомумән, яныбыздагы һәр кеше «өйрәтүче» ролен үти: алар аша без нидер аңларга, яңа баскычка күтәрелергә тиеш. Ирем менә гаиләбезгә бер дә юктан гына килеп кермәде ул. Чөнки безнең нәселнең хатын-кызлары матриархат принциплары буенчарак яши, барысын да үзебез хәл итәбез, тормышны без ерып барабыз. Һәм безнең арага: «Хатынны тыңла да, үзеңчә эшлә, беренче урында – ир-ат сүзе», – дип фикер йөртүче кеше килеп керә... (Ә бит, уйлап карасаң, ул хаклы! Элек моны аңлап бетермәгәнмен, үзем барысын да булдырам, яхшырак беләм, дип, бөтен тормыш мәшәкатен үз өстемә өйгәнмен, ирдән узып үзем тартканмын... Ә чынлыкта, киресенчә – тормыш дилбегәсен ир кулына тапшырып, динебез кушканча ир-ат күләгәсендә хатын-кызның төп вазыйфаларын гына үтәп яшәргә тиеш булганмын. Без – хатын-кызлар күп очракта үз тормышыбызны үзебез катлауландырабыз, хатыннарның көче көчсез булуда икәнен аңламыйбыз... Аннары үпкәләүләр, тормыш йөген нигә мин генә тартам дип зарланулар, балалар проблемаларын берүзең хәл итүләр, финанс мәсьәләләре – болар барысы да төрле авыруларга бер сәбәп булырга мөмкин. Шулай, аннары өстән безне кисәтәләр: «Җитәр, тукта, син бит хатын-кыз, яшәешеңне үзгәрт!» – диләр.)

Диагнозымны ишеткәч, әрнеп, өзгәләнеп әти белән әни турында уйладым: мине югалтуны алар ничек кичерер? Безгә – ике кызларына шулкадәр нык бәйләнгән иделәр. Һәм без сеңлем белән аларга әлегә бернәрсә белгертмәскә хәл иттек.

Әти, бәлки, чыннан да берни сизенмәгәндер. Ә әни белмәмешкә, күрмәмешкә салышты бугай. Чынбарлыкка күз йому аңа җиңеллек биргәндер. Көчсезлек түгел бу. Бары мине артык ярату. Бу чирнең миңа кагылганын белгәнче, ул минем урынга үзе авырырга әзер иде. Белде ул минем авырганымны. Мунчага сеңлем белән генә йөри башлавыма ничек игътибар итмәсен инде? Алай-болай әни килеп керсә, тизрәк артым белән борылып басам. Авылга сирәк кайтуларым, ябыгуларым аларны ничек шикләндермәсен?

«Химия» ала башладым. Ул көннәрне искә төшерүе дә авыр... Ябыктым, чәчләр коелып бетте – көзгегә карарга куркыныч. Парик сатып алдым. Эсседә өйдә аның белән йөреп булмый, яулык бәйләп куям.

Сигез «химия» алдым. Бу – бер елга диярлек сузылды. Соңыннан лейкоцитларым төште: иң түбән норма – дүрт, ә минеке икегә калды. Организм «химия»не кабул итми башлады – соңгысына инде көчем җитмәде. Чит илдә дәвалану мөмкинлеге килеп чыкты – монысы өчен якын туганнарга рәхмәт. Анда махсус аппаратка тыгып, бер тәүлек буе тәнемне 44 градуска кадәр эсселәтеп тоттылар. Гипертермия дип атала ул. Барысы да наркоз астында башкарыла. (Әмма мине анда барып дәвалану гына коткарды дип уйламыйм. Мәскәүдән бик зур бер җитәкченең хатыны ятты янымда. Миннән аз гына өлкәнрәк иде. Алардагы мөмкинлекләрне безнеке белән чагыштыра торган да түгел. Ярты елдан ул «китте»...)

Чит илгә дәваланырга баруымны әниләргә «чит илгә укырга барам, стажировка үтәм» дип аңлаттык. Башымдагы паригымны анда ясаткан яңа прическа дидек. «Ышандылар»... Парик икәнен бер караудан аңлап була югыйсә. Балаларны мин юкта әти белән әни карап торды, сеңлем кайтып булышып йөрде. Зур рәхмәт аларга. Сизенү дигәннән... Чит илдән кайткач, әни: «Кызым, авыр күтәрмә!», «Күп эшләмә!», «Кызым, ятып тор әле!» дигән сүзләрне бик еш әйтә башлады. Аңа ка-

дәр өйдә бөтен эшне җигелеп эшли идем. Әмма авыруым хакында, ул инде чигенгәч тә, әниләр белән утырып сөйләшкән булмады. Мин елмаеп кайтып кердем, алар «бар да әйбәт» дигән ялганыма «ышануны» дәвам итте.

Мин ул көннәрдә Ходайдан: «Улларымның унбиш яшькә җиткәнен булса да күрсәм икән», – дип бик сорадым. Аларга дөньяның агын-карасын аңлатырга өлгерсәм икән, дип ялвардым. Химиядән соң бөтен җирем авырта, идәннәрдә тәгәрим, аңнарымны җуям... «Бу авыртуга да түзәм, шушы теләгем генә үтәлсен иде», – дим. Ялваруларымны Ходай ишетте... (Бу хәлләргә инде 15 ел үтте, балалар үсте. Хәзер инде булачак киленнәрем белән кызларым кебек яшәп, оныклар үстерәсем килә! Намаздан соң үземә дә хатын-кыз бәхете сорыйм әле, миндә кемнедер бәхетле итәрлек күңел жылысы, наз бар дип саныйм, аннары: «Кайсы хәерле, шулай булсын», – дип тә өстим.) Мин бу авыртуны җиңдем дип әйтә алмыйм – теләсә кайсы вакытта килеп чыгарга мөмкин. Әмма мин ул чакта үземне үзем дәвалый алам дигән нәрсәгә бик ышандым.

Кеше үзенең эмоцияләре, үпкә-рәнҗүләре, бу тормышның алдавыч яклары өчен борчылулары белән күп очракта үзен-үзе авыруга китереп җиткерә. Аннары дарулардан, табиблардан, им-томчылардан могҗиза көтә башлый. Ә могҗиза аның үзендә – Аллаһы Тәгалә тумыштан биргән илаһи көч ул. Шул көч безгә матур шигырьләр, көйләр, картиналар иҗат итәргә, искитәрлек архитектура корылмалары тудырырга, машина-самолетлар уйлап чыгарырга, медицинада, башка өлкәләрдә ачышлар ясарга мөмкинлек бирә. Кемдер матур күлмәк тегә, кемдер тәмле аш-су пешерә, матур чәчәкләр үстерә... Адәм баласындагы күзгә күренмәс шул илаһи көч, дөрес аңлап, ул үзенең тормыш философиясен, эмоцияләрен үзгәртсә, аңардагы әллә нинди авыруларны да юкка чыгара ала яки ул чиргә карата кешенең карашын үзгәртә, аны сабырлыкка өйрәтә. Без үзебезнең нинди көчкә ия булганыбызны аңлап кына җиткермибез.

Авыр вакытта кеше Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылганын һәм кире аңа кайтасын аңлый башлый.

Ходай ул нәрсә сорасаң, шуны гына бирми, кешенең җанын Ходайның үзенә ни якынайта, шуны да җибәрә. Шуның өчен тормыштагы һәр нәрсәне (бәхет-шатлык, авырлык, авыру, кайгы, үлем...) рәхмәт әйтеп, сабыр булып кабул итәргә өйрәнергә кирәк. Тыныч, матур тормышта без Аллаһы Тәгаләне онытабыз, яраткан кешебез, гаилә, балалар беренче урынга чыга, тышкы матурлыкка, матди байлыкка омтылабыз – шулар өчен генә яши башлыйбыз. Ләкин адәм баласы бу дөньяга ялгыз килә, ялгызы китә: бар тапканың җирдә кала.

Үткән юлымны ничек бар – шулай кабул итәргә, нинди булуына карамастан, яшәгән һәр көнемнең, һәр мизгелемнең үзем өчен кирәклеген аңларга һәм рәхмәтле булырга өйрәндем. Моңа күп уйланулар, күз яшьләре, өзгәләнү-бәргәләнүләр, әрнүләр аша килдем. Яшәүдән дә, үлемнән дә инде курыкмыйм, чөнки Аллаһы Тәгаләгә илтәсе юлны таптым. Шул уй мине көчле һәм бәхетле итә.

БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ



Психология буенча китаплар авторы Луиза Хей Лос-Анджелес шәһәрендә туа. Үги әтисе аңа карата бик кырыс була. Ә биш яшьлек вакытында аны көчлиләр... Аннан соңгы тормышында да сынаулар шактый була. 1977 елда аңарда яман шеш табалар... «Авыруымның сәбәбе — балачагыма карата күңелемдә яшәгән нәфрәттә, үпкәдә», — ди ул. Луиза тормышын, яшәү рәвешен үзгәртә, уйларын тәртипкә сала. Авыру чигенә... Шушы хәлләрдән соң ул берничә китап яза. «Нинди дә булса проблеманы чишәргә алынганчы, мин үземнең уйларымны дөреслим, — ди ул. — Шуннан соң әлеге проблема үзеннән-үзе хәл ителә».

■ Авырып китә икән, кеше иң беренче эш итеп күңелендә казынсын: кемне гафу итәргә тиеш ул?
■ Үз-үзегезне тәнкыйтьләүдән туктагыз. Үзегезне начарга санамагыз.
■ Үзегезне мактарга өйрәнегез. Тәнкыйть күңелне күмергә калдыра, ә мактау очкыннан да ялкын кабыза. Нәрсә генә эшләсәгез дә, үзегезне мактап куярга онытмагыз.
■ Ярдәм сорап дусларыгызга мөрәҗәгать итәргә өйрәнегез. Ярдәм сорау – көчсезлек билгесе түгел, киресенчә... Авырлык килгәндә, без күп вакыт үз-үзебезгә генә ышанабыз: читләргә дә таянып карагыз әле бер.
■ Үзегезне куркытудан туктагыз. Нигә һәрнәрсәнең ахыры начар бетәргә тиеш дип саныйсыз? Начар әйберне көтеп яшәү шундый авыр бит ул. Тузан бөртеге кадәр булган проблеманы тау кадәр итеп үстермәгез.
■ Көнне көзгегә караудан башлагыз. Көзге каршысына басыгыз да үзегезгә: «Мин сине яратам, син гаҗәеп, искиткеч...» – диегез. Һәм бу көнне матур, күтәренке кәеф белән үткәрегез. Тормышыгыз үзгәргәнне сизми калмассыз.
■ Үз-үзегезгә карата мәрхәмәтле булыгыз. Начар уйларыгыз өчен үзегезне гаепләмәгез. Үткәндәге ялгышлар өчен дә гел үзеңне битәрләп тору ярамый. Аңардан сабак кына алыгыз. Үзеңә мәрхәмәтле булу – гаепләрең, ялгыш адымнарың өчен үзеңне үзең газаплаудан, җәзалаудан, әрнүдән арыну ул.
■ Сабырлык – зур көч. Күп вакыт бөтен нәрсәнең нәтиҗәсе бик тиз булырга тиеш дип көтәбез. Куйган максатларга барып җитү өчен ниндидер адымнар ясамыйча, сабак алмыйча, өйрәнмичә нәрсәгәдер ирешәсебез килә.




ӘКИЯТТӘ КУНАКТА



Лилия
ГӘРӘЕВА

СЕЗ ӘКИЯТЛӘРГӘ ЫШАНАСЫЗМЫ УЛ? ӘЛЛӘ ИНДЕ ТОРМЫШТА МОГҖИЗАГА УРЫН ЮК ДИП САНЫЙСЫЗМЫ?

Юкка ышанмыйсыз. Бар икән, бар ул әкият! Казанда яшәүче Венера ханым Габделхәева да могҗизаның барлыгына моңарчы ышанмаган, ә язмыш аңа чын әкият әзерләп куйган.





Утыз ел гомерен медицинага багышлаган, өзелергә торган гомер җепләренең кабат ялгануының да, өмет тулы күзләрнең мәңгегә йомылуының да шаһиты булган Венера апа моңа кадәр бер тапкыр да чит илгә чыгып карамаган. Акча яки теләк булмаганнан түгел, бәлки, җае чыкмаганнан, вакыт җитмәгәннән. Чит ил комында кызынасым килә дисә, ире Фәрит абый сөекле хатынының гозерен үтәү чарасын тапкан да булыр иде. Моңарчы ял итү кайгысы булмаган шул Венера апада. Кичкә кадәр – операция бүлмәсендә, кичен – сеңлесе янында. Кияүләре Юра дәвасы юк сирәк чирләрнең берсе белән авырый башлагач, дөньялары кисәк тарайган да куйган аларның. Кул бармаклары оюдан башланып киткән авыру аны урыннан тора алмас хәлгә җиткергән. Мондый диагноз куелган кеше, гадәттә, ярты ел эчендә вафат була. Ә алар аның тормышын тагын биш елга озайта алган. Юра үзе дә нык торган. Башын тота алмас булса да, үзенең чире турында мәкаләләр язган. Күз алдыңда сүнеп барган якын кешеңне өметләндерердәй сүзләр табып юатуның никадәр авырлыгын, аның газапларын берничек тә җиңеләйтә алмаудан җаның бәргәләнеп, гомеренең санаулы минутларын озайту мөмкин түгеллектән күңелнең ничек сызганын үз башына төшкәннәр генә белә.

Венера ханымның яшәеше гел шулай авырулар мәнфәгатеннән генә торуына, онытылып бер ял итү форсаты булмавына Фәрит абыйның да җаны әрнеп йөргән, күрәсең. Бергә гомер итүләренә 26 ел тулган көнне хатынына нинди бүләк ясарга дип баш ватканда, искиткеч шәп фикер килә аңа. Венера апага белдерми генә «StarHit» журналы уздырган «Җәйге ялга Андрей Малахов белән» конкурсына хат яза. Ниләр язгандыр инде ул хатка, анысын Венера апа үзе дә төгәл белми. Әмма Фәрит абыйның хаты конкурска килгән 30 мең хат арасыннан җиңеп чыга.

Ул көнне бик яхшы хәтерли әле Венера апа. Ире белән машинага утырып, көндәгечә эшкә барырга кузгалгач, Фәрит абый бик дулкынланып, сөенечле хәбәр ирештерә. «Безнең яшьтә артык куанырга да, артык борчылырга да ярамый дисәң дә, сиңа әйтәсе зур куанычым бар. Син быел Андрей Малахов белән ял итәргә барасың!» Венера апа сөенеченнән һушын җыя алмый торгандыр дип уйлыйсыздыр инде. Юк, билгеле. Ышанмаган ул бу хәбәргә. «Шаяртма әле», – дип, кул гына селтәгән. Журнал битендә үз исемен күргәч тә исе китмәгән. Хәзер компьютер белән әллә нәрсәләр ясарга була ла ул! Әле «StarHit»тан шалтыратып, «Сез Андрей Малахов белән ял итәргә барачаксыз, ул хакта беләсезме?» – дигәч тә, «Шаяртмагыз инде, мин андый әкияткә ышаныр яшьтә түгел», – дигән. Менә шул шул, әкиятләргә күптәннән ышанмый башлаган инде без.


Беренче каналның төшерү төркеме: «Без киләбез», – дип шалтыраткач кына, Фәрит абыйның шаяртмаганын, ә бәлки, әкият дөньясына ачкыч бүләк итүен аңлаган. Тапшыруны Юраларда төшергәннәр. Венера апа эшләгән хастаханәдә дә булганнар. (Боларның барысын да Беренче каналдан күрсәттеләр. Бәлки, сез дә карагансыздыр аны.) Мавыктыргыч әкият әнә шулай башланып киткән.

Гаҗәеп ул көннәрне Венера апа әле дә тыныч кына искә төшерә алмый, күңеле – хисләрдән, шул вакыйгаларның тәэсиреннән ташый. Казан клиник хастаханәсендә шәфкать туташы булып эшләүче Венера Габделхәева конкурста җиңгән ун кешенең берсе иде.

Һәр кешенең күңелендә сабый бала яши. Әкияткә ышанмыйбыз дисәк тә, күңел барыбер дә могҗиза көтә.

«Анда һәрнәрсә безнең өчен сюрприз булды. Хәтта кайсы илгә баруыбызны да соңгы минутка кадәр сер итеп сакладылар. Аэропортка илтүче автобуска утырышкач кына, Малахов билетлар чыгарып, Кипрга баруыбызны әйтте. Мин үзем кая барсак та риза идем, – дип искә ала ул сентябрь ахырында булып узган вакыйгаларны. – Кипрда безне иң яхшы кунакханәләрнең берсенә урнаштырдылар. Яныбызда көне буе ике оператор төшереп йөри. Малаховның бер адым да калмый ияреп йөрүче үз стилисты бар. Гел чәчен тарап, битенә кершән ягып, килеш-кыяфәтен кайгыртып тора. Андрей бик зыялы, аралашучан икән. Популяр кеше булгач, мин аны тәкәбберлер, гади кешеләр янында үзен өстен куядыр дип уйлаган идем. Кая ул! Безнең белән үзен бик гади тотты». Венера апа сөйләгәннәрне тыңлавы безгә дә кызык. «Сезгә үзегезне ничек тотасын, нәрсә сөйләргә кирәген, ничек киенәсен алдан әйтеп куйганнар идеме? Ялыгыз әзер сценарий буенча бардымы?» – дип, аны сорауларга күмеп ташлыйбыз. «Әлбәттә, редакторларның үз сценарийлары булган инде. Ул хакта без берни дә белмәдек. Безгә алай итегез, болай итегез дип өйрәтеп торучы булмады. Алар әзерләгән сюрпризлар безнең өчен чынлап та сюрприз булды. Тапшыруны караганнар хәтерлидер: Ижаудан килгән Светлана Фокина Малаховны пионерга кабул итүне оештырган иде. Ул күренешнең авторы дөрестән дә Светлана үзе. Галстукларын да үзе белән Ижаудан ук алып килгән. Малахов белгәнче, без аны башта редакторлар белән килештердек. Бу – безнең тарафтан Малаховка сюрприз булды. Аннары мин аны кош теле пешереп сыйладым. Монысы да аның өчен көтелмәгән иде. Шул кош телен пешергән искә төшсә, әле дә көлми түзә алмыйм. Дөрес, аның идеясен редакторлар бирде. Алар берәр төрле бәлеш пешерсәң дигәннәр иде дә, мин йә камырым кабармас дип, кош теле генә пешерергә булдым. Безгә кухняны бер генә сәгатькә бирделәр. Ярдәмгә Сюзанна исемле аш-су остасын билгеләделәр. Әй шул тел белмәү! Аларда бөтен нәрсә зәйтүн маенда әзерләнә. Ә миңа көнбагыш мае кирәк. Көнбагыш ашаган кебек итеп, ишарәләр белән үземә нәрсә кирәген аңлатырга тырышам. Сюзаннаның,

PRESSA.RU



■ Венера һәм Фәрит Габделхәевләр кызлары Гүзәлия белән уллары Рамилнең уңышларына сөенеп яши.

мине аңлап алып, инглизчә: «Йе-е-ес!» диюләре исемә төшә дә, авыз үзеннән-үзе ерыла. Он кирәген дә, уклау кирәген дә ишарәләп аңлаштык. Әзер кош теленең өстенә шикәр оны сибәргә кирәк. Һич аңлата алмыйм шуны. Ахырдан, йодрыгымны тукмак итеп, шикәр комын төя башладым. Бик тәмле килеп чыкты ул кош теле. Без аны Малаховка катер белән диңгезгә чыккач тәкъдим иттек. Кош телен сайлап, дөрес эшләгәнмен, ул Андрейның яраткан ризыкларының берсе икән.

Хәтергә уелырлык бәхетле мизгелләрне язмыштан көтеп утыру дөрес түгел. Андый мизгелләрне бер-беребезгә без үзебез дә бүләк итә алабыз икән.

Кипрга килгән кеше Киккос монастырена сугылмый калмый. Диңгез өслегеннән 1800 метр биеклектә ул. Монастырьда апостол Лука иҗат иткән Изге Ана сурәте бар. Аның каршында теләк теләп, шәм куйсаң, кабул була диләр. Минем иң зур теләгем – Юраның гомерен озайту. Аллаһы Тәгаләдән аның хәлен яхшыртуны, гомерен озынайтуны сорадым. Сәфәрдәшләремнең кайсын гына алма, һәркайсы үзенчәлекле тормыш юлын узган, авырлыгын да, борчу-хәсрәтен дә җитәрлек татыган кешеләр. Алар нинди теләкләр теләгәндер, без ул хакта сөйләшмәдек. Ләкин минем теләгем кабул булмады. Без Кипрдан кайтасы көнне Юра вафат булган. Мәскәүгә кайтып җиткәнче миңа беркем бу хакта белдермәде. Фәритем, шалтыратып, күңелен төшермәгез, бәхетле мизгелләре озаккарак сузылсын диген. Тау башындагы монастырьда күңелемнән Аллаһка инәлгән шушы минуттан алып бу күңелсез көнгә кадәр алда минем бәхет тулы бер атнам бар иде әле.

Безнең арада үзенә күрә бер шартлы билге барлыкка килде. Малахов каядыр югала икән, димәк, нинди дер сюрприз әзерлиләр. Беркөн безне Афродитаның ватаны саналган Петра-ту-Ромиуга алып килделәр. Анда Матурлык һәм Мәхәббәт алиһәсе диңгез күбегеннән калыккан урын бар. Ул тирәдә гаҗәеп ташлар очрый. Үзләре ап-ак, үзләре нәкъ йөрәк төсле. Шул ташны табып алучы кеше һичшиксез мәхәббәтен таба дигән ырым бар. Сәфәрдәшебез – 15 ел буе шахтада эшләгән Людмила Кузнецова өчен бу көн гомерлек хатирә булып калыр инде. Диңгез ярында мәхәббәт ташларын гына түгел, мәхәббәтенең үзен дә очратты ул. Шул көн иртән генә Уралдан килеп төшкән Сергей Кулагин сөйгәненең кулын нәкъ менә бүген, нәкъ менә шушы диңгез ярында сорады. Әкият кебек яңгыраса да, болар бар да чын иде. Икенче көнне уздырылган туй да, ак күлмәк, алтын балдаклар да чын һәм барыбыз өчен дә көтелмәгән булды. Минем үземнән дә кем белән очрашасыгыз килә, нинди теләкләрегез бар дип сорашканнар иде: «Монда сезнең белән булуым да җиткән», – дидем. Җир йөзендә әкият юк, могҗизаларга ышанмыйм дип йөргән кеше өчен, моннан да зуррак бүләк була алмыйдыр ул.

Кипрда без тугыз көн кунак булдык. Анда күргән-кичергәннәрнең барысын да тасвирлау мөмкин түгел. Кайвакыт уйлап куям: бу хәлләр чынлап та булдымы, әллә мин төш кенә күрдемме? Төш кенә дияр идем, тугыз көн дәвам иткән матур әкиятнең чынлыгын раслаучы фотосурәтләр бар. Әйтеп кара син моннан соң җир йөзендә әкият юк дип!



РӘХИМОВА Вәсилә

Казан дәүләт университеты, журналистика бүлеге (1978).

Ике бала анасы.

Карьера:
ирекле журналист. «Атаклы дин әһелләре» сериясендәге китаплар авторы.

Тормыш шигаре:
«Гомер буйлап барам, барысын уйлап барам:
Әллә кем түгелбез, әмма кем түгелбез,
Әллә кем булганнардан».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Мин беренче булдым!

Татарстан Диния нәзарәтенең хатын-кызлар белән эшләү бүлеге, Мөселмәләр иҗтимагый оешмасы беренче тапкыр «Татарстанның атаклы абыстае» дигән республикакүләм бәйге оештырды. Анда без – мәчетләрдә дин сабагы алып баручы ун абыстай катнаштык. Ә җиңеп чыгу миңа насыйп булды! Коръәнне мәкам белән дөрес итеп уку, үтемле итеп дога кылу, тыңлаучыны ничек итеп кызыксындыру, җәлеп итү алымнарын күрсәтергә кирәк иде. Ризык пешерүдә, уңганлыкта, булганлыкта да ярыштык. Соңгы вакытта үзем төзегән нәсел шәҗәрәм, тәрҗемә иткән китапларым да җиңәргә булышты бугай.

Лаеклы алмаш килә


Дини темага яза башлаганыма 20 елдан артык. Вәлиулла хәзрәт Якуб чыгарган «Иман» газетасына заманында байтак язма әзерләдем. Казандагы һәммә мәчетләрне белә идем. Хәзрәтләр, имамнар, мәчеттә эшләүчеләр – барысы да пенсиягә чыккан картлар, олы бабайлар иде ул чакта. Ә хәзер карыйм: имамнар сафы яшәргән: мәчетләргә «Мөхәммәдия»не тәмамлаган шәкертләр, шушы юлда 4-5 ел инде үзләрен сынаган, үз урыннарын тапкан, эш күрсәтергә өлгергән яшьләр килгән. Белемле, гыйлемле яшьләр. Болгар ислам академиясе ишекләрен ачса, ислам диненең чын асылын аңлатучы зур галимнәр тагын да күбәер.

Тел Кытайга илтер...


Европа илләрендә ким дигәндә дүрт тел беләләр, шуңа күрә аларга дөньяның һәр почмагы ачык – кая барсалар да үз кеше. Мондый мөмкинлек безнең яшьләрдә дә бар хәзер. Үз балаларымнан чыгып әйтәм. Олы кызым Диләрә татарча, русча, инглизчә эш йөртә, укый, яза. Стажировкада Америкада булып кайтты, аңа кадәр Босния һәм Герцеговинада булды. Алсуым да өч телдә иркен аралаша. Алман телен камилләштерү өчен Германиядә булып кайтты. Испан теле курсларына йөрде, төрек теле белән кызыксына. Алар өчен капкалар күп җирләрдә ачык хәзер.

сөендерде

көендерде







Җылы сүз – җан азыгы

Миңа калса, бүген яшьләребез әти-әниләренә карата рәхмәтне без көткәннән азрак әйтәләр. Әти-әнинең балага карата кылган һәр гамәле, һәр нияте изгелектән генә. Анда бернинди мәкер, усаллык юк. Ярдәм кулы сузабыз, киңәш бирәбез икән, болар бар да ихлас, чын йөрәктән. Җәлил хәзрәт Фазлыев әйткәндәй: «Бернинди исәп-хисапка корылмаган ярдәм ул». Һәм безгә шуның өчен нибары: «И-и, әни, әле дә син бар, әле дә син булыштың!» – дигән сүз кирәк. Шуны ишетсәк, без күккә күтәреләбез.

Һәркемнең үз юлы да бит...

Кая барсам да: театрда, җәмәгать урыннарында яки мәҗлестә еш кына үзебезнең милләттәшләр тарафыннан тәнкыйть сүзләре ишетеп торам: «Әниләр яулыкны болай бәйләми иде, безнең халык яулыкны алай ябынмаган», – диләр. Гел нидер таләп итәләр. Ә үзләренең чәчләре дә җыелмаган, кием-салымнары да Ходай кушканча түгел. Бәхәсләшәсе килгәндә дә дәшмим. Андый чакта Аллаһ кушканча киенгән, дин юлына баскан яшь кызларны уйлыйм: миңа авыр, ә аларга бит тагын да читенрәк...

Кеше хәлен кеше белми...

Җир шары бик тынычсыз. Теге яки бу кайгы-хәсрәтләр әлегә бездән ерак дип һич әйтеп булмый. Бүген ерак, ә иртәгә... Сүриядән Европага бик күп качаклар килде. Ул илләр аларны кабул итте, әмма төрле фикер бар. Имеш, җиңел тормыш эзләп кузгалганнар. Бер минутка гына үзеңне алар урынына куеп карасаң... Бөтен җыйган малыбызны, тормышыбызны, әшебезне ташлап, туганнардан аерылып, бер чемодан белән, 4-5 баланы җитәкләп, Германиядә тормыш рәхәт, дип, анда пособие бирәләр икән дип кенә кузгалыр идекме соң? Сәбәпләре, димәк, тирәндәрәк...

PRESSA.RU

16+

МӘХӘББӘТНЕҢ ГОМЕРЕ ТУГЫЗ АЙ...

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар кертә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.



Камил КӘРИМОВ,
язучы-сатирик;
өйләнгән;
гаилә стажы — 34 ел;
ике бала атасы.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Бөтен ирләр дә бер калыптан, дигән әйтемне гаилә бәхете күрмәгән хатыннар уйлап чыгаргандыр. Әйтик, мин үзем хатын-кызның аягына да, биленә дә, күкрәгенә дә игътибар итәргә өлгермим, ә әүвәл аның йөзенә тутырып карыйм. Иман нуры күреп алсам, тизрәк сөйләштерә башлыйм: тавышы елак түгелме, һәр сүзе чүкеч кебек чүкемиме, пычак кебек кисмиме...
Инде ягымлысы туры килсә, чәчен тузгыткан җил уңаена басып, ислемаен тоярга тырышам. Шуннан – богаулый да куя инде.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Аларга... саранлык та килешә. Хәтерсезрәге белән яшәве тагын да җиңелрәк: вак-төякне кабат-кабат искә төшереп җәзаламый... Ә менә бизәнергә иренмәгән хатыннарны хупларга гына кирәк.

Ә нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Ирләрнең кесәсәен актаручыларны сөймим. Үпкәләшкәндә «балавыз сыга» торганнары да җенемне чыгара.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручылар... Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Күңел ачу өчен генә дигәндә, «илһамияләр» кирәк. Яшәр өчен – хуҗабикәләр ышанычлырак. Мәхәббәтнең гарантиясе тугыз гына ай, ә бергәләшеп нужа күрү – гомерлек...

Чынында исә, танышып-кавышканчы кызларны без гел илһамландыручы буларак кына күрәбез. «Кухня һәм комфорт» төшенчәсе яши башлагач кына килеп чыга. Эштән арып, карыны ачып кайткан ир, иң әүвәл тамак ялгап, бераз ял итеп алу турында гына уйлый ала. Ә менә инде тамагы туйгач, ир кешенең фәлсәфәсе үзгәрә – аңа «илһамия» кирәк. Яши-яши хатыннарның да зәвыгы үзгәрә – аларга байлык кирәк икән! Олигархлар һәм чибәр сөяркәләр турында сериаллар карап бозылып бетәбез бугай инде.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Дус һәм дошман дип шәрехләсәк, хәзер үз хатының гына иң ышанычлы дус була ала. СССР таркалгач, бик күп дуслар сатылып бетте. Хәзер бит сыйнфый дошманнар юк, сыйнфый дуслар гына бар. Алар белән аралашу, ихластан дуслашу, көрәшү дә җиңел түгел.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– Тәкъдим ясаган көне-сәгате юк: биш ел бергә укыдык, ике ай буе Молдавиядә студентларның төзелеш отрядында булдык. Диплом алгач язылышырбыз дигән идек, нәкъ шулай килеп чыкты да. Кире чигенергә урын калдырмадык, алдан ук туй күлмәге, костюм-чалбар тектердек. Алтынга бик нык бәя арткан, «кытлык-корылык» башланган чор иде: загс белешмәсе белән балдакка 50 процент ташлама ясадылар һәм ике әрҗә аракы алырга рөхсәт бирделәр. Көндезләрен укыдым, кичләрен гел эшләдем, туйга дип ике мең сум акча (1981 ел бу!) җыйдым.

Әгерҗегә кызларын сорарга кайткач, әнисе: «Кызым, синең яшьрәк егетләрең дә бар иде бит», – дип каршы төшмәкче иде дә, ләкин Клара җавапны бик кыска тотты: «Киявегез йә шушы кеше, йә беркем дә түгел!» – диде.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Дөрес сүз түгел бу! Кызлар белән танышуны җиңеләйтер өчен кайбер ирләр уйлап чыгарган шаяру гынадыр.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар... Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Ир кеше гаиләдә баш була алса – гаиләсе ныграк була. Кыз бала кечкенәдән алтын-көмеш әйберләргә кызыгып үсә, аның өчен бәхет белән байлык бер исәптә.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Кавышуны ашыктырырга бер сәбәп инде бу. Сөяме-сөймиме, дип ромашка чәчәге таҗын өзгәләп вакыт әрәм иткәнче, туп-турыдан хәл итәсең дә куясың...

Игътибар итегез әле, безнең халык: «Малаем өйләнде», – дими, ә: «Улым башлы-күзле булды», – дип сөйли... Димәк, өйләнгәч, ирләрнең күзе ачыла, башы да дөресрәк эшли башлый. Менә шул чакта ник ашыгып өйләнгәнеңә үкенә башлыйсың да инде... Элеккеләр бу мәсьәләдә акыллырак булган. Патша Россиясендә ирләр 40-45 яшьләрдә өйләнгән. Йә ул солдат хезмәтен үтәп, йә байлык туплап өлгерергә тиеш булган.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Йә гәүдә, йә һөнәр, йә фатир, йә романтика, йә әти-әнисе, йә кыюлык, йә тәмле тел, йә байлык...

10 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Күзгедән күренми торган шәп якларым җитәрлек лә...

11 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта.

– Әгәр ир-ат үзе дә менә дигән буй-сынлы, булдыклы икән – куркытмый торгандыр. Булдыксыз, җебегән, мәхлук ирнең хатыны чибәр икән, монда инде ул ир тарафыннан көнләшү, үзен бераз кимсетеп тоту кебек гадәтләр барлыкка килергә мөмкин.

12 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Кавышканчы ирләр ашыктыра, кавышкач, хатыны көенә бара. Минемчә әйтсәк: кызлар җиде кат үлчи, бер кат кисә, ә егетләр бер кат кисә дә, соңыннан җиде кат үлчәп йөри.

13 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен, үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Игътибар иткәнегез бармы: җылы якта яшәүче халык аз хәрәкәтләнә, кояштан качып, күбрәк күләгәдә утырырга тырыша, алар бөтен авыр эшне көн кызуы сүрелгәч башкарыр, әкрен йөрер, ашыкмас... Минем хатын да әнә шундыйрак бик кызу планетадан килгәндер. Ул флегматик – үз көенә тау-ташлар күчерә ала. Әгәр шунда: «Тизрәк кыймылда инде!» – дип өстенә кычкырсаң, коела да төшә, үпкәләргә дә мөмкин... Ә мин үзем пружиналарым бушаганчы йөгерәм, тиз-тиз ашыйм, кабаланам, йоклаганда да кыймылдап ятам, йокы аралаш йөреп тә керәм... Лунатик – айдан төшкән кешедер, күрәсең, айның да салкын ягыннан.

Бакчада, рәхәтләнеп бәрәңге үсәрдәй җиргә хатынның ел саен түтәл-түтәл чәчәк утыртуын да бик аңлап бетерә алмыйм инде.

14 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез? Үзегезнең хаклы булуыгызны исбатларга тырышып карыйсызмы, әллә инде юл куясызмы?

– Кая инде юл кую?! Тавышны көчәйтеп җиңәм. Сүгенгән чакларым да җитәрлек. Тиз кызам һәм шунда ук сүреләм. Ә менә мин сүрелгәч, ул сеңдереп кенә әйтеп куя һәм... хаклы була.

Хатын-кызга ир кешенең авызын ябу бик җиңел бит ул: «Вакланма, зарланма, ир кеше була бел инде», – дип кенә әйтәләр... Шым буласың. Хаклы-хаксызны конфликтлы минутларда ачыклау мөмкин түгел, тынычлап сөйләшү кирәк. Ә тынычлану өчен кайсыдыр бер як ак флаг (әләм түгел) күтәрергә – бераз гына җавап кайтармыйча түзеп калырга тиеш.

15 Шундый очракны күзаллыйк әле: арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора.

– Пешерә белмим. Йомырка тәбәсе генә ашап ир кеше күпме яши ала – шул чаклы яшәрмен.

16 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Минеке генә шулай озак әзерләнә дип белә идем, барыгыз да бер иш икән алайса... Дөрес, барасы җирнең бөтен вак-төяге аның җилкәсендә, шуңа да җиренә җиткереп әзерләнә. Ә мин, йөрәкне бозмас өчен, машинаны кабыза торам, дип, чыгып китәм.

17 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Мин үземә носки да сайлый белмим. Кибет шүрлекләре буш чорда, Мәскәүгә баргач, су буе чират торып, Польшадан кертелгән ботинка алдым: сайладым-сайладым, киеп-киеп карадым да, түләдем. Казанга кайткач киеп карасам – аякны кыса. Ул ботинканы Роберт Миңнуллинга саттым, аның аягы бер үлчәмгә кечерәк икән.

Хатын ни-нәрсә кирәген алдан ук үзе белеп тора, мине кибетләргә сөйрәп йөрми. Алып кайткан бүләкләре таман гына була.

PRESSA.RU



БАШТАНАЯК МАТУР БУЛ

Баш киемнәренә борын-борыннан ук аерым хөрмәт белән караганнар. Кеше тәненең иң кадерле өлешен — акыл сыйдырган башны саклау вәкаләте тапшырылган аңа! Башлык кар-яңгырдан, салкыннардан коткарган, сугышчыларны дошман һөҗүменнән йолып калган. Саклау хасияте булган билгеләр ясалган чалма, имеш, явыз көчләрдән аралаган.

Соңгы вакытта баш киемнәрен дөрес итеп киюгә дә игътибар ителә. XXI гасырда баш киемнәре җылытып, кояш нурларыннан саклап кына калмый, бәлки, кигән кешенең кемлеген белгертә торган аксессуар да. Бүгенге тизлек, нанотехнологияләр заманында да мода көтелмәгән «могезләр» чыгарып куя.

Шәһәребездә баш киемнәре дизайнеры Анастасия СОРОКИНА яши. Модалы баш киемнәренә, үзегез беләсез, ихтыяҗ һәрчак зур. Настя Прагада туган, озак вакыт Башкортстанда яшәгән, педагогик белеме бар. Дизайнга үзлегеннән өйрәнгән ул. Ләкин һәр кешенең тормышында хәлиткеч борылышлар була. Настя җәйге челләдә колагына салкын тидерә. Ни хәл итмәк кирәк, кызыйга җылы баш киеменнән йөрергә туры килә. Бу хәл Настяны ел әйләнәсе киярлек баш киеме – чалма уйлап табарга этәрә. Гадәти генә чалма булмый ул. Күргән берсе, бигрәк килешле, каян алдың, ничек табарга дип кызыксына башлый. Шәрыкта чалманы борын заманнан ук башка урый торган булганнар. Аны елның теләсә кайсы вакытында ирләр дә, хатын-кызлар да салмаган. Андый баш киеме көндәлек тормышта да, бәйрәмнәрдә дә килешле. Шәрык баш киемнәренең катлаулылыгы – баш өстендә матур оя ясап куюдадыр, мөгаен. Настя «оя коруның» гади һәм җайлы чишелешен тапкан: галәмәт зур килешсез нәрсәдән дә чалма

ясап, соклангыч матур күренеп була. Анастасия уйлап тапкан баш киемнәре теләсә кайсы сезонга да ярашлы. Кыш өчен чалма җылы йон тукымадан ясала.

Без җан җылысын, уңайлылыкны тансыкладык. Бәлки, шуңа күрәдер, күп кызлар һәм ханымнар шәркый нәфислеккә, татар милли бизәкләре белән чигелгән киемнәргә өстенлек бирәдер.

2009 елдан башлап Анастасия әкренләп үзе ясаган баш киемнәрен сатуга чыгара башлый. 2010 елда Евро–Уфа–Азия конкурсында катнашып җиңеп чыга. 2011 елның мартында Санкт-Петербургта узган Сәнгать атналыгында катнаша, бу аны фешн-индустриягә багышланган төрле чараларга алып кереп китә. Ире белән үз эшен ачып җибәрә, аларның гаилә бизнесы җиңел сәнәгать индустриясендә төүге адымнарын ясый. Анастасия иҗат иткән баш киемнәре россиялеләрне генә түгел, чит илдәге мода тарафдарларын да битараф калдырмас. Соңгы вакытта ул баш киемнәрен төрләндерү өстендә эшли. Кубанка бүрекләр, козыреклы кепкалары төрле тукыма, ясалма мех детальләрен аралаштырып тегелә.

Үзеңә килешле баш киемен ничек сайларга? Дизайнер Анастасия Сорокина шул хакта сөйли.

Чалма:

Чалма, нигездә, бар кешегә дә килешә, ләкин кызлар һәм ханымнар истә тотарга тиешле аерым үзенчәлекләре дә бар. Нәфис йөзле кызларга трикотаж баш киемнәре килешәрәк төшә. Киң йөзне исә трикотаж белән тарттырып булмый. Түгәрәк йөзле хатын-кызларга твид һәм кашемир кебек җиңел тукымалардан тегелгән баш киемнәре отышлы булачак.

Бәйләнгән башлыклар:

Кыш көне кардан яки көчле җилдән саклану өчен менә дигән баш киеме! Аларны төрле җепләрдән бәйләп була, кыш өчен, әлбәттә инде, кашемир башлыклар җылырак. Өс киемегезгә туры килеп торырлык кара, соры, зәңгәр, аксыл көрән төсләрне сайлагыз.

Ничек кияргә? Башлык арттан бераз иркен булырга тиеш. Аны кашыгызга кадәр батырып кимәгез. Башлыкны кайтармалы итеп тә киеп була, бу очракта резинкалап бәйләнгән караңгы-зәңгәр төстәге башлыкны сайлап, кечкенә моряк образы тудырырга мөмкин. Яшь кызларга бик килешәчәк.

Фетр эшләпәләр:

Ирләр гардеробыннан алынган бу кышкы эшләпәләр теләсә кайсы киемгә килешәчәк, модада булачак. Сумкага да сыя торган йомшак эшләпәләр сайлагыз, формасын югалта дип хафаланасы булмас. Гадәттә, андый эшләпәләр куян мамыгыннан йә йоннан эшләнә.

Ничек кияргә? Кырлары тар булса, баш артына шудырып – бу инде йомшак фетр ирләр эшләпәсе була яки, кырлары киң очракта, бераз маңгайга төшереп кияләр.

Рәмзия КАШАПОВА

Дизайнерские тюрбаны/пилотки/кепки/шляпыSorokina



Instagram:@sorokina_hats
https://vk.com/sorokina_hats
+7(960)051-54-16
+7(987)000-555-0

РЕКЛАМА





2016 ел — Маймыл елы. Әйдәгез, бергәләшеп Яңа ел хуҗасы — сөйкемле маймылны ясыйбыз. Бу мавыктыргыч эшкә балаларыгызны да җәлеп итә аласыз. Бергә-бергә эшләү тиз дә, кызыклы да. Еллар узар, бүген сабый булган оланнарыгыз үсеп җитеп, үз балалары белән чыршы бизәгәндә шушы маймылны кулга алырлар да, аны бергәләшеп теккән кичне искә төшерерләр. Алар өчен якты балачак хатирәсе булыр ул.




Мастер-классны Диана ЗӘЙНУЛЛИНА үткәрә.

МАЙМЫЛ КЫЗЫ

Кирәк:

- 20х25 см көрән төстәге йөнтәс тукыма;
- 15х25 см аксыл тукыма;
- 12х100 см алсу төстәге фатин (сетка яки капрон белән алыштырырга була);
- холлофайбер (иң арзанлы мендәр сатып алып, шуның эчен кулланырга мөмкин);
- 50 см тар атлас тасма;
- 2 кара сәйлән яки яртылы мәрҗән (полубусинка);
- 20 см нечкә тимерчыбык (чәчәк кибетләрендә сатыла торганы яхшы. Ул булмаса, ут чыбыклары эчендәгесе дә ярый);
- көрән һәм аксыл төстәге тегү җепләре, тегү энәсе, озын камыт энәсе.



■ бирелгән өлгеләрне каләм эзеннән кисәбез.

Эш барышы:



■ Көрән тукыманы уң ягы белән эчкә каратып, икегә бөклибез. Акбур белән гәүдә һәм тәпиләрнең өлгесен төшерәбез. Шушы эздән машина җөе белән вак атлатып тегәбез. Тегеп бетергәннән соң, җөйдән 0,5 см ара калдырып, «зигзаг» тешле кайчы белән детальләрне кисәбез.

■ Маймылның эче һәм йөзе ике катлап куелган аксыл тукымадан тегелә. Кисү, тегү эше нәкъ гәүдә өлешен теккәндәге кебек.

■ Колакларның аскы каты – көрән, өске каты аксыл тукымадан киселә, башка беркетеләсе читен текмичә калдырабыз.

■ Гәүдәнең кендек тирәсендә очлы кайчы белән 1,5 см кисем ясыйбыз. Шундый ук кечкенә кисемнәрне башка детальләрдә дә ясарга кирәк булачак. Агач таякчык ярдәмендә аларның һәрберсен уң ягына әйләндерәбез. Тәпиләр белән игътибарлырак булыгыз, алар бер-берсенә карап торырга тиеш! Кисемне тәпинең гәүдәгә беркетеләсе ягына ясыйлар.

■ Гәүдә белән тәпиләргә тыгыз итеп холлофайбер тутырабыз. Монда да агач таяксыз булмас. Тутырып бетергәч, энәгә тукыма төсендәге җеп саплап, яшерен җөй белән кулдан гына типчеп куябыз. Гәүдәгә кечкенә генә йөрәк тә тыгып калдыралар – матур хисләребезнең гәүдәләнеше ул.

■ Аксыл тукымадан тегелгән өлешләрне уң ягына әйләндергәч, эчке яктан таяк очы белән этеп, җөйне тигезлибез. Аннары аларны үткәргә дә кирәк булачак. Маймылның йөзен башына яшерен җөй белән генә тегеп куябыз. Теккәндә урыныннан күчмәсен өчен, чукмарбашлы энәләр белән беркетеп торсаң уңай.

■ Кендек турындагы кисемне каплап, маймылның эчен тегәбез. Тегеп бетергәндәрәк кенә бер чеметем холлофайбер тыгып калдырсак, корсагы күперенкерәк булып, бәләкәчкә сөйкемлелек өстәячәк. Кендек уемы көрән төстәге җеп белән чигелә.

■ Хәрәкәтчән булсын өчен тәпиләрне махсус ысул белән беркетәбез. Озын энәгә тукыма төсенә ярашлы ныграк җеп саплап (мулине дә ярый), уң тәпинең гәүдәгә беркетеләсе ягыннан бер-ике чәнчеп алабыз. Аннары энәне гәүдә аша үткәреп, икенче тәпи беркетеләсе урыннан чыгарабыз. Ул тәпинең дә эчке ягыннан бер-ике чәнчибез. Шул рәвешле энәне гәүдә аша ике-өч тапкыр уздырабыз. Аннары җепне ныгытып тартып, тәпиләрне гәүдәгә кысабыз. Култык төбендә җепне төенләп, энәне койрык турысыннан чыгарабыз, җепне кисәбез.

■ Көрән тукымадан иңе – 5 см, озынлыгы 20 см булган тасма кисеп алып, турыпочмаклык тегәбез. Бу – койрык булыр. Аны булавка ярдәмендә уң ягына әйләндереп, эченә тимерчыбык тыгабыз. Карга борыны белән тимерчыбыкның очларын бөгәргә кирәк, югыйсә ул тукыманы тишеп чыгачак. Койрыкны да беленми торган җөй белән тиешле урынына тегеп куябыз. Инде колакларны беркетик.

■ Маймыл туташның кашлары көрән җеп белән чигелә. Күзләренә кара төстәге яртылы мәрҗән ябыштырдык (кара сәйлән дә матур булачак). Авыз-борынын башта гади карандаш белән ясыйбыз. Аннары теш чистарткыч таякчыкны көрән төстәге акрил буяуга манып, шул эз буенча йөртеп чыгабыз. Телен кызыл буяу белән буйыйбыз. Андый буяулар табу мәшәкатьле булса, чигеп кенә дә куя аласыз.

■ Без теккән уенчык – маймыл кызы. Аңа инде матур итәк тә кирәк. Фатинны 1 см киңлегендәге тар тасмаларга телеп, һәрберсен атлас тасмага элмәкләп беркетәбез. Итәк маймылның биленә бәйләп кенә куела.



Ә бу сөйкемле Кар кызларын тегүгә багышланган мастер-классны сайтыбыздан карый аласыз.

PRESSA.RU

«Сөембикә»нең кунагы — Руслан ШӘРӘФЕТДИНОВ. Укучыларыбызга «Татарстан—Яңа гасыр» каналыннан атна саен күрсәтелүче «Секреты татарской кухни» тапшыруының алып баручысы буларак таныш ул. Шаяннар һәм тапкырлар клубындагы атаклы «Дүрт татар»ның берсе булуын да хәтерлибез әле без аның. Әлмәттә туып-үскән Русланның Казанда «кайнавына» да 16 ел икән инде. Телевидениедә шушы тапшыруны алып бара башлагач, үзенең дә аш-су әзерләүгә һәвәслеге уянган. Хатыны — Татар дәүләт опера һәм балет театры балеринасы Гөлназны, кызы Самирә белән улы Әскәрне җае чыккан саен тәмле ашлар белән генә сыйлый ул хәзер. Кеше кулланган рецептларны да үзенчә баета, яңаларын уйлап чыгарырга ярата. Укучыларыбыз өчен Яңа елга яңа сый әзерләвен сорагач та, Руслан ялындырып тормады — гади генә әйберләрдән бәйрәм бизәге булырдай ризык пешереп күрсәтте.



Фото: Алексей Сагитов

ТАБЫНГА — «ЧЫРШЫ»

Кирәк:

(биш кешелек гаилә өчен)
- кило ярым ит фаршы;
- 200 г чүпрәсез катлы камыр;
- 200 г төшсез каражимеш;
- 1 баш суган;
- тәменчә тоз-борыч;
- агач таякчыклар.







Эш барышы:

■ Фаршка ваклап туралган суган, тәменчә тоз-борыч кушып, яхшылап болгатабыз. (Фаршка суганны жәлләмичә кушарга кирәк. Суганы күбрәк һәм ите майлырак булса, ризык сусылрак, тәмлерәк була).

■ Агач таякчыкларга өчәр каражимеш эләбез. Җимешләр сусыл булса, аларны алдан суга салып торуның кирәге юк, әгәр дә инде корырак икән, җылымса суга салып, бераз җебетеп аласы була.













■ Таякка элгән җимешләрне шактый калын итеп ит фаршы белән төрәбез. Ит таралып төшәрлек булмасын – уч төпләре белән яхшылап кыскалагыз! Кырыйдагы җимешләр күренеп калсалар да ярый, алай матуррак та булачак әле.
■ Бүлмә температурасында җебетелгән камырны кунага салып, уклау белән тәгәрәтеп җәябез. Артыгын юкартмагыз, 0,2-0,3 мм калынлыгында булса, шул җиткән. Шушы камырны ярты сантиметрлы тасмаларга теләбез.

■ Ит өстеннән спираль рәвешендә камыр тасмаларны чорныйбыз. Тасмаларның ике башын да таякка чорнап куярга кирәк. Алай итмәсәң, камыр кирәкле рәвешен сакламаячак.
■ Таба төбенә фольга җәеп, итле таякчыкларны тезәбез. Майлаган табага гына да тезәргә мөмкин. Араларын бушрак калдырыгыз. Мичкә тыгар алдыннан өсләрен үсемлек мае белән майлап алырга кирәк булачак.
■ Сюрпризлы Яңа ел котлетлары 200 градуска кадәр кызган мичтә 40 минут чамасы пешә.

■ Бу ризык Яңа ел табынына дип әзерләнде – бәйрәмчә итеп бизик әле үзен. Моның өчен зур матур тәлинкәгә түгәрәк тәбикмәк салабыз. Итле таякчыкларның бер очын тәбикмәккә кадап, икенче очын бер-берсенә терәп, бастырып куябыз. Үзенә күрә, чыршы хасил булды. Инде «чыршы» очына кызыл помидордан киселгән лалә чәчәге кадыйк та, табын уртасына куйыйк. Ышаныгыз, якыннарыгыз бу ризыкны әле бер генә пешертмәс үзегездән. Яңа ел мөбарәк булсын!

«Ә диганче»



Бәйгебезне Казан шәһәренең 415 нче балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүче Миләүшә ШИҺАБИЕВА дәвам итә. Ул тәкъдим иткән бу торт теләсә кайсы бәйрәм табынына куярлык.

Кирәк:

(камыр өчен)
- 5 йомырка;
- 150 г шикәр комы;
- 150 г он;

(эчлек өчен)
- ярты литр кибет каймагы;
- 150 г шикәр комы;
- 3 банан һәм бизәү өчен кокос йомычкасы. (Без аның урынына уылган шоколад кулландык, әмма Яңа ел табынына куяр өчен пешерелгән тортны кокос йомычкасы белән бизәсәгез, матуррак булачак.)

Эш барышы:

■ 5 йомырканы яхшылап күпертәбез. Шуңа он белән шикәр комын кушып, янә бераз туглыйбыз.
■ Кечерәк табаның төбен майлап, камырны шунда бушатабыз да 180–200 градус кызулыктагы мичтә 20 минут пешерәбез. Баштагы 15 минутта мичне ачарга ярамый.
■ Пешкән коржны бераз суытып, озын пычак белән икегә бүләбез.
■ Кибет каймагын шикәр комы белән туглыйбыз.
■ Коржның берсен зур тәлинкәгә салып, өстенә шикәрле каймакның яртысын ягабыз.
■ 3 бананны юка гына итеп тәгәрмәчләп турап, каймак өстенә тезәбез дә икенче корж белән каплыйбыз. Аның өстенә каймакның калган яртысын сылап, кокос йомычкасы сибәбез.
■ Тортны бераз суыткычка куеп торсагыз, ул йомшабрак китәр.



XXI гасырның тагын бер елы тәмам. Алда яңа — 2016 ел — Шәрык календаре буенча Кызыл маймыл елы! Быелгы ел тынгысызрак, ыгы-зыгылырак булырга охшап тора. Маймылның холкын үзегез беләсез инде! 2016 елның стихиясе — ут, ә ул гел хәрәкәттә, гел югарыга үрли. Ул яктылык, җылылык чыганагы. Юлындагы киртәләрне җиңеп, алга ыргыла. Димәк, 2016 ел яңа үрләр яулау, дөньяга балку, танылу, үзгәрү, яңа эшләр башлау өчен яхшы вакыт булырга тиеш. Бөтен нәрсәдән яхшылык эзләүче, белемгә, яңалыкка омтылучылар өчен Маймыл елы уңыш вәгъдә итә. Елны уңышлы итеп уздыру өчен фэн-шуй белгечләренең киңәшләренә кызык өчен генә булса да күз салыйк әле. Дөньяныкын белмәссең, бәлки, ярдәме тиеп куяр.

МАЙМЫЛ ЕЛЫ — МАЙМЫЛЛАНМА!

Нинди кием киярга

Кызыл маймыл белән бер күрүдә дуслашу өчен, ут кебек янып торган җете төсләр сайларга кирәк. Болар, кызыл, сары, кызыл-сары, җирән, мәрҗән (коралл) төсләре. Мут маймыл көмеш төскә дә сүз әйтмәс. Фәкать шушы көнне кию өчен генә яңа күлмәк алырга димәгән. Муеныгызга маймыл яраткан җете төстәге шарф яки муенса гына да тага аласыз. Гел киеп, инде бераз ялыктырган күлмәкне дә бәйрәмчә итеп үзгәртергә була. Мәсәлән, күлмәкнең яка читенә, җиң очларына ялтыравык сәйләннәрдән берәр үзенчәлекле бизәк чигеп куйсагыз, яңа күлмәк алып кигәндәй булырсыз.

Кадерле ир-егетләребез үзләренең гомер бакый яратып кия торган караңгы төстәге костюмнарыннан булсалар да, маймыл аларны кичерәчәк. Иң мөһиме – костюм эченнән кигән күлмәк тел-теш тидерерлек булмасын да, галстуклары күз явын алсын.

Чәчне ничек ясарга

Хатын-кызның зиннәте – чәч. Кешенең күзе иң элек чәчкә төшә. Чәч караулы булса, хатын-кыз затлы күренә. Чәчең килешле икән, кигән күлмәгеңнең ниндилегe дә мөһим түгел. Кыска чәчләрне ялтыравыклы лак сиптереп, күпертергә мөмкин. Уртача озынлыктагы чәчләрне бөдрәләтеп, иңнәргә таратып кына салсаң да матур. Озын чәчләрне исә әллә нинди әкәмәт рәвешләргә кертеп үрергә була. Ничек кенә булса да, чәч сезне бизәргә тиеш. Җиңел холыклы итеп күрсәтә торган прическалар киңәш ителми – андыйларны маймыл дус өнәми.

Табынга нәрсә куярга

Мул табыннан башка бу бәйрәмне күз алдына да китерә алмыйбыз. Мандариннарсыз, атаклы оливьесыз нинди Яңа ел булсын инде, ди?! Ә менә тәмлетамак маймыл нәрсә ярата икән соң? Аның күңелен ничек күрергә?

Маймыл матур итеп бизәлгән табигый ризыклар ярата. Гаҗәеп бай табын әзерләү мәҗбүри түгел. Иң мөһиме – матур итеп бизәлгән булсын ул. Өстәлгә ак эскәтер җәеп (аның өстеннән әфлисун төсендәге тар гына җәймә җәяргә була), тастымалларны, кашык-чәнечкеләрне ачык төстәге матур тасмалар белән бәйләсәң, бик матур булачак. Шул ук тасмаларны күбәләкләп бәйләп, булавкалар белән эскәтер читләренә дә беркетергә мөмкин.

Маймыл – җылы як кунагы. Җиләк-җимеш, баллы тәм-том ярата. Аларны өстәлгә мулдан тезегез. Ә менә хәмер исен маймыл бер дә яратмый икән. Моны да истә тотыгыз.

Болар шаярулы киңәшләр иде, әлбәттә. Яңа елны ничек каршы аласын һәркем үзенчә хәл итә. Ничек кенә каршы алсак та, уңышлы, бәрәкәтле, тыныч-имин ел булсын ул.

Барыгызны да Яңа ел белән тәбрик итәбез, кадерле укучылар!


КУЧКАР. Һөнәри һәм иҗади сәләтегезне күрсәтү өчен бик яхшы ел булачак. Тормышның теләсә кайсы өлкәсендә уңышка ирешерсез. Һөнәрегезне үзгәртергә уйласагыз, отарсыз. Бу сезгә җан тынычлыгы да бирер, дәрәҗәгезне дә арттырыр.


ҮГЕЗБОЗАУ. Сезне уңыш, һөнәри үсеш, керемнәрнең артуы көтә. Гаиләгездә дә куанычлы хәлләр, шатлыклар күп булачак. 2016 ел – гаилә кору яки бәләкәч алып кайту өчен бик яхшы вакыт.


ИГЕЗӘКЛӘР. Шатлыгы да, мәшәкате дә җитәрлек булыр. Эшегезне җиренә җиткереп башкарырга тырышыгыз, югыйсә җитәкчегезнең начар мөнәсәбәтенә юлыгуыгыз бар. Эш алыштыру өчен кулай ел түгел. Тормышыгызда зур үзгәрешләр көтелми.


КЫСЛА. Һөнәри яктан күтәрелешләр булмаса да, финанс ягыгыз тотрыклы калыр. Эш сөюегез, тырышлыгыгыз һәртөрле киртәләрне дә җиңәргә булышыр. Ялгызыгыз гына калырга теләгән, ялыккан мизгелләр булыр.


АРЫСЛАН. Тормышыгыз зебраны хәтерләтер. Берара уңай булса, берара – авыррак. Авырлыкларның вакытлыча гына булуын онытмыйча, үзегезне кулда тотсагыз, уңышка ирешми калмассыз. Таныш булмаган кешеләр белән серләр бүлешмәгез, зыяны тиюе бар.


СӨМБЕЛӘ. Шәхси тормышта да, эштә дә зур уңыш көтелә. Һәр яктан яхшы үзгәрешләр булачак. Яңа эшкә керешсәгез, отарсыз. Ялгызлар быел насыйп ярларын очратып, гаилә корачак. Гаиләлеләрне дә күңелле сюрпризлар, хисләрнең кабат дөрләве куандырачак.


БИЗМӘН. Катлаулы, четерекле мәсьәләләрне хәл итәргә туры килер, башкарган вазыйфаларыгыз бик зур көч, игътибар сорый. Аның каруы, әҗерен дә мулдан алырсыз. Шәхси тормышыгыз үз җае белән барыр, зур вакыйгалар көтелми.


ЧАЯН. Елның үтеп киткәнен дә сизми калырсыз. Яңа сәфәрләр, яңа танышлар, яңа хисләр бөтереп алыр. Шундый сәфәрләрнең берсе язмышыгызны бөтенләй дә үзгәртеп ташларга мөмкин. 2016 ел – яңа эшкә күчү, һөнәр үзгәртү өчен менә дигән вакыт.


УКЧЫ. Керемегез артыр, һөнәр баскычында югарырак күтәрелерсез, керемегез дә кимемәс. Сизгерлегегез низаглардан котылып калырга ярдәм итәр. Дус-ишләрегез арасында дәрәҗәгез артыр. Яңа танышлар белән сак булыгыз. Читләргә серегезне ачмагыз.


КӘҖӘМӨГЕЗ. Теләсә нинди мәсьәләне дә хәл итәрлек көчкә ия булырсыз. Хыялларны, теләкләрне чын итә торган ел бу сезнең өчен. Тырышлыгыгыз да, хезмәтегез дә тиешенчә бәяләнер.


СУКОЯР. Һөнәри вазыйфаларыгызны башкарганда аеруча игътибарлы һәм тыныч булырга тырышыгыз. Ашыгуыгыз зыян салырга мөмкин. Якыннарыгыз белән дә түземле булыгыз. Ел катлаулырак башланып китсә дә, тора-бара уңай якка үзгәреш тоярсыз.


БАЛЫК. Тыныч, рәхәт ел көтелә. Уңышларыгыз күңелегезне генә куандырып калмас, акчалата әҗерен дә кайтарыр. Шәхси тормышыгызда да мәхәббәт, аңлашу, хөрмәт кебек якты хисләр өстенлек итәчәк. Бергә уздырган ял сезне әле тагын да якынайтачак.

декабрьдә кабынган йолдызлар

Татарстан



Фәүзия БӘЙРӘМОВА (5.12.1950) – **сәясәтче, язучы, җәмәгать эшлеклесе.** Саба районы Сабай авылында туа. Сигезенче сыйныфтан соң район газетасына эшкә урнаша. Аннан театр училищесын тәмамлый. 1983 елда Казан дәүләт университетына укырга керә. Беренче зур әсәре – «Болын» повесте. Сиксәненче еллар ахырындагы үзгәрешләр аны милли азатлык көрәшчесе итеп таныта. 1990–1995 елларда – Татарстан Республикасы парламенты депутаты. Иҗаты да шул елларда активлаша. «Кырык сырт», «Соңгы намаз» (шушы һәм «Кара урман» романы өчен 2001 елда Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясенә лаек була), «Караболак» романнары халкыбыз язмышын таныта торган әсәрләр. Соңгы елларда зур-зур тарихи романнары дөнья күрде.

Россия



Ольга Аросева (21.12.1925–13.10.2013) – **театр һәм кино артисты.** Мәскәүдә революционер Александр Аросев гаиләсендә туа. Ольгага биш яшь чагында әниләре яңа мәхәббәте артыннан Сахалинга китә. 1937 елда әтиләре кулга алынгач, балаларны да шунда озаталар. Ольга, мәктәпне экстерн тәмамлап, цирк училищесына укырга керә. Ике елдан Мәскәүдәге театр мәктәбенә күчә. Ләкин аны да тәмамламый – өченче курста укыганда, апасының дипломы белән Ленинград комедия театрына эшкә урнаша. Төрле елларда төрле театрларда эшләгән актриса кинода 1940 елларда уйный башлый. Танылу китергән эшләре – Эльдар Рязановның «Берегись автомобиля» һәм «Старики-разбойники» фильмнары.

Чит илләр



Эдит Пиаф (19.12.1915–10.10.1963) – **дөньякүләм танылган җырчы һәм актриса.** Парижда туа. Әнисе аны әчкече әбисенә ташлап китә. Соңрак әтисенең әнисендә – Нормандиядә фәхешханә тотучы әбисендә яши. Өч яшендә дөм сукыр булуы ачыклана. Бәхеткә, алты яшендә күзләре ачыла. Аңа мәктәптә уку эләкми – әти-әниләр балаларын фәхешханәдә яшәүче кыз белән бергә укытырга теләмиләр. Тугыз яшеннән Париж урамнарында җырлап, тамак туйдыра. Танылу аңа 20 яшендә, «Жернис» кабаресында эшләгәндә килә. 1936 елда «Медрано» циркы аренасында узган концерттан соң, Эдит Пиаф исеме телдән төшми. Ә инде «Бөек Эдит Пиаф» барлыкка килүгә шагыйрь Раймон Ассо «гаепле». 1954 елда «Версаль серләре» фильмында уйный.

PRESSA.RU



ӘНҖЕ КАЛФАК

Бердәнбер бугай ул. Алтын җепләр белән хәтфә тукымага татарның тарихын чигүче Луиза Фәсхетдинова хакында әйтүем. Әле бик борынгы ук булмаган заманда да һәр татар өендә кул эшенә маһир чигүче, тукучы, бәйләүче, каючы кызлар үскән. «Әбиемнең биш кызы булган. Әтнә районындагы Бәрәскә авылына кунакка кайткач, диварга беркетелгән чигү эшләрен күреп хәйран калганым хәтердә. Һәр чигештә «Әниемә бүләккә» дигән сүзләр дә бар. Мин дә бер матур нәкышны мулине җебе белән тукымага күчереп, аңа: «Әбиемә бүләгем» дип чигеп куйдым. Беренче эшем шул булды».

Рәсем мәктәбендә укыган кызның юлы рәсем сәнгате училищесында, аннары Татарстан Фәннәр академиясенең тарих институтының аспирантурасында дәвам итә. Кызының бу юнәлешен әтисе – танылган рәссам Фәһим Фәсхетдинов та бик хуплый: «Кызым, бик кирәкле, бик игелекле шөгыль булыр бу. Өйрән син татарның нәфис мәдәният дөньясын. Оттырмассың!» Чыннан да, оттырмый Луиза. Чигешләрнең хасиятен, чигү алымнарын, тукыма төрләрен өйрәнә торгач, ул әллә нинди тарихи табышларга юлыга. Шәмаиле, намазлыгы гына түгел, кигән киеме дә алтын җепләр белән чигелгән халыкның кем булганлыгын аңлау өчен Луиза Фәсхетдинованың «Хәзинә» күргәзмәләр галереясына бер кагылып чыгу да җитә. Ә ул үзе бу нечкә сәнгатьне 20 ел өйрәнгән. Ука белән чигү, тамбур ысулы белән бизәк төшерү генә түгел бит әле ул чигү осталыгы. Әйтик, Луиза иҗат иткән ләүхәләрдә (шәмаил) мөселманны гомер буе озата барган дога сүзләрен укыйм. «Оҗмах капкасы», «Фирдәвес», «Ихлас сүрәсе» – болары шәмаилләр. Тамбур ысулы белән элмәкләп тә, укалы чигү белән дә эшләнгән сәнгать әсәрләре – намазлыклар, сузанеләр (мәгънәви бизәкләр төшерелгән кашагалар) янында озакка тукталам. Ә бу шкафларда калфаклар тезелеп киткән. Һәр калфак шәһәр тормышының бер өлкәсеннән хәбәр. Әйтик, очлымлы калфакны ханбикәләр генә кигән. Ә менә кыңгыр салып киелә торган биек калфакның – бикәләр генә кигән баш киеменең тарихы тагын да борынгырак. Бу заманга якынайган саен, калфаклар җыйнаклана барган. XXI гасыр кызлары кечкенә генә көяз калфак яраталар. Луиза да чигү җепләренең генә түгел, бәлки, калфакка тезелә торган энҗе-мәрҗәннәрнең дә хасиятен җентекләп белә.

Хәер, Мәскәү Кремлендәге Корал пулатындагы патша киемнәрен күреп, аларның, нигездә, Казан морзалары, сарай әһеле киемнәреннән күреп, күчереп тегелгәнен белгәннән соң, югалган дәвер киемнәрен тергезүне максат итә оста. Калфаклар, бүрекләр, җиләннәр – барысы да затлы тукымадан, алтын ука белән чигелгән, мех тотып бизәкләнгән... Сөембикә ханбикә кигән киемнәрне Луизаның ничек күзаллаганын да күрдем. Япон сәнгатен хәтерләткән, шома чигү белән чигелгән кечкенә миниатюраларга сокландым да, Луиза Фәсхетдинованың шушы осталыгын отып, өйрәнеп калырга тиешле шәкертләре булмаганга көендем. Югыйсә аның Бохарага кадәр, Кырымга кадәр барып җитеп эзләп тапкан, бөртекләп туплаган табышлары татарның югалган нәфис сәнгать ядкарьләре бит ул. Бу сәнгать өлгеләре белән Төркиядә дә, Иранда да, Омман солтанатында да Россия уртасында Татарстан дигән ил барлыгын белдереп кайткан кеше лә ул. Бу сәнгатьне саклап калу, аңа икенче гомер бирү Луизадан бигрәк, татарның үзенә кирәк.

Асия ЮНЫСОВА











ЛУИЗА ФӘСХЕТДИНОВА

PRESSA.RU

Газета-журналга язылган өчен iPad!

1 **Язылыгыз**
30.12.2015 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә өч басмасына язылыгыз *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласыз).*

2 **Җибәрегез**
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәрегез *(телефон номерыгызны күрсәтергә онытмагыз)*: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт яки podpiska@tatmedia.ru

3 **Отыгыз**
Айпад, фотоаппарат һәм башка бүләкләр отарга ашыгыгыз!



Акциянең спонсоры

KUKMARA «КУКМАРА МЕТАЛЛ САВЫТ-САБАЛАР ЗАВОДЫ»

Kukmara

Сделано в России







2016 елның 12 феврале

БҮЛӘКЛӘР УЙНАТУ

Акцияне үткәрү вакыты: 1.11.2015–10.03.2016.
Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында.
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84, өстәмә номер – 1261.

16+
Реклама

«Сөембикә» журналына иң кызыклы теманы сайла!

20 декабрьдән 25 декабрьгә кадәр журналыбызның сайтында www.syuyumbike.ru укучыларыбыз тәкъдим иткән темалар өчен тавыш бирү узачак. Иң күп тавыш җыйган тема авторларын бүләкләр көтә! Темаларны сайлауга сез дә кушылыгыз!